МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№3 / март 2014

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

МИРАС
№3 / 2014

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Марат ЗАКИР
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №А-510
Тираж — 1500 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Басарга кул куелды: 3.03.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле



Порт-Артур дигән калага
Японнар туп аталар...

24 бит

Казанда мәшһүр әдип исемен йөрткән дүрт-биш йортлы урам барлыгын (Вишневский-Калинин урамнары тирәсендә) исәпкә алмаганда, әдәби вә мәдәни гавамның (һәм, әлбәттә, хакими җитәкчелекнең дә) әдип истәлеген мәңгеләштерүдә, бәһа биргесез мирасын барлау-саклауда әллә ни эш майтарганы юк шикелле.

76 бит

Ленин, Толстой кебек даһилар укыган университетның абитуриентлары булу — яшьлектә сулышка каба торган бәхет түгелмени!

78 бит

ЧЫН МИРАС
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№3(27)/март 2014

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдмәнд

ЭЧТӘЛЕК

2 **«Чын мирас» журналы: кичә, бүген, иртәгә».** *(Түгәрәк өстәл)*

ТАРИХИ МИРАС

14 **Минтимер Шәймиев: «Гомер буе вакыт җитмәде»**
20 **Яңа төрек уңчылары.** *Йосыф Акчура*
24 **Хәтер яңарту: рус-япон сугышы татар чыганакларында.** *Раиф Мәрданов*
29 **Япон сугышы яки татар солдаты.** *Габделхаликъ Әхмиров*
40 **Йортларның да җаны бар.** *Сәмига Сәүбанова*

ӘДӘБИ МИРАС

48 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
52 **Тукай энциклопедиясенә**
53 **Бер рәсем тарихы**
54 **Мәрьям.** *Зариф Мөәминов*
75 **Әдип турында замандашлары** (Әмирхан Еникинең тууына 105 ел)
76 **Әмирхан Еники музее булырмы?** *Ләбиб Лерон*
78 **Сүз хәнҗәре кынындамы?** *Марсель Галиев*
84 **Шигырьләр.** *Фәннур Сафин*
86 **Милли мәзәкләр**

СӘНГАТИ МИРАС

88 **Милли мирас сагында.** *Филүсә Арслан*
96 **Зөләйха.** *Әхтәм Зарипов*
105 **Бикчәнтәевләр йолдызлыгы**

ФӘННИ МИРАС

108 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

112 **«Кояш» газетасында Казан хәбәрләре: 1914 елның февраль ае.** *Ленар Гобәйдуллин*
116 **Спорт тарихы — ил тарихы.** *Алмаз Гафиятов*
119 Мирасворд
120 Яңа китаплар. *Әлфия Мотыйгуллина*

Тышлыкның 1 нче битендә — «Казак угланнары» (фрагмент). Киндер, майлы буяу. *Р.Заһидуллин эше.*

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторларның, ТР Милли музее фондыннан, А.Дубин, Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон һәм К.Кәримов архивларыннан да фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Безнең журналга 54132 ИНДЕКСЫ буенча Татарстанның һәм 70275 ИНДЕКСЫ буенча Россия төбәкләренең һәр элемтә бүлегендә язылырга мөмкин.

«ЧЫН МИРАС» ЖУРНАЛЫ:

30 гыйнварда «ТАТМЕДИА» ААҖнең конференц-залында «Чын мирас» журналы: кичә, бүген, иртәгә» дип исемләнгән түгәрәк өстәл утырышы булып узды. Утырышта Республиканың матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе **Ирек Миннәхмәтов** һәм аның урынбасары **Илдар Сәгъдәтшин,** «ТАТМЕДИА» ААҖнең генераль директоры **Фәрит Шаһиәхмәтов** һәм аның урынбасары **Сөмбел Таишева,** Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиев,** ТР мәдәният министры урынбасары **Ирада Әюпова,** ТР мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге җитәкчесе **Алсу Шәрипова,** Татарстанның халык шагыйре, «ТАТМЕДИА» ААҖнең генераль директоры киңәшчесе **Равил Фәйзуллин,** күренекле галимнәр – **Марсель Әхмәтҗанов, Дания Заһидуллина, Рамил Исламов, Илдус Заһидуллин, Фәнзилә Җәүһәрова,** Татарстанның халык шагыйре **Ренат Харис,** Татарстанның халык язучысы **Марсель Галиев,** Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары, шагыйрьләр **Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла,** М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, шагыйрь **Газинур Морат,** «Чын мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** катнашты.

КИЧӘ, БҮГЕН, ИРТӘГӘ

Ирек МИННӘХМӘТОВ:

— Хөрмәтле ил агалары, мөхтәрәм коллегалар, дуслар! Бүген без «Чын мирас» журналы турында сөйләшергә җыелдык. Кемдер аның исемен, йөзен үзгәртергә кирәк ди, кемдер исә аның эчтәлеген, дизайнын үзгәртү ягында. Төрле фикерләр, киңәшләр бар. Әйдәгез, бергә киңәшеп, уңышларны барлап, максатларны ачыклап, журналыбызга тагын да дөресрәк юнәлеш бирик. Баш редактор — яңа кеше, бу вазифага күптән түгел генә кереште. Ул, мондагы фикерләргә колак салып, киләчәктә эшен максатчан алып барыр, журналны тиешле югарылыкта тотар, дип ышанам.

Ләбиб ЛЕРОН:

— «Чын мирас» — бүгенге көндә иң мәртәбәле, иң дәрәҗәле журналларыбызның берсе. Ул — безнең уртак журналыбыз, ул — татар халкының милли-мәдәни журналы, әйтер идем, татарның һәм тарихи, һәм әдәби, һәм сәнгати мирас журналы. Татар мохитендә, татар дөньясында, шөкер, төрле өслүбтә, төрле кимәлдә булган журналлар басыла. Әлбәттә, әлеге басмаларны, шул исәптән «Чын мирас»ны да халык укый, үзенчә бәяли, төрлечә фикер йөртә. Башка басмалар арасында безнең журнал нинди урын тота? Аның эчтәлеге ни дәрәҗәдә, укучылар даирәсе күпме? Журнал кемнәрне күздә тотып чыгарыла, иртәгә ул ничек булырга тиеш? Без бар мәсьәләләрне дә уртага салып сөйләшсәк иде.

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ:

— 1991 елдан бирле чыгып килгән «Мирас» журналы бик зур эш башкарды, халкыбызның мираска мәхәббәтен тәрбияләүдә аның ролен инкяр итеп булмый. Соңыннан гына, редакторның кайбер гаепләре белән, журнал сайлаган юлыннан тайпылып китте. Безгә элекке журналның уңай якларын күрә, ә тискәре ягыннан гыйбрәт ала белергә кирәк. Әүвәлге журнал кыю рәвештә безнең мирасыбызны пропагандалап килде, бу яңа чыга башлаган журнал да шушы позицияләрдә калсын, мирасның төрле тарихи дәверләренә игътибар итсен иде. «Чын мирас»та соңгы заман мирасларына гына игътибар ителә. Мираска тирәнрәк керергә кирәк, җәмәгать! Саллы текстологик эшләр кирәк. Шулай ук әдәбият фәнен күтәрүче галимнәр турында да мәкаләләр булырга тиеш. Мәсәлән, Җәвад Алмас турында…

Шулай ук татар сәнгатенә кагылышлы мәсьәләләрне дә тикшерү яхшы булыр иде. Әйтик, мәсәлән, җырчылар, артистлар турында языла, әмма революциягә кадәрге татар музыкасы тарихыннан мәкаләләр юк. Ә бит татарның революциягә кадәр үк композиторлары булган, алар маршлар язган, әсәрләре халык арасында бик мәшһүр булган. Революциягә кадәрге татар музыкантларының иҗатлары да журналда чагылсын иде, дип әйтергә телим.

Мирасны пропагандалау мәсьәләсенә килгәндә, мин, авылларда экспедицияләрдә йөргәндә, мәчет имамнары белән еш очрашам. Алар Казанда «Мирас» журналы чыга, аны бөтен мәхәлләләргә яздырырга кирәк, барлык укымышлы кеше бу журналны белергә тиеш, дип әйтәләр. Хәзерге «Чын мирас» та Татарстандагы һәм республикабыздан читтәге мәхәлләләргә барып җитсен иде.

Ренат ХАРИС:

—Минем карашымча, «Чын мирас» журналы үзенең юнәлешен күпмедер дәрәҗәдә тапкан журнал, анда безнең иҗтимагый аңыбызга кирәкле күп әйберләр яктыртыла. Әмма басманың юнәлешен һәм максатын тагын да ачыклап бетерергә кирәк. Мәсәлән, аның исеменнән башлыйк. «Чын» һәм «ялган» мирас була алмый! Бүген китап чыга икән, яхшымы, начармы, ул инде иртәгә мираска әверелә. «Чын»мы бу? «Ялган»мы бу? Шуның өчен журналның исемен үзгәртергә кирәк. Ике тәкъдимем бар. Исемнең берсе — «Безнең мирас». Пушкин заманындагы «Современник» журналын «Наш современник» дип үзгәрттеләр һәм ул бик уңышлы чыкты. «Безнең мирас»ка бөтен нәрсә керә. Татар халкының мең, ике мең еллык әдәбисәнгати мирасы бар. Болардан безгә ни калды? Шәһәр төзелеше, өй төзелеше, авыл культурасы кебек күренешләр бар. Бүген без ат дирбияләренең, үз киемебезнең тарихи атамаларын да белмибез… Болар бит гасырлардан килгән мирас! Бу мирас белән без бүген нәрсә эшлибез? Аны милли үзенчәлекләребезне саклауда ничек файдаланабыз? Менә шушы әйберләрне яктыртыр өчен безнең журналыбыз бар һәм аның юнәлешен без төп-төгәл итеп билгеләргә тиешбез. Икенче исем — «Мәдәни мирас». «Мәдәни мирас» — ул хәзерге журнал. Монда без татар халкы алдында торган иң зур проблемаларның берсе белән очрашабыз. Ул да булса — безнең мәдәни, дөресрәге, әдәби мирасыбыз безгә барып җитмәү. Күпчелек халык әдәби җәүһәрләрне белми һәм белә дә алмый. Әгәр дә мин, кемгә дә барып, Сәиф Сараи белән мактанырга теләсәм, мин аның әсәрләрен инглиз телендә дә, рус телендә дә таба алмыйм. Равил Бохарай тәрҗемә итте, әмма ул төгәл түгел… Габделҗаббар Кандалыйлар, Утыз-Имәниләр һ.б. йөзләгән

шагыйрьләребез һәм әдәбиятчыларыбыз бар, әмма алар әлегә бездән ерак. Шуларны белми торып, татар үзен ничек культуралы милләт дип санарга тиеш? Без бүген үзебезнең культурабызны белмибез. Аны мәктәптән үк башларга кирәк, ә мәктәп көннән-көн тәрбия һәм мәгариф мәсьәләләреннән ераклашканнан-ераклаша бара. Институтлардауниверситетларда да тарихи ядкярләрне өйрәтәләр — иске, борынгы татар телендә. Әмма сөйләшкәндә аларны сүз тәртибенә кертеп җибәреп, ягъни өземтә китереп булмый. Шуның аркасында без барлык әдәбиятны бүгенге көн гамәлендә файдалана алмыйбыз. «Мәдәни мирас» дип әйткәндә, журнал шуны укучыларга илтеп җиткерергә тиеш. Бу журнал һәрбер мәктәптә булырга тиеш, Татарстанда 1500дән артык мәктәп бар. Мәдәният министрлыгы системасында 1550 китапханә эшли. Аңлашыладыр, журналның мәҗбүри тиражы беренче чорда 3 мең ярым-4 мең була ала, аннары инде ул үзен пропагандалый башлый һәм аерым абунәчеләр хисабына артырга мөмкин.

Журналның, һичшиксез, «Яңа мирас» дигән өлеше дә булырга тиеш. Әйтик, ел саен Татарстанның 15 театрында гына да 60лап премьера була, сынлы сәнгатьтә дә, музыка сәнгатендә дә яңа әсәрләр туа тора. Шулар арасында, сирәк кенә булса да, шедеврлар, ягъни 10-15 елдан соң, антологиягә керерлекләре, алдагы буыннар өчен кыйммәтле мираска әвереләчәкләре дә булуы ихтимал. Ләкин андый әсәрләрнең вакыт сынавы аша үтүен көтә белергә, моның катгый критериен булдырырга кирәк. Әйтик, «Татар энциклопедиясе»нә бөтен нәрсә дә керми, чөнки аның критерийлары катгый. Соңгы елларда бу мәсьәләдә, минемчә, хәтта Тукай премиясе генә дә критерий була алмый. Ә менә, мәсәлән, С.Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә»се, И.Юзеевның «Таш диварлар авазы», Г.Әбсәләмовның «Ак чәчәкләр»е, Ә.Еникинең «Рәшә»се, «Әйтелмәгән васыять»е, Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»е, Ш.Хөсәеневнең «Әни килде»се, Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е (исемлекне, әлбәттә, дәвам итеп була) «Яңа мирас» рубрикасында бүген үк бирерлек шедеврлар.

Бу журнал безнең иҗтимагый аңыбызга, әхлакый аңыбызга тәэсир итсен дисәгез, һәр мәктәптә, һәр китапханәдә ул булырга тиеш. Моны республикабызның Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы белән генә, махсус бюджет балансына кертеп кенә гамәлгә ашырып була. Шул очракта гына журналның халыкка кирәге була. Әлбәттә, «Безнең мирас» концепциясен эшләргә кирәк. Дөресен генә әйткәндә, без бик күп нәрсәләрне белмибез. Татарның һөнәрмәнд композиторлары булмаган, әмма композиторлык эше барган. Мәсәлән, Камил Мотыйгыйлар заманында ничек барган? Менә шул ничек барганны күрсәтергә, шул гасырдан килгән мирасны халыкка җиткерергә кирәк. Бу эшләрне журнал үзе генә башкарып чыга алмый. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, Казан федераль университетының кафедралары, галимнәр белән тыгыз хезмәттәшлек иткәндә генә бу журнал кирәкле басмага әвереләчәк.

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА:

— Журнал өч юнәлештә — тарих, әдәбият һәм сәнгать тармагында мирасны кайтаруга кагылышлы материаллар бастыра. Шул ук вакытта, проблемалар да юк түгел. Иң беренче чиратта, журналга хронологик тирәнәергә кирәк. Әлегә бу тирәнәюне без тарих буенча гына күрәбез. Биредә хронологик яктан тирән тарихка төшкән мәкаләләр бар. Еш кына журнал турында Фәннәр академиясендә гуманитар булмаган галимнәр белән дә сөйләшәбез, кайчакта кайбер мәкаләләр

бәхәс чыганагы да булып ала. Аерым алганда, журналда Казан ханлыгы, Казан ханлыгы яулап алыну, күчмәннәр тарихына багышланган бик матур мәкаләләр тәрҗемә ителеп чыгарылды. Бу — бик яхшы күренеш, ләкин монда без игътибар итәргә теләгән бер фактор да күренеп тора. Төрки-татар халкы тарихы буенча архив материалларына нигезләнгән хезмәтләрнең күбесе Татарстаннан читтә языла. Тирән тарихи хезмәтләр язарлык потенциал әле Татарстанда зур түгел. Моның объектив сәбәпләре бар, чөнки Совет чорында безнең институтларыбыз Татарстан кысалары белән генә чикләнделәр, шуның өстенә гасыр ягыннан да, хронологик яктан да бик тар темалар белән генә шөгыльләнергә рөхсәт ителә иде. Архивларда утырып, тирән тарихны өйрәнә торган галимнәр әзерләү өчен күп вакыт кирәк. Татарстанда аерым фәнни эшләр язылуына да карамастан, бу өлкәдә киң масштабта эшләргә әле үзебезнең генә көчебез җитәрлек түгел. Димәк, шулай булгач, журналның урта гасырларга нисбәтле мәкаләләрне тәрҗемә итеп укучыга тәкъдим итүе бик яхшы гамәл, ләкин бу шул ук вакытта тәрҗемәчеләргә акча тотарга бу өлкәне махсус үстерергә, тәрҗемәчеләр белән хезмәттәшлек итәргә кирәк икәнлеген дә күрсәтеп тора.

Икенче яктан, «Чын мирас» журналы Татарстанда һәм республикабыздан читтә яшәүче татар, хәтта генетик яктан татарларга катнашы булган яшь галимнәрне туплаучы үзәккә әверелеп килә. Бу да бик яхшы күренеш. Димәк, журнал яңа, яшь авторлар таба һәм аларның фәнни хезмәтләрен татар укучысына тәкъдим итә.

Әдәбият бүлегендә хронологик яктан тирәнәюне без журнал редакциясе Рифкать ага Әхмәтҗанов белән хезмәттәшлек итә башлагач кына күрдек. Бу юнәлеш, һичшиксез, дәвам итәргә тиеш. Бездә урта гасырларга, ерак тарихка караган әдәби мирасны текстологик эшләүче галимнәр, күп булмаса да, бар.

Өченчесе — географик җәһәттән киңәю. Журналның, аеруча аның беренче саннарында, без Төркия галимнәренең мәкаләләрен күрдек. Бу материаллар бик киң резонанс алдылар. Монда татарларның Төркиягә күчү тарихы, татарларның гомумтөрки мәдәняткә керткән өлеше турында, без моңа кадәр белмәгән Төркия архивлары чыганаклары нигезендә, язылган мәкаләләр бастырылды. Һичшиксез, бу эшне дә дәвам итәргә кирәк, ләкин Төркия белән генә дә чикләнергә ярамый. Бүгенге көндә ТР Фәннәр академиясе, аның институтлары Румыниядәге, Ирандагы, Казахстандагы татарлар буенча фәнни проектлар башлап җибәрде. Бу проектлардан 3-5 ел эчендә зур нәтиҗәләр дә көтәбез. Әлеге нәтиҗәләрне журналда да биреп барырга кирәк, ягъни Төркиядә, Румыниядә, кайда татарлар яши, анда булган чыганаклар нигезендә язылган мәкаләләрне татар укучысына җиткерү «Мирас» журналына йөкләнә, дип уйлыйм.

Дүртенче юнәлеш — фән тарихы. Мәсәлән, бер ел чамасы элек безгә Француз Фәннәр академиясеннән зур татар галиме Һарун Таҗиев турында мәгълүмат сорап мөрәҗәгать иттеләр. Шушы кешенең тормыш юлын өйрәнү максатыннан, Фәннәр академиясе Үзбәкстан белән элемтәгә керде һәм галимнең моңа кадәр билгеле булмаган нәсел-шәҗәрәсе ачыкланды. Галим морзалар нәселеннән булып чыкты. Һарун Таҗиев — француз фәненә зур өлеш керткән һәм һәрвакыт үзен татар дип санаган шәхес. Андый затлар безнең күп. Шул исәптән, биредә яшәп, әмма онытыла барган шәхесләребезнең дә мирасы бар.

Разил ВӘЛИЕВ:

— Журналның концепциясе кирәк икәнлеген әйттеләр. Монсыз бер эшне дә башлап булмый. Журналның исеме һич кенә дә болай калырга тиеш түгел. Бу исемне аптыраганнан кушканнардыр. «Безнең мирас» — әйбәт исем бит! Журнал «Чын мирас» исеме астында кабат чыга башлагач, «Безнең мирас» исеме турында Туфан ага Миңнуллин һәм Гәрәй Рәхим белән сөйләшкәнебез дә булган иде. Икенче мәсьәлә — журналның күләме. Әгәр дә бу журналны без бик тә мәртәбәле итәргә телибез икән, аның күләмен, һичшиксез, арттырырга кирәк! Ул төсле, бизәкле, иллюстрацияләр белән чыгарга тиеш! Аны укырга гына түгел, күрсәтергә дә кирәк! Чыннан да, журнал китапханәләрдә булырга тиеш! «Чын мирас» журналы Мәдәният министрлыгы кул астындагы китапханәләргә таратыла.

Эчтәлегенә килгәндә, безнең мирасыбыз кечкенә нәрсәләрдән оешырга, авыллар тарихыннан башланырга тиеш. Анда архитектура һәйкәлләре дә булырга тиеш. Атаклы шәхесләр турында да язарга кирәк, мәшһүр династияләрне дә, борынгы әдәбиятны да бирергә кирәк. Аннары яңа табылган документлар бигрәк тә кадерле. Мин моннан дистә ел чамасы элек Кытайның бер борынгы китапханәсендә булган идем. Шунда аларның борынгы кульязмаларын саклый торган алты катлы җир астындагы китап саклагычларында булдым. Шунда төшкәч, мин татарга кагылышлы документлар бармы, дип сораган идем. Алар, бездә татарга караган чыганаклар бик күп, әмма безгә Татарстаннан килеп бу документлар белән кызыксынганнары юк, дип җавап бирделәр. Моның сәбәбе, әлбәттә, кытай телен белмәү. Менә бүген безнең университетта кытай теле өйрәтелә. Гыйззәтулла исемле кытай теле белгече хәтта Казанга күчеп тә кайтты. Әгәр дә Кытайдан килеп Казанда укучы, эшләүче татарлар белән элемтәгә керсәгез, алар акрынлап-акрынлап архивларга, китапханә фондларына кереп, татарга кагылышлы документларны өйрәнсәләр, бик тә әйбәт булыр иде. Миркасыйм ага Госманов та Иранда, Ватиканда булып, бу илләрдә татарга кагылышлы документлар булуы турында әйтте.

Аннары гел борынгылык белән генә мавыгырга димәгән. Хәзерге заман авторларыбызның да тарихка кагылышлы әсәрләре журналда басылырга тиеш. Без бүгенге көндә матди булмаган тарихи ядкярләребез турында бер закон проекты эшләргә уйлыйбыз, чөнки матди мираслар турында законнарыбыз бар, ә матди булмаганнары турында бүген Россиядә дә, Татарстанда да берни юк. Шулай итеп, матди булмаган мирасны да журналда чагылдыру бермә-бер артырга тиеш.

Тел дә — безнең матди булмаган иң зур мирасыбызның берсе. Кызганыч, телебез бүген бик нык шапшакланды, пычранды. Менә шушы мәсьәләне дә журнал игътибар үзәгенә алсын иде. Мин соңгы көннәрдә борынгы төрки тел сүзлеген өйрәнәм, анда шулкадәр матур сүзләр бар ки, аларны акрынлап хәзерге укучы да ишетергә, белергә тиештер, дип уйлыйм. Бүген әйтелгән фикерләргә колак салсак, миңа калса, журналыбыз тагын да саллырак булыр.

Фәнзилә ҖӘҮҺӘРОВА:

— Журналның концепциясе — ул аның структурасы дигән сүз. Без кирпечне өябез дә өябез — зур, калын гына журнал барлыкка килә. Журнал һәрвакыт үзенең укучы даирәсен күз алдында тотарга тиеш. Укучы даирәсен күз алдында тотмаган журнал ул — үзенең логистикасы булмаган, төрле-төрле якка тайпылган басма. «Чын мирас» журналы тышына «Әдәби-нәфис, фәнни-популяр» журнал дип язылган.

Без журналның зур өлешен фәнни басма итеп күз алдында тотабыз. Бу — журналның концепциясенә керә торган җитди мәсьәләләрнең берсе. Фәннилек белән бергә популярлык та булырга тиеш. Ни өчен журналда рәсем сәнгате тарихын да бирмәскә? Ул да — безнең мирас!

Телне саклау мәсьәләләре турында да мәкаләләр бирелергә тиеш. Шулай ук журналның рус һәм инглиз телләрендәге интернет версиясен дә эшләргә кирәктер, дип уйлыйм. Без, мирас дигәндә, татар кешесе турында гына түгел, ә татар әдәбияты, тарихы белән кызыксынучы башка кешеләр турында да уйларга тиешбез.

Алсу ШӘРИПОВА:

— Соңгы вакытта безнең министрлыкта көндәлек матбугат чаралары белән эшләү юнәлешендә Энгель Нәвап улы Фәттахов җитәкчелегендә киңәшмәләр булып узды. Редакция хезмәткәрләре дә безгә берничә тапкыр килде, журналның концепция мәсьәләсе кат-кат тикшерелде. Монда әйтелгән фикерләрнең барысы белән дә килешәм. Әлбәттә, татар телендәге матбугат чараларының мәктәп китапханәләренә яздыруның зарурлыгын аңлап, бу юнәлештә эш алып барыла. Дөрестән дә, бу эш нинди дер административ ресурсларны, бюджет мөмкинлекләрен кулланмыйча гына гамәлгә аша алмый.

Мирас белән танышуга балаларны ничек җәлеп итәргә, дигән сорауга да без җавап эзләп карадык. Аның бер юлы буларак, редакция хезмәткәрләренә министрлык уздыра торган конференцияләрдә журнал турында мәгълүмат бирергә, жюри әгъзалары сыйфатында катнашырга тәкъдим иттек. Фәнни-гамәли конференциягә тәкъдим ителгән эшләрнең иң яхшыларын журналда яктырту мәслихәт. Шулай ук укучылар өчен журналда кечкенә генә фәнни мәкаләләр конкурсы оештырылса, яхшы булыр, дип уйлыйм.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Без мирасыбыз турындагы яңа журналны Татарстанны, аның үткән тарихын яктырта, затлы кешеләр укый, чит яклардан килгән кешеләргә бүләк итә алырлык затлы басма итәргә тиеш.

Беренчедән, без журналны кем өчен чыгарабыз? Аны кемнәр укыячак? Бу концепциянең төп нигезе булырга тиеш, дип исәплим. Әгәр дә без аны галимнәр өчен генә чыгарсак һәм һәрбер мәкалә артыннан икешәр битлек искәрмә биреп барсак, ул галимнәр өчен кызык булырга мөмкин, ләкин бу мәгълүмат бик тар даирә өчен генә кирәк булачак. Әгәр дә журналны интеллигенциянең төрле катламы, укытучылар, студентлар да укый алсын дисәк, аңа бөтенләй башкача карарга кирәк булачак. Шуннан чыгып, материал да җиңел укылышлы булырга тиеш. Язучы укучыны тоеп иҗат итә. Журналның авторлары да, нигездә, язучылар булыр, алар булышыр, дип уйлыйм.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Ренат ага Харис әйткән вариант яхшыдыр, дип уйлыйм. 3000-3500 данәне министрлыклар белән дә эшләп була. Аннары, журналны популярлаштыру мәсьәләсенә карасак, төрле даирә укучыларыбыз да язылыр, дигән өмет тә бар. Сыйфатлы, тагын да зәвыклы итеп чыгару мөмкинлеген эшләсәк, кулга тотып укырлык һәм һәрбер укучы аңларлык материаллар да бирсәк, һичшиксез, журналның үз укучысы булыр. Басмабызның киләчәген матур итеп гоманлаган бер мәлдә, форсаттан файдаланып, булдыклы хезмәткәрләр туплаганы һәм журнал эшчәнлеген чын мәгънәсендә җанландырып җибәргәне өчен эллеке баш мөхәррир Илфак Мир-

за улы Ибраһимовка ихлас рәхмәтемне җиткерәм.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Татар телендә уннан артык журнал бар. Күп басмаларның җитәкчеләре — яңа, яшь редакторлар. Яшьләрнең килүе яхшы күренеш, әмма алар үткән мирасны, традицияләрне беләләрме? Яңа кеше килә дә, үткәнне белмәсә, велосипед уйлап таба башлый. Журнал мирас турында икән, тарихны яхшы итеп күрсәтергә кирәктер, дип уйлыйм. Мин журналны игътибар белән укып барам. Анда русчадан тәрҗемәләр күп. Ә нигә гасыр башында, моннан йөз ел элек чыккан «Шура» журналындагы безнең бабаларыбыз язган мәкаләләрне калкытып чыгармаска?! Мин журнал Татарстанны күрсәтә торган булырга тиеш, дип уйлыйм. Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы, дип игълан ителде. Шушы вакыйгага нисбәтле, журналны төрки халыкларга да кызыклы булырлык итеп чыгарырга тиешбез. Эшнең башы матур күренә, «ТАТМЕДИА» җитәкчеләренең дә моңа игътибар бирүе күңелгә сары май булып ята. Журнал татар халкының, Татарстанның йөзек кашы булырга тиеш. Без монда бер-беребезгә булышырга тиеш.

Ирек МИННӘХМӘТОВ:

— Бу түгәрәк өстәл — экспертлардан торган түгәрәк өстәл, дип уйлыйм. Минемчә, бүтән журналлар белән дә шулай җыелып сөйләшергә кирәктер. Бөтенебез өчен дә бу бик файдалы гамәл, чөнки без монда төрле фикерләрне, төрле тәкъдимнәрне ишетәбез, һәм без аларны тормышка ашырырга да тиешбез. Димәк, исемне үзгәртергә булдык. Тавышка куйыйкмы? Кем журнал исемен «Безнең мирас» дип үзгәртү яклы — тавышка куям.

Разил ВӘЛИЕВ:

—Үзгәртү түгел инде бу, төгәлләштерү…

Ирек МИННӘХМӘТОВ:

— Әйе, тәртипкә китерү. Кем каршы? Каршылар юк. Димәк — журналның яңа исеме — «Безнең мирас» булачак!

Фәрит ШАҺИӘХМӘТОВ:

— «Безнең мирас» журналының кыйбласы, максаты бер — бөтен дөньяга таралган мирасыбызны туплап, барлап, халыкка кайтару булсын иде. «ТАТМЕДИА»га караган 19 журнал арасында үз йөзен, үз стилен табып, ул кабатланмас урынын алсын иде.

Рамил ИСЛАМОВ:

— Без нәрсәгә карасак та, хәтергә ул иң әүвәле үзенең кыяфәте белән кереп кала. Шуңа күрә журналның бердәм кыяфәтен — дизайнын барлыкка китерергә кирәк. Һәрбер саны, хәзергечә, төрлечә чыкса, ул хәтердә калмаячак. «Шура», «Сөембикә» журналлары үз дизайннарын үзгәртмәгән.

Аннары инде бер тапкыр чыккан мәгълүм әйберләрне журналда бастырырга кирәкми. Башка җирдә чыккан икән, аны журналда кабатлап торудан мәгънә юк. Авторларның фотоларына урын бирү дә кирәкмәс, чөнки ул ике абзацлык урынны ала.

Кайбер четерекле материалларны экспертиза аша үткәрүне кирәк дип саныйм, чөнки укучыларны саташтырып, фәнни төгәлсезлеккә кертеп җибәрергә ярамый.

Фәнзилә ҖӘҮҺӘРОВА:

— Бер тапкыр басылган материалларны бирмәү дигәннән… Әйтик, Марсель абый Әхмәтҗановның тарихка мөнәсәбәтле хезмәтләре гаять кечкенә тираж белән басылалар ки, алар тар даирәдә генә тарала. Ни өчен бу хезмәтләрне популяр телдә журналда бирмәскә?! Мин, әсәр бер басмада

басылган икән, журналда бастырмаска, дигән фикерне кабул итеп бетерә алмыйм. Кайвакытта бер мәкалә махсус мәкаләләр җыентыгында басыла, кирәкле һәм кызыклы булуына карамастан, киң катлам укучыларга барып ирешми. Шул сәбәпле, аны, һичшиксез, журналга бирергә кирәк.

Фәнни экспертиза — бик җитди мәсьәләләрнең берсе. Экспертлар кемнәр була, дигән сорау шулай ук җитди, чөнки галимнәр арасында берберсенә капма-каршы фикердә булган кешеләр бар. Тарих фәне масштаблы эзләнүләрен яңа гына башлап җибәрде, дияргә була. Редколлегия каршында экспертлар составы булдырылып, аларга түләү мәсьәләсе дә каралырга тиеш. Басмага хәзерләнә торган мәкаләдәге сорауны билгеләргә генә түгел, ә аны ачыклап бетерергә дә кирәк. Бу өстәмә фәнни эзләнү эшен таләп итә. Әгәр дә без «Безнең мирас» журналын җитди журнал дип кабул итәргә телибез икән, аңа «ТАТМЕДИА»ның да мөнәсәбәте җитди булырга тиеш.

Ренат ХАРИС:

— Без мирас турында сөйләшәбез. Журналның төп өлешен мирас биләп торырга тиеш! Монда кем турындадыр сүз бармый. Фәлән проблема да, тарих та булырга тиеш түгел! Моның өчен фәнни журналлар, тарих журналлары бар. Тарихның фәлән тармаклары турында махсус басмалар бар. Журналның төп өлешен мирас тәшкил итәргә тиеш! Мирас үзе! Мираска берничә төрле караш булырга мөмкин. Ерак мирас бар. Якынрак мирас бар. Әйтик, Зариф Бәшири бар. Заманында Тукай аның турында тискәре фикер әйткән дә, без аны сызып ташладык. Ә Зариф Бәширинең «Чуваш кызы Әнисә»се — татар әдәбиятының иң гүзәл ядкярләреннән берсе. Ул «Агыйдел»дән дә, «Йөзек кашы»ннан да ким түгел. Тагын да якынрак мирас бар. 30-40 ел вакыт сынавын үткән мираслар бар. Мәсәлән, Әмирхан Еники китапларын хәзер кем дә булса сатып алып укыймы икән?! Аның иң гүзәл ядкярләре журнал сәхифәләрендә урын алырга тиеш! Димәк, журналда фәкать мирас булырга тиеш, ә нидер, нәрсәдер турында язылырга тиеш түгел!

Зиннур МАНСУРОВ:

— Мондый зур журналны чыгару гаять дәрәҗәдә катлаулы, ә катлаулылык мирас төшенчәсенә барып ялгана. Әгәр дә без гадәти генә басма чыгарсак, болай җыелышып утырмас та идек. Мирас, исеме ягыннан карасак та, җисеме ягыннан карасак та, колачлап, бәяләп бетерә алмаслык төшенчә. Үзен-үзе раслаган һәрбер халыкның да зур мирасы була. Татар үз мирасы белән башка халыклардан бик нык аерылып тора. Заманында Сибгат Хәким: «Без үзебезнең мирасыбызны таптап йөрибез», — дигән иде. Безнең мирасыбыз биниһая тау рәвешендә күзаллана: аны колачлап бетереп булмый. Без һаман да шушы тау алдында торабыз сыман. Безгә шушы мирас катламнарының өстенлекле юнәлешләрен ачыкларга кирәк. Әлбәттә, мирасның барысы да әһәмиятле, әмма шулар арасында бүгенге көн өчен әһәмиятлерәк булганнары бар. Менә шуларны безгә билгеләргә һәм шул ук вакытта төрлелекне дә күз алдында тотарга кирәк. Мирасны яктырту да төрле, яхшы мәгънәсендә чуар булырга тиеш. Татар халкы төрле кыйтгаларга чәчелгән, һәм аның мирасы да яшәгән урынында сибелеп ята. Төрле илләрдә саклана торган мирасны өйрәнү җәһәтеннән дә безгә көч куярга кирәктер, дип уйлыйм. Бу гаять дәрәҗәдә авыр эш ки, биредә чит илләрдәге вәкиллекләрне дә файдаланырга кирәктер. Безнең милли мохтариятләр, милли оешмалар бар. Аннары авторларның исемлеген бул-

дырырга, аларны яңартырга, шул исәптән, журналга төрле белгечләрне дә тартырга кирәк. Яңа белгеч үзе белән тарихның яңа катламын алып килә.

«Безнең мирас» — мирас журналы булырга тиеш. Редакциядә эшләүче һәрбер белгечнең күңелендә: «Нәрсә ул мирас?» — дигән сорау торырга тиеш. Без бүгенге заман әйберләрен дә мирас дип бирәбез, әмма аның мираска бернинди дә катнашы юк. Бу җәһәттән журнал «Казан утлары»ның да, «Мәдәни җомга»ның да бакчасына керергә тиеш түгел. Без чын мәгънәсендә мирас белән шөгыльләнергә тиешбез. Бу журнал фәкать галимнәр өчен генә чыгарга тиеш түгел. Аны киң катлау укучылар да якын күрсен. Мираска халыкны якынайту зарур. «Чын мирас» журналы кайбер китапханәләрдә бар, халык аны укый, кызыксына. Журналда укучылар соравы һәм аңа җавап, шулай ук абунәче хатлары да булырга тиеш. Болар барысы да журналның укылышын арттыра, аны халыкка якынайта. Безнең балаларыбыз тарихи темага рәсемнәр ясый. Журналның һәрбер санында балалар ясаган рәсемнәрне дә биреп барырга кирәк. Аннары һәрбер йортта гаилә ядкәре бар, һәм «Гаилә ядкәре» дигән конкурс та игълан итү мәслихәт. Нәтиҗәдә, сезгә хатлар явып кына торачак. Аннары, «Түгәрәк өстәл»ләр дә даими булырга тиеш. «Түгәрәк өстәл», шулай ук, журналны халыкка якынайтачак.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН:

— Биредә яңгыраган теләкләр, фикерләр безнең өчен бик кыйммәтле. Иң мөһиме — сөйләнгән сүзләрдән редакция коллективының да, килгән кунакларның да бер рухта, бер юнәлештә уйлый торган, милләтне кайгырта торган шәхесләр икәнлеге күренә. Утырышта яңгыраган фикерләрне тормышка ашыру юнәлешендә соңгы ике ел ярым вакыт эчендә инде азмы-күпме эш тә башкарылды. Һәр сан саен урта гасыр татар дәүләтчелеге тарихына караган бер мәкалә биреп барырга тырышабыз. Татарстаннан читтә яшәүче авторларыбыз даирәсе формалашты, чит илләрдән кайткан мираска бәйле материаллар басылып килә. Шәҗәрәләр, авыллар белән бәйле булган «Нигез» рубрикасы калыплашты. Татарның югалган авыллары турында мәкаләләр дә биреп барырга ниятебез бар. «Милли матбугат сәхифәсеннән», «Милли идея», «Милли мәгариф каһарманнары», «Фотоларда — тарих» дигән рубрикаларда да саллы мәкаләләр, чыганаклар тәкъдим ителә, даими рәвештә заманыбызның күренекле шәхесләре белән әңгәмәләр бирелә. М.Солтангалиевкә, кулъязма мирасны өйрәнү мәсьәләләренә багышланган, археография буенча, булачак бердәм тарих дәреслеге турында «түгәрәк өстәлләр» узды. Татар Казан ханлыгы тарихына багышланган, Бөтендөнья татар конгрессының бишенче съезды, «Татнефть»нең 70 еллыгы уңаеннан журналның махсус саннары дөнья күрде. Быел «Казан — төрки дөньяның 2014 елгы мәдәни башкаласы» дигән тема журналның тышлыгында һәм эчтәлегендә инде чагылыш таба. Тарихи чыганаклар, документлар, текстлар журнал сәхифәләрендә матур гына урын алды. Шулай итеп, Сез әйткән тәкъдимнәр инде өлешчә тормышка ашырылып килә. Әмма, чыннан да, еракка карау өчен концепция кирәк. Концепциянең проектын, шулай ук, фикерләшеп тикшерү мәслихәт.

Марсель ГАЛИЕВ:

—Журналның сулыш юлы кысылган. Бу бик тар. Ул бу кадәр әйберне сыйдыра алмый. Менә журналның әүвәлге саннарын тотып карагыз. Кулга бөтенләй икенче тоела.

Калын. Ә менә монысын тотып карагыз. Бөтенләй икенче. Монда бер утыз-кырык бит җитми. Ике табак бит өстәргә кирәк монда. Кая бу кадәр концепцияне сыйдырасың монда. Журналны киңәйтергә, сулышын ачарга кирәк.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА:

— Монда төп фикерләр әйтелде инде. Кулъязмалар бүлегендә иге-чиге булмаган байлык бар. Мин мирас дигәндә, беренче чиратта, әдәбият мирасын күз алдында тотам. Әдәбият мирасы — ул безнең байрак.

Зәки Вәлиди, мәсәлән, истәлекләрендә бик күп ориентировкалар биреп, үзенең архивында нинди чыганаклар булуы турында ара-тирә әйтеп бара. Мостафа Шакуловның истәлекләре дә аның архивында бар. Мостафа Шакулов — сәетләр нәселеннән, аның сеңлесе Сара Шакулова Сорбонна университетын революциягә кадәр тәмамлаган кеше. Зәки Вәлиди архивыннан татар халкы өчен кызыклы язмаларны алырга буладыр, дип уйлыйм. Зәки Вәлиди генә түгел, шул ук Рәшит Рәхмәти Аратның архивында ниләр генә юктыр, чөнки ул татар, гомумән, төрки әдәбияты тарихы буенча бик зур эш башкарган кеше. Әгъдәс Куратның, Зөбәер Кушайның, Габделбари Батталның да архивлары бай. Төркиядә бит инде күпме кеше укыды. Төрек телен бик шәп белгән кешеләр бар. Монда төрек телен генә белү җитми, ә гарәп графикасын да белергә кирәк. Төркиядә татар егетләре һәм кызлары эшли, шуңа күрә бу бик зур проблема булыр, дип уйламыйм. Андагы архивлардан татар халкына кагылышлы бик кызыклы материалларны кайтарып, шушы журналда нәшер итәргә кирәк. Зиннур Мансуров әйткән «Гаилә ядкяре» конкурсы шулай бик кызыклы нәрсә булыр иде. Бу бит, билгеле әйбергә бәйләп, кеше язмышын ачу дигән сүз.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Алга таба «Безнең мирас»та гаилә ядкяре турында да укучыларыбыз өчен бер конкурс булыр әле.

Газинур МОРАТ:

—Тарих ул милләт кешесен горур итеп тәрбияләргә тиеш. Шуңа күрә бөтен кеше борынгылык эзли, тарих эзли. Ә безнең, дөресен әйткәндә, байлык аяк астында ята. Монда Һарун Таҗиев турында фикер әйтелде. Ә андый шәхесләр бит бездә йөзләгән. Алар турында да язылырга тиеш, дип уйлыйм мин. Кыскасы, «Безнең мирас» горурлык уята торган басма булырга тиеш. Төрки дөнья турында язу да шул ук горурлыкка дәрт өсти. Кыскасы, безнең горурланырлык әйберләр хәттин ашкан!

Ләбиб ЛЕРОН:

— «Безнең мирас» — мәртәбәле журнал. Аны ничек тә яхшы итеп күрәсе, басмабызны киң даирәгә җиткерәсе килә. Хөрмәтле әфәнделәр һәм ханымнар! Бүгенге «Түгәрәк өстәл» утырышында катнашканыгыз һәм әтрафлы чыгышлар ясаганыгыз өчен барыгызга да бик зур рәхмәт. Журналның күләмен арттыру, шулай ук «Безнең мирас»ка кагылышлы башка мәсьәләләр турында без әле бергә-бергә кабат-кабат сөйләшербез, киңәшләшербез. Кабат очрашканга кадәр сау булыгыз!

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында яңгыраган чыгышларны, фикер-тәкъдимнәрне ***Марат Закир һәм Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

ТАРИХИ МИРАС

Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Яшәмәде халык хәтерсез;
Томаларга теләсә дә еллар,
Бәреп чыкты барыбер әйтер сүз.

Харрас Әюп

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ: «ГОМЕР БУЕ ВАКЫТ ҖИТМӘДЕ»

Лев Овруцкий. «Минтимер Шәймиев белән әңгәмәләр» китабыннан

– Сез бүгенге көндә сәясәттән читләштегез кебек, ләкин әле хәзер дә интервьюлар бирәсез, чыгышлар ясыйсыз...

— Инде алары да сирәгәеп бара. Хәзер мин үз-үземне чикләү халәтендә.

– Гафу итегез?..

— Әйе, нәкъ менә туры мәгънәсендә үземне чиклим. Эшчәнлек даирәсен мөмкин кадәр тарайтырга тырышам. Үз-үземә шундый максат куйдым.

– Ул максатыгыз гамәлгә ашамы соң?

— Әйе, минемчә һич зыянсыз бара. Мине тегендә чакыралар, монда чакыралар, ә мин исә әкренләп читләшү ягын карыйм. Чакыралар, кызыклы да кебек… Аннары янә бер уйлап куям да: «Юк, сез, егетләр, мине аптыратмагыз инде», — дим.

– 20-30 ел элек чакырырга кирәк булган аларга, ә хәзер – игътибарыгыз өчен рәхмәт дияргәме?

— Ә 30 ел элек бөтенләй вакытым юк иде. Гомумән, гомер буе вакыт җитмәде миңа! Нинди генә эш белән шөгыльләнсәм дә, буш вакытым булмады. Һәрчак ни дә булса эшлим, һәр эшкә тулаем бирелəм, кыскасы, һәрдаим эштә булдым мин. Мөгаен, Сезгә моны аңлау кыенрактыр, чөнки Сез — иҗат кешесе, кәеф халәтенә бәйле затлардан. Ә мин даими рәвештә, һәрвакыт проблемалар хәл иттем. Хәзер исә мин үз-үземне чикләргә, тегендә-монда йөрмәскә тырышам.

– Димәк, гомумән алганда, хәзер фәкать Болгар һәм Зөя генә калды?

— Әйе, бу проектларны мин, Ходай гомер биреп, ахырынача башкарып чыгарга ниятлим. Барып чыкса, тарихи истәлекләрне торгызу эшендә үз сүзебезне әйтәчәкбез. Мин моның белән чын-чынлап мавыктым, ихлас күңелдән әйтәм! Эш бихисап, һәрхәлдә, миңа артыгы белән җитә.

– Сез ничектер бу төзекләндерү эшләрендә прораб сыйфатында эшлим, дигән идегез.

— Әйе, прораб кебек. Минем табигатем шундый: нәрсә белән генә шөгыльләнсәм дә, асылына төшенергә тырышам. Предметны белү, темада булу, хәбәрдар булу миңа бик ошый.

– Сезнең бу эшне детальләренә кадәр белүне берәү дә таләп итә алмый лабаса. Моның өчен махсус белгечләр бар.

— Әлбәттә, белгечләр бар. Мин алар белән таныштым!

– Кемнәр хакында әйтәсез?

— Археологлар, архитекторлар, реставраторлар… Гаҗәеп кешеләр! Үз эшләренә фидакарьләрчә бирелгән затлар! Аларга менә шушы борынгы нәрсәләр генә булсын, ә калганы… икенче мәсьәлә.

– Анда, әлбәттә, чынлап мавыккан кешеләр эшли. Реставрация – ул кәсеп түгел, ул – сәнгать.

— Менә шуларга төшенә башлагач, уйлап куясың: ничә еллар

Зөя-каланың «Ат утары»нда

дәвамында хакимияттә утырасың, ә бит бу эшләрнең, бу кешеләрнең кырыйдан үтеп кенә китүе дә ихтимал иде. Болгар һәм Зөя-каланы төзекләндерү белән шөгыльләнүче буларак, бу эшнең бар әһәмиятен аңлап әйтүем. Чит илләргә баргач, тарихи истәлекләрне карыйсың, экскурсия алып баручыны авыз ачып тыңлыйсың, сокланасың. Үзебездә гаҗәеп матур табигать күренешләре, тарихи урыннар, борынгы истәлекләр азмыни? Россияне күрсәтү максатында Идел елгасын аз файдаланабыз. Бу тармакны үстерергә вакыт җитте. Инфраструктура булдырырга кирәк, Көнбатыштан да, Кытайдан да, Япониядән дә, гарәп дөньясыннан да туристлар киләчәк. Гарәпләр өчен аеруча кызыклы. Чөнки аларда гел чөллә, яшеллекне су сибеп үстерәләр, ә бездә ул үзеннән-үзе үсеп тора. Нинди урманнар, яр буйлары, нинди кыр-болыннар бездә! Таң калырлык!

Зөя утравындагы Троица чиркәве

– Ә кар? Экзотика түгелмени?

— Юк, кар-буранга алар хәзергә бик сагаеп карый. Бездә туризмның сезонлы булуы очраклы түгел. Ә менә яшел үлән, урман... Бервакыт безгә гарәп делегациясе килде, Казаннан Чаллыга киттек. Юлда барганда берничә тапкыр машинаны туктатуны үтенделәр, болында утырып торыр

Идел буе болгарларының Ислам динен рәсми төстә кабул итүләренә багышланган мозаик панно янында. Болгар. Елга вокзалындагы Болгар цивилизациясе музее.

өчен, урманның ни икәнен карар өчен. Аңлыйсызмы? Алар өчен бу гадәттән тыш күренеш. Соңыннан миңа шулай дип сөйләделәр. Без аларга барып шаккатабыз, ә алар безнең табигатькә хәйран кала. Туризм, туристлык сервисы — безнең өчен әле яңа тармак. Без моңарчы бервакытта да бу кадәр кеше кабул итмәдек, әле хезмәт күрсәтергә өйрәнә алмадык. Безгә өйрәнергә дә өйрәнергә әле.

– Туристлык тармагында «азау теше ярган» көнбатыш фирмаларны чакыруны мәгъкульрәк күрмисезме – өйрәтсеннәр безне! Бу тизрәк тә, безнең үзешчәнлектән яхшырак та булыр иде.

— Әлбәттә, алар тәҗрибәсен өйрәнергә, файдаланырга, аларны чакырырга кирәк. Ләкин мин сезгә шуны әйтәм, бездә дә бу эшнең аерым осталары бар. Мин Санкт-Петербургның 300 еллыгында булдым, Президент Путин мәҗлескә чакырды, аннан соң хәләл җефетем белән Валаамны күреп кайтырга булдык. Ул якларда булганым да, күргәнем дә юк иде. Оят инде, әлегә кадәр ни Байкалны, ни Алтайны барып күргәнем юк. Алтайга быел барачакбыз, анда форум үткәрәбез. Шулай итеп, Валаамга юл тоттык, бер матур җирдә туктадык, белештем: биредә яшь эшмәкәрләр ресторан ачып җибәргәннәр.

– А ля рус?

— Әйе, чылбырда — аюлар, рус кухнясы, мич, чуеннар, щи һәм башкалар. Төрле аракылар бик күп. Казан, татар маркалары бармы, дип сорадым.

– Таптылармы соң?

— Таптылар. Һәммәсе сатыла, рәхим ит. Аракымы, әллә самогонмы, дип сорыйлар. Самогон, дим, аны беркайчан да эчкәнем булмады. Шундук китереп бирделәр.

– Самогон эчкәнегез юк идемени?!

— Юк. Беренче тапкыр әнә шунда эчеп карадым. Хәтерлим, министр булып эшләгән чакта, аны миңа берике тапкыр алып килеп тә караганнар иде, йотып карагыз әле, дип. Кагылып та карамадым, нигәдер. Бәлки, вакыт булмагандыр?

– Теләк булса, вакыт табылыр иде...

— Эчү теләге миндә беркайчан да булмады.

– Сез Валаамга сәяхәтегезне сөйлисез, ә мин исә шундыйны ук Зөя-калада, Ат ута-

Дөньядагы иң зур басма Коръән Болгар өчен махсус эшләнде

Ак мәчет. Болгар

рында күрдем. Атлар да, затлы стильдәге рус рестораны да, тимерче алачыгы да.

— Аннары Валаамга егетләрне җибәрдем, карап-өйрәнеп кайтсыннар дип. Зөядә исә күбрәк православие һәм рус рухы булачак. Бу эшкә тотынучы кешеләр табылды инде. Шулай ук Болгарда да без Икмәк музее белән шөгыльләнәчәк кешене таптык. Ул гына да түгел, Болгарда болгар, яисә Алтын Урда акчаларын күз алдында ук чүкеп, сувенир итеп ясап бирәләр.

– Ягъни кешеләр һөнәрне эш барышында үзләштерә?

— Чынлап әйткәндә, Болгар белән Зөяне төзекләндерү эшенә тотынганда, без моны иң элек мәдәни проект дип күзаллаган идек. Әгәр дә тарихи

истәлекләр күз алдыбызда җимерелеп бара икән, димәк, без үзебезне хөрмәт итмибез. Аларны саклап калырга кирәк, югыйсә йөз яисә ике йөз елдан ни буласын күз алдына китерүе дә кыен. Болгар да, Зөя дә — тарихи калалар, икесе дә Иделнең гаҗәеп матур ярларында урнашкан. Нигә әле менә шундый сирәк мөмкинлекне тулысынча файдаланмаска? Тарихи хәтер үз чыгымнарын үзе капларга тиеш түгел, әмма туристларны җәлеп итү мөмкинлеге бар икән — бу искиткеч ләбаса.

– Бөтен дөнья шулай эшли.

— Шул турыда сөйлим дә. Югары технологияләрме, туризммы — безгә һәммәсен өйрәнергә, уртак компанияләр оештырырга кирәк. Хәрәкәт итәргә, үсәргә. Болгар һәм Зөяне төзекләндерү проектын уйлап йөргәндә без аның гаять катлаулы булачагын күзаллаган идек. Кемнеңдер теләге генә дип уйламагыз.

– Мин алай уйламыйм.

— Бу — безнең тарихи истәлекләребез һәм аларны төзекләндерергә кирәк, бу аңлашыла. Казан Кремлен яңарту тәҗрибәсе безгә зур ышаныч бирде. Шул ук вакытта без Зөянең Казан ханлыгын буйсындырган Явыз Иван шәхесе белән бәйләнгәнлеген дә аңлый идек. Ул дога кылган чиркәүне без иң кадерле ядкяр дип саныйбыз. Уйландык: бу ничек кабул ителер? Һәммәсен дә аңларга кирәк, шул исәптән халыкның моны кабул итә алмаган өлешен дә.

– Сез татар милләтчеләрен күздә тотасызмы?

— Ә сез Явыз Иванның Казанны яулап алуы миңа бик ошый дип уйлыйсызмы? Юк. Ләкин мин болай дим: бу — архитектура-мәдәният хәзинәсе, чыннан да шулай. Моңа кулы тигән төзүчеләр, рәссамнар, архитекторлар биредә кабатланмас бизәкләр калдырган. Без — кыргыйлар түгел, ә цивилизацияле халык. Шул ук вакытта безнең үзебезне дә Русьне яулап алып, өч йөзләп елга үз хакимиятләрен урнаштыручылар дип саныйлар. Русларның да үпкәләргә хакы бар…

– Буйсындырылу кемгә генә ошый икән? Чиркәүләр җимерелмәгән, салымнар аз салынган һ.б. дип тарихка соңыннан гына төзәтмәләр кертмәскә иде. Басып алуны аклау кебегрәк килеп чыга. Чынлыкта ничек булганын мин белмим, сезнең белән без белмибез, анысын инде тарихчылар ачыкласын. Әмма халыкның тарихи хәтере дигән нәрсә бар. Барысы да шунда җыелып бара. Менә, мәсәлән, Куликово кырындагы сугыш. Тарихчылар бәхәсләшә: чынлыкта булганмы соң бу яу? Ләкин ул тарихи хәтердә берничә гасыр дәвамында бөек вакыйга буларак сакланып килә. Моны берни эшләтеп тә булмый. Бу – иллюзия, хорафат.

— Тарих шулай ук иллюзияләрдән дә тора. Кеше гомере дә…

– Сугыш даталары, хәрби җиңүләр исемлеген төзегәндә аңа Куликово кырындагы сугышны да керттеләр. Гафу итегез, Урда җирләре дә хәзер Россиягә керә, нишләп Урда коралы җиңүләрен дә кертмисез? Мәскәүне яндырганнарын һәм башкаларны. Болар да данлы җиңүләр бит. Ягъни монда бик әдәпле булырга кирәк. Ике халык бәрелешкән көннән дәүләткүләм җиңү көне ясарга кирәкми, дип әйтер идем.

— Сезнең белән бу хакта сөйләшкән идек. Безнең моңа ризасызлык белдерүебез хәлиткеч әһәмияткә ия булды. Россия Президенты администрациясе турында тиешлесен әйтик: анда бу проблема белән шөгыльләнүчеләр безнең дәлилләрне аңладылар. Бу бер дә җиңел булмады.

– Дөрестән дә, моңа игътибар бирмәү тактсызлык булыр иде. Татарлар – Россия түгелмени? Алай икән, әйдәгез, Урда коралы җиңүләрен дә бәйрәм итик! Ә Кырым ханлыгы ничә мәртәбә җиңгән? Шул ук чеченнар да аларны яулап алуның 150 елы дәвамында үзләре дә берничә тапкыр җиңүгә ирешкән – моны тарихтан ничек сызып ташлыйсың?

— Без барыбыз да үзебезнең катлаулы тарихыбыз белән оешканбыз. Россия Федерациясен күздә тотып әйтүем.

– Мин бу өлкәдә белгеч түгел, Октябрь революциясе белән шөгыльләндем, сул эсерлар буенча диссертация яздым. Әмма Россия, аның нигезе – бер яктан Киев Русе, икенче яктан – Алтын Урда дигән концепция бик ышандырырлык концепция кебек тоела

Җәмигъ мәчете һәм Олы манара. Болгар

миңа. Әгәр дә Урданы алып ташласагыз, Идел буеның, Себернең һәм башкаларның каян килеп чыгуы гомумән аңлашылмый, ә болар барысы да татарлар бит.

— Татарлар гына түгел — тартарлар. Көнбатышта әле хәзергәчә күпләр безне шулай дип атый.

– Бу инде көнбатышның шулай үзенчә кабул итүе, үзенчәлекле сөйләме. Һич үпкәләп булмый.

— Зөя хакында мин күп уйландым. Йөз процент ук тәңгәл килмәсә дә, мин аны Ангела Меркельнең Җиңүнең 65 еллыгына Мәскәүгә килүе белән чагыштырам. Парад вакытында Кызыл мәйданда утырды. Аңа җиңел булмагандыр, дип уйлыйм. Үз-үзем өчен тагын бер кат нәтиҗә ясадым: нәфрәт белән яшәргә ярамый. Тарих шулай борылган, безнең өчен дә, алар өчен дә фаҗига, ләкин киләсе буынга үзеңне җиңүчеләргә карата нәфрәт сеңдереп калдырырга ярамый.

– Без бит заманында Швеция белән дә сугыштык, инде Швецияне дә гомер буе күралмаска тиешбезме? Полтава янында җиңдек тә оныттык. Французларны, төрекләрне тар-мар иттек, немецларны җиңдек. Эмоцияләр уза, узарга тиеш. Сөйләргә, бәхәсләшергә мөмкин, әмма Клас көле йөрәкне какмаска тиеш.

— Зөя һәм Болгар бу мәгънәдә күп кенә сорауларга җавап бирә. Менә ни өчен без бу ике проектны нәкъ менә берьюлы гамәлгә ашырырга булдык. Ахыр чиктә, күрәбез, никадәр рәхмәт ишетәбез. Аңлыйсызмы, бу кешеләр күңеленә хуш килә. Кабул ителә. Шуңа куанам.

– Сезнең бик яхшы сүзегез ул – «кабул ителә», мин аның мәгънәсен инде аңлыйм. Күңелегезгә яткан дигәнне аңлата.

— Чынлап та шулай. Күңелгә ятты. Ни өчен? Чөнки Болгар белән Зөя кешеләрне дулкынландырган бик күп сорауларга җавап бирә. Без аларны төзекләндерербез, болары матди чыгымнар һәм башкалар, әмма без бик күп тарихи сорауларны ачыклыйбыз, аларга җавап бирәбез.

– Рухи ихтыяҗларга.

— Рухи ихтыяҗларга, алар киләчәктә арта гына барачак.■

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ*

ЙОСЫФ АКЧУРА

МАҖАР ВАМБЕРИ [1]

Инглиз һәм госманлы бәйләнешләре турындагы әсәрләр госманлы төрекләре арасында соңрак күренә башлый. Моның беренче үрнәген көнчыгыш телләре белгече маҗар Вамберинең «Азия сәяхәтләре»ндә күреп була. Вамбери дүрт ел Истанбулда яши. Шулчакта Госманлы вәкилләренең кунакханәләрендә үткәрелгән мәҗлесләрдә була. Соңрак, 1861 елда, Азия сәфәренә китә. Дәрвиш кыяфәтенә кереп, Рәшит әфәнде исемен ала. Өч ел Урта Азия илләрендә йөри һәм Истанбулга әйләнеп кайта. Аннан ватаны Венгриягә китә, ә берникадәр вакыттан соң Англиягә күченә. Ялган дәрвиш бу сәфәрендәге фәнни тикшеренүләрен, ачышларын иң әүвәле венгрларга түгел, ә инглизләргә тәкъдим итә. Вамберигә инглизләрнең күрсәткән яхшы мөнәсәбәтләре Будапешт университетының Көнчыгыш телләре профессоры булып урнашырга ярдәм итә. Профессор Вамбери әсәрләре 1863 еллардан басыла башлый. Әсәрләренең күбесе немец телендә, кайберләре — маҗарча, ә берничәсе инглиз телендә язылган. Мәсәлән, «Бер ялган дәрвишнең Урта Азиягә сәяхәте» [2] немец, маҗар, инглиз телләрендә басылып чыга. Вамбери әсәрләренең төрек телендә тулы библиографиясен төзегән шәкерте Месарош аның турында [3]: «Көнчыгыш телләрен һәм идарә ысулларын яхшы белүе сәбәпле, Англиягә

Арминий Вамбери

олы хезмәтләр күрсәтте. Шул рәвешчә, гайрәте һәм зирәклеге аркасында зур байлык иясе дәрәҗәсенә күтәрелде. Бу байлыгы картлыгын мул, бәхетле тормыш белән тәэмин итте», — дип яза [4].

Профессор Вамбери: «Инглизләр мине сөйделәр, чөнки мин аларга, беренчеләрдән булып, Азияне таныткан идем. Алар мине тыңладылар, аңладылар. Мин хәтта король гаиләсе әгъзалары белән дус булдым, аларның илтифатларын күрдем», — ди [5]. Шул кыска мәгълүматлардан маҗар ориенталист-тюркологының Урта Азия сәяхәтенә, йә инглизләрнең тәкъдим

* Дәвамы. Башы журналның 1,2 саннарында

һәм практик заказлары буенча кузгалганлыгы, яки Урта һәм Якын Көнчыгышка кагылышлы фәнни эчтәлекле тикшеренүләрнең шул замандагы инглиз сәясәте өчен бәясе югары булачагын алдан сиземләп язганлыгы аңлашыла.

ӘЗӘРИ ТӨРКИЛӘРЕНДӘ ТӨРКИЧЕЛЕК. АХУНЗАДӘ МИРЗА ФӘТХ АЛИ [6].

Көнбатыш (Госманлы) төрекләре яңа төрек милләтчелеге фикерләрен, беренчеләрдән булып, тел фәне, тарих, сәясәт өлкәләренә кертү белән мәшгуль чакларда, Төньяк, Көнчыгыш һәм Кырым төркиләренең 1870 елларга кадәр тел, тарих, сәясәт белән бәйләнешкә кергәнлеге безгә билгеле түгел. Фәкать Кавказда яшәгән, бүген әзәриләр (азәрбайҗанлылар) дип атап йөртелә торган төркиләрнең хезмәтләрендә генә игътибар итәргә һәм өйрәнүгә лаеклы әйберләр булган. 1811 елда туып, 1878 елда вафат булган Ахунзадә Мирза Фәтх Али (Мирза Фәтх Али Ахундов) 1850-1855 елларда туган телендә, төгәлрәк әйткәндә, туган теленең җирле сөйләшендә Европа ысулында берничә комедия яза [7]. Мирза Фәтх Али 1863 елда Истанбулга килә. Ислам әлифбасын яңарту турында язган әсәрен садыре әгъзам [8] Кәчәҗизадә Фуад пашага [9] тәкъдим итә [10]. Мирза Фәтх Али әлифба ляихәсен [11] садыре әгъзамга тәкъдим итү белән генә чикләнми, ә хәреф яңарту темасына Истанбул мәгърифәтле фикер ияләре белән бу хакта сөйләшүләр, очрашулар да үткәрә. Мирзаның хәреф яңарту турында ляихә төзеп садыре әгъзамга тәкъдим иткән язмасы «Хазинәи фөнүн»нең 1864 елгы 14 нче санында басылган. Садыре әгъзам ул проектны тикшерүне «Җәмгыя-и гыйльмия-и Госмания»гә тапшыра. Җәмгыятьнең бу документны тикшергәннән соң кабул иткән карары да «Хәзинәи фөнүн»дә дөнья

Мирза Фәтх Али Ахундов

күрә. «Җәмгыят-и Гыйльмия-и Госмания» әгъзалары Мирза Фәтх Алинең (ул бу вакытта Русиянең Кавказдагы гаскәрендә хәрби хезмәттә була) үзен дә комиссиягә чакырып китергәннәр. Ул мәсьәләне өч нигезгә баглап аңлатырга керешкән: 1) Гамәлдәге ысуле әлифба яңартылуга мохтаҗмы? 2) Әгәр бу беренче ляихә кабул ителсә, тәкъдим ителгән яңа ысул эзләгән максатка тәңгәл киләме? 3) Бу пландагы исляхат фикере азагына чыгарга мөмкинме? Беренчесенә җәмгыять уңай җавап биргән. Икенчесенә карата, Фәтх Али исляхатенең фәннилек дәрәҗәсе җитәрлек түгел, дигән карарга киләләр. Өченчесе — хәреф исляхын тиешле дәрәҗәдә гамәлгә кертү кыен мәсьәлә, дигән караш белән чикләнәләр.

«Җәмгыят-и Гыйльмия-и Госмания»дә Мирза Фәтх Алинең комедияләре белән дә танышканнар. Мәкалә азагында бу хакта шундый сүзләр бар: «Язган театр хикәяләре дә тулысынча укылды. Аларда көнчыгыш өлкәләрдә таралган кайбер начар фикерләрнең

ярамаслыгы фаш ителә. Күтәрелгән мәсьәләләрне, фикерләрне һәм максатларны уку өчен файдалы булганлыктан, «Җәмгыяти гыйльмия», киләчәктә госманлы теленә тәрҗемә ителеп, тиз арада бастырып чыгарырга тырышачак. Мирза — мактауга лаеклы шәхес. Дүрт-биш көнчыгыш һәм көнбатыш телләрен белгән шәхес мәгариф тарату юлында да егетлек күрсәтеп мөһим эшләр башкара. Ватанпәрвәр, хөрмәт һәм ихтирамга лаек зат булып күренә... Әмма аның комедияләренең төрек теленә тәрҗемә ителүен белмибез». Фәтх Алинең ляихәләре, фәнни тикшерүләре һәм бу очрашулары нәтиҗәсез тәмамланган. Бу хакта Мирза Фәтх Али үзе, хатирәләрендә: «1857 елда мин гарәп хәрефләрен ислях итү турындагы фикергә килдем. Әлеге мәсьәләне тикшерер өчен Истанбулга һәм Тәһранга бармакчы булдым. Бу мәсьәләдә байтак сүз куерттык. Әмма мөселман рәисләре әлифбага кагыласы түгелләр кебек. Хәлбуки, бу мәсьәлә бик кирәкле һәм алдыбызда беренче урында торган нәрсә», — дип яза.

Ахунзадәнең әсәрләре белән таныша алмадым. Биографиясен һәм әсәрләрен тикшергән кешеләр комедияләре азәрбайҗанның гади сөйләм телендә язылган, дип раслыйлар. Алар югары катлам кешеләре, шәһәрлеләр, авыл халкы киң дәрәҗәдә аңлый алырлык телдә язылганнар. Бизәкләүләрдән ерак, саф һәм хакыйкый әзәри телен Мирза әсәрләрендә иркен файдаланган, имеш. Ул чакта Ахунзадә Мирза Фәтх Али әдәби тел мәсьәләсендә, беренчеләрдән булып, төркичелек юлына чыгучылардан була. Әмма Мирзаның төрки милләтчелеге мәсьәләсендә нинди дәрәҗәгә ирешүе һәм карашлары турында сүз әйтергә кулымда җитәрлек материал юк. Ахунзадәнең тарих, фәлсәфә, сәяси карашларында нинди дәрәҗәгә җитүе «Хаккыл якый» дигән басылмаган әсәрендә чагылдырылуы мәгълүм. Ләкин Мирзаның бу әсәрендә нинди фәнни карашларның алга сөрелгәнлеге турында берәр фикергә юлыга алганым юк. Гөкалып Зыя бәй [12] «Төрекчелек әсаслары» дигән китабында аның турында: «Исмәгыйль бәй Гаспралы [13] дәрәҗәсендә бөек төркиче югарылыгында булмаса кирәк», — дигән фараз белән чикләнә. Әмма Зыя бәй мәрхүм Мирза Фәтх Али иҗатын тиешле дәрәҗәдә махсус өйрәнмәгән. Мирза 1878 елда, солтан Габделхәмид [14] тәхеткә чыккан елларда вафат була. Зыя бәй аны Габделхәмид заманында җитешкән Гаспралы белән чагыштыра. Исмәгыйль бәйнең беренче әсәре — «Русия мөселманнары» — 1880 елда, ягъни Мирза Фәтх Али вафатыннан соң ике ел үткәч язылган [15].

«Төркиядә бу изге эшчәнлек җәелүен солтан Габделхәмид туктатырга тырышу белән мәш килгәндә, Русиядә ике бөек төркиче җитешкән. Беренчесе — мирза Фәтх Али — Европа телләренә тәрҗемә ителә», — дип яза Зыя Гөкалып. Әлбәттә, бу Ахунзадәнең комедияләре барлык Европа илләре телләренә дә тәрҗемә ителгән дигән сүз түгел. Үз хатирәләрендә Ахунзадә: «Әсәрләремнең җидесе дә рус теленә тәрҗемә ителде. Русия һәм Берлин газеталарында алар турында мәкаләләр басылды», — дип яза. Комедияләрнең һәммәсе дә рус һәм фарсы телләренә тәрҗемә ителүе бәхәссез булса да, кайберләренең тулысынча яки өлешчә французчага, инглизчәгә һәм немецчага тәрҗемә ителүе әлегә тикшерүгә мохтаҗ.

Мирза Фәтх Алинең төркичелек фикере һәм әдәбиятында иң олы гамәле — төрки телдә беренче драма әсәрләре язуында. Минем белүемә караганда, Көнбатыш (Госманлы) төрекләре арасында беренче сәхнә әсәре — Зыя пашаның Мольердан [16] тәрҗемә иткән «Тартюф»ы. Әбуззыя Тәүфикъ бәй [17] хезмәтеннән күренгәнчә, бу әсәр 1857 елда тәрҗемә ителгән булса да, басылып чыкмаган һәм һичбер җан иясенә билгеле булмаган [18].

Көнбатыш төрекләрендә беренче

оригиналь драма әсәре — Нәмыйк Кәмалның «Ватан, яхуд Селистрия» исемле драмасы. Бу әсәр 1872 елда язылган, басылып таратылган һәм сәхнәгә куелган. Мирза Фәтх Алинең югарыда искә алынган комедияләре 1850-1855 елларда язылган, 1859 елда басылган. Мирза иҗатына Мольерның яки Россия драма әсәрләре язучыларның, мәсәлән, Гогольнең [19] тәэсире булуы, драматургның алардан илһам алганлыгы бик мөмкин. Кыскасы, Мирза Фәтх Али Ахунзадә төркиләр тормышыннан алынган, гади әзәри телендә язылган беренче сәхнә әсәрләре мәйданга китергән. Аның бу эше олы хөрмәткә лаек. Шул гамәле белән ул әдәби төркичелеккә зур хезмәт күрсәткән.

Төрек теленнән ***Мәсгуд Гайнетдин*** *тәрҗемәсе*



М.Ахундовның «Пушкин үлеменә» (1837) поэмасының бер бите.

Искәрмәләр:

1. Арминий Вамбери (1832-1913) — мәшһүр венгр тюркологы һәм этнографы.
2. Китап рус теленә дә тәрҗемә ителгән: Путешествие по Средней Азии в 1863 г. А.Вамбери, с картой. — СПб., 1865.
Китап ике мәртәбә татарчага да тәрҗемә ителә: 1913 елда үлгән бер яшь галим, ә 1918 елда «эшсез калган» Ф.Кәрими белән Б.Шәрәф тәрҗемә итәләр. Ике тәрҗемә дә басма күрми. Кульъязмалары да сакланмаганга охшый.
3. Дьюла Месарош (1883-1957) — венгр тюркологы, фольклорчысы, антропологы һәм музей хезмәткәре. Галимнең 1906-1907 елларда Идел буенда чувашларның һәм татарларның фольклорын өйрәнүе мәгълүм.
4. Төрк йорты, V җилд. — Б.974.
5. Төрек йорты, V җилд. — Б.964.
6. Азәрбайҗанча тулы исеме: Mirzə Fətəli Məhəmmədtağı oğlu Axundov (Axundzadə).
7. Мирза Фәтх Алинең җиде комедиясе 1859 елда басылып таратыла. Җидесе дә, русчага тәрҗемә ителеп, Тифлис шәһәрендә басыла («Молла Ибрагим Халил, алхимик, обладатель философского камня» (1850), «Повесть о Мусье Жордане – учёном-ботанике и дервише Масталишахе, знаменитом колдуне» (1850), «Приключения везиря Ленкоранского ханства» (1851), «Медведь — победитель разбойника» (1851), «Приключение скряги» («Хаджи Кара», 1852), «Правозаступники в городе Тебризе» («Восточные адвокаты», 1855), «Обманутые звёзды» (1857)
8. Садыре әгъзам — Төркия хөкүмәтендә баш вәзир (министр).
9. Кәчәҗизадә Мәхмәд Әмин Фуад паша (1814-1869) — госманлы дәүләт эшлеклесе, язучы, олуг вәзир.
10. Йосыф Вәзирев. Азәрбайҗан әдәбиятына бер назар. — Б.47.
11. Ляихәсен — проектын
12. Мәхмәт Зыя Гөкалып (1867-1924) — төрек язучысы.
13. Исмәгыйль Гаспринский (1851-1914) — кырым татарлары җәдидчелек һәм төркичелек идеологы, җәмәгать эшлеклесе.
14. Сүз 1876-1909 елларда идарә иткән Госманлы империясе солтаны Габделхәмид III турында бара.
15. Гаспринский И. Русское мусульманство. Мысли, заметки и наблюдения. — Симферополь, 1881.
16. Жан-Батист Поклен, әдәби псевдонимы Мольер (1622-1673) — мәшһүр француз драматургы.
17. Әбүззыя Тәүфикъ бәй (1848-1912) — мөхәррир, мәгърифәтче, драматург.
18. Әбүззыя Тәүфикъ. Намунәи әдәбият-и Госмания. — Истанбул, 1330/1911-1912. — Б.261.
19. Николай Васильевич Гоголь (1809-1852) — мәшһүр рус язучысы. ■

XX гасыр тарихында дәһшәтле вакыйгаларның берсе булган рус-япон сугышы башлануга 110 ел тулды. Сугыш хәрәкәтләре төньяк-көнчыгыш Кытай (Манҗурия) белән Кореядә хакимлек итү өчен алып барылган.

ХӘТЕР ЯҢАРТУ: РУС-ЯПОН СУГЫШЫ ТАТАР ЧЫГАНАКЛАРЫНДА

РАИФ МӘРДАНОВ

Россия белән Кытай арасындагы 1897 елның март ае конвенциясе нигезендә Порт-Артур 25 елга Россиягә арендага (киләчәктә аренда вакытын озайту хокукы белән) бирелгән була. 1898 елның мартында Порт-Артур рәсми рәвештә рус хәрби флотының Тын океандагы төп базасына әверелә. Руслар кулына биргәндә шәһәрчектә 4 мең чамасы кеше яшәгән. 1901 елдан төзелеш эшләре киң җәелеп, торак һәм хәрби ныгытмалар корыла, халкы да арта. 1904 елның 1 гыйнварына анда хәрбиләрдән тыш, 51906 кеше яшәгән (шулардан 15388 рус һәм 35 мең кытайлы). Порт-Артурны ныгы-

Порт-Артур гаване. 1904 ел

тып, фортификация корылмалары төзү эшләре планы 1909 елга хәтле каралган була.

1904 елның 27 гыйнварына (яңа стиль белән 9 февральгә) каршы төндә 10 япон эсминецы, рус эскадрасына көтмәгәндә һөҗүм итеп, 2 броненосецны һәм 1 крейсерны батыра. Һөҗүмнең икенче көнендә, 28 гыйнварда (10 февральдә) Япония Россия империясенә сугыш игълан итә.

Порт-Артурда урнашкан һәм көчсезләнеп калган рус эскадрасы диңгездә сугыш хәрәкәтләре алып бармыйча, саклану тактикасына күчә. 8 мартта Порт-Артурга килгән вице-адмирал С.О.Макаров, эскадраны һөҗүмгә әзерли башлагач, «Петропавловск» броненосецында минага эләгеп, һәлак була. Флотның яңа җитәкчеләре диңгездә сугышудан баш тарта һәм хәрби диңгез көчләрен Порт-Артурны саклауга юнәлтә.

1 нче япон армиясе 1904 елның гыйнвар азагында-февраль башында диңгездән Кореяга басып керә. 22 апрельдә (5 майда) Ляодун ярымутравында Бицзыво шәһәре янында 2 нче япон армиясе Порт-Артурга бара торган тимер юлны өзә һәм 13 (26) май көнне Цзиньчжоу районында Порт-Артур ягына илтүче юлны саклаган рус отрядын чигенергә мәҗбүр итә. Порт-Артурны яулап алу өчен 3 нче япон армиясе оештырыла.

Ерак Көнчыгыштагы рус армиясенең җитәкчесе А.Н.Куропаткин изоляциядә калган Порт-Артурга генерал Штакельберг командалыгында 1 нче Себер корпусын җибәрә, ләкин корпус Вафангоу янында 1-2 (14-15) июнь көннәрендә тар-мар ителә.

Порт-Артур гарнизоны япон гаскәрләренең һөҗүмнәрен батырларча кире кагып тора. Порт-Артурдагы эскадра ике тапкыр, 10 (23) июнь һәм 28 июль (10 август) көннәрендә, уңышсыз рәвештә Владивостокка китәргә талпынып карый, ләкин Сары диңгездә япон кораблары белән бәрелештән соң, тәмам хәлсезләнеп, Порт-Артурга кайтып сыена. 1904 елның 20 декабрендә (1905 елның 2 гыйнварында) ныгытылган Квантун районы башлыгы генерал А.М.Стессель кирмәнне японнарга тапшыра. Порт-Артурны алу дошманга 3 нче армияне төп көчләргә кушарга мөмкинлек бирә.

Шахэ елгасы буенда 100 чакрым фронт булып урнашкан рус-манҗур армияләре 1905 елның гыйнвар аенда, 3 нче япон армиясе килеп җиткәнче дип, Сандепу районында һөҗүм башлыйлар һәм уңышсызлыкка очрыйлар. Япон гаскәрләре, русларны флангтан уратып үтү нияте белән, 6 (19) февральдә һөҗүмгә күчәләр. Мукден бәрелеше 25 февральгә (10 мартка) кадәр дәвам итә һәм безнең гаскәрләрнең зур җиңелүе белән тәмамлана. Зур югалтуларга дучар булган гаскәрләр Мукденнан 160 чакрым төньяктарак Сыпингай төбәгенә чигенәләр, актив сугыш хәрәкәтләре алып бармыйлар.

Рус флотының 2 нче һәм 3 нче Тын океан эскадралары, Балтыйк

Порт-Артурны саклау. 1904 ел

диңгезеннән чыгып, Африканы урап үтеп, 1905 елның 14 (27) маенда Цусима бугазына килеп керәләр һәм биредә ике көн дәвам иткән диңгез сугышында япон флоты тарафыннан тар-мар ителәләр.

Хәрби уңышларга ирешүенә карамастан, Япония сугыштан бик алҗый, зур югалтуларга дучар була. Россиядә исә беренче рус революциясе кабынып китә. Мондый шартларда ике як та солых төзү турында кайгырта башлый. АКШның Портсмут шәһәрендә 1905 елның 23 августында (5 сентябрь) солых имзалана. Аның буенча Россия Кореяны японнар йогынтысында дип таный, Квантун өлкәсенә, Порт-Артурга һәм Кытай Көнчыгыш тимер юлының көньяк өлешенә аренда хокукын, шулай ук Сахалин утравының көньяк өлешен Япониягә бирергә мәҗбүр була.

1904-1905 еллардагы әлеге сугышта татар солдатлары да күп катнашкан. Аның дәһшәте һәм афәте шулвакытта иҗат ителгән «Порт-Артур» җырында да чагылыш тапкан:

Порт-Артурга барып кергәч,
Хәйран калдым ташына;
Яңгыр кебек ядрә ява
Без мескеннең башына.
  Ай-ли, Порт-Артур,
  Була идең син матур.

Порт-Артур дигән калага
Японнар туп аталар;
Аямый дошман, аямый,
Таш каланы ваталар.
  Ай-ли, Порт-Артур,
  Була идең син матур…

Япон сугышы бәетләренең дә әллә ничә төре үз вакытында халык арасында киң таралган. Алар XX гасыр башы татар солдатларының куен дәфтәрләрендә һәм шәкерт дәфтәрләрендә сакланган. Япон явы хәлләрен тасвирлаган бәетләрнең текстлары «Татар халык иҗаты» күптомлыгының 1983 елда нәшер ителгән «Бәетләр» китабында басылган иде. Анда җиде бәет варианты бирелгән.

Япон сугышы вакыйгалары шул чор

татар укымышлыларының хатларында да теркәлеп калган [1].

Яуда катнашкан һәм япон әсирлегендә булган татарларның көндәлекләр язып барганлыгы да билгеле. Мәсәлән, шундый материалларның берсе «Чын мирас»та дөнья күргән иде [2].

Солдат көндәлекләреннән берсе 1909 елда Казандагы «Үрнәк» матбагасында китапчы Хөсәенов варислары «Япон мөхарәбәсе, яхуд Татар солдаты» исеме астында нәшер иткән 20 битлек китапчык рәвешендә басылган. Анда 1904-1905 еллардагы рус-япон сугышын башыннан ахырынача кичергән татар солдатының язмалары бирелгән. Вакыйгаларны тәфсилле теркәп, хәтта сугышның сәбәпләре һәм нәтиҗәләре турында фикер йөрткән солдат — Оренбург губернасының Орск өязе кешесе Габделхаликъ Әхмиров. Аның рус-япон сугышы турындагы елъязмасы 1905 елның октябрь аенда, әсирлектә вакытта, тәмамланган.

Китапны бастыручылар Әхмиров тексты алдына үз фикерләрен белдереп мондый тәкъдимнамә язганнар: «Порт-Артурда булган солдатлар үзләренең хәлләрен бәян кылып язган кечкенә бер дәфтәр кулыбызга керде. Шул дәфтәрдә язылганнарны бер китапчык шәкелендә нәшер итүне монасыйп күрдек. Дәфтәр Русия белән Япония сугышында рус гаскәре арасында булган мөһим вакыйгаларны бәян иткәннән соң, рус әсирләренең Япониядә булган вакытларын да бераз күрсәткән.

Бу дәфтәр солдат каләме белән ничек язылган булса — аны шул рәвешчә бастырырга карар бирдек. Мәгълүм булсын ки, безнең солдатлар арасында нинди егетләребез бар!».

Язманың авторы Габделхаликъ Әхмиров үзенең «охотниклар» командасында булуын әйткән. Патша Россиясе армиясендә 1874 елгы хәрби үзгәрешләр нигезендә, 18 яше тулган, шулай ук солдат итеп алыну вакыты кичектерелгән һәм бөтенләй азат ителгән кешеләрдән


یاپون محاربەسی
یاخود
(تاتار صالداتی).
ناشری: کتابچی حسینوف ورثەلری.
قزانده
قزانده «اورنەك» مطبعەسی.
Казань.
Электро-типографія „УРНЭК"
1909 г.

Әхмиров Г. Япон мөхарәбәсе, яхуд Татар солдаты. — Казан: Электро-тип. «Үрнәк», 1909

үз теләкләре белән хәрби хезмәткә кабул ителүчеләр «охотниклар» (ягъни, доброволецлар) дип аталган.

XX гасыр башында Оренбург шәһәрендә чыккан «Вакыт» газетасының 1906 ел 28 июнь санында дөнья күргән бер язма «Япон мөхарәбәсе...» китабында язылган мәгълүматларга аваздаш һәм берникадәр өстәмә мәгълүмат бирә. Газетада «Уфадан» исеме астында басылган ул хатның тексты түбәндәгечә.

«Порт-Артур мөхарәбәсендә әсир алынып, Япониядә Асакафу шәһәрендә тормыш (торган) Бөгелмә өязе Керкәле авылының Әхмәтҗан әфәнде Котлыәхмәт угылы Уфага кайтып керде.

Асакафу янында унбер ай торып, ошбу ел гыйнварында Германия пароходы илә Владивосток шәһәренә боз ватып килмешләр. Аннан Фәйзуллин илә бәрабәр Харбинга килмешләр.

Мөфти хәзрәт үзенә ун сум иганә акчасы бирде. Мөфти тарафыннан Япониядә булган ислам әсирләренә җибәрелгән китаплар бик соң тапшырылмыш икән.

Әхмәтҗан әфәнде японнарның әхлакларын мәдех итәдер (мактый). Һичкемгә җәбер итмиләр, тәхкыйрь кылмыйлар (мыскыл итмиләр), тәвазыйглылар (әдәплеләр), генераллары да садә йөриләр. Һәр кавемнең үзенә махсус рухани галәм куеп, дин иҗра кылырга (тотарга), укырга рөхсәт иттеләр, диядер.

Мөселман әсирләре өчен Әхмәтҗан әфәнде үзе имам булган вә укытып торган, хәтта бер хәреф язу белмәгән солдатлар укучы вә язучы булганнар. Яннарында бер генә данә Исмәгыйль әфәнденең [3] «Хуҗаи сыйбийан»ы илә Һади әфәнденең [4] «Гакаиде исламийә»се булып, шулар илә гамәлләнеп торганнар. Күп адәмгә бу берәр генә нөсхә җитешмәгән сәбәптән һәр икесен һектограф илә басып күбәйткәннәр.

Япониядә фәхеш, исраф, угрылык юк. Хатыннар бик гакыллы булып, безнең әсирләр дә яхшы торганнар. Хәтта гомерендә намаз укымаган солдатлар әсирлек вакытында бер намазаларын калдырмаганнар икән».

Бу хатта язылган Әхмәтҗан Котлыәхмәт улының исеме Әхмиров текстында да бар. Ул кешенең Самара губернасыннан булуы гына әйтеп үтелгән. Шулай ук Әхмировта телгә алынган уфалы Морадетдин Фәйзуллин исеме «Вакыт»та да әйтелгән. Әхмиров үз язмаларында япон әсирлеге вакытында Аскафур шәһәрендә булганлыкларын әйтсә, «Вакыт» газетасында ул шәһәрнең исеме «Асакафу» дип язылган. Асылда бу ике атаманы да Осака шәһәре дип фаразларга мөмкин.

Габделхаликъ Әхмиров бүтән әсирләр белән бергә Порт-Артурдан 1904 елның 27 декабрендә Япониягә китерелә. Аның көндәлеге япон әсирлегендә 1905 елның 5 октябрендә язылып туктаган. «Вакыт» газетасындагы мәгълүматка караганда, япон җирендәге әсирләр 1906 елның 1 гыйнварында гына азат ителеп, Владивостокка кайтканнар.

Мәгълүмат тулылыгы өчен шуны да искәртик, Г.Әхмиров китабының әсирлек турындагы өлеше матбугатта чыгарылган иде [5].

***

Әхмировның хатирәләре үзе өчен язылган булуын һәм матбугат өчен махсус хәзерләнмәгән, әдәби эшкәртелмәгәнлеген исәпкә алырга кирәк. Текстның җөмлә төзелешләрендәге кайбер стиль чатаклыклары шул сәбәпкә бәйле.

Китап авторы рус сүзләрен бик күп кулланып язган. Аларның күпчелеге хәрби терминнар: позиция, укрепление, бомбардировка, миноноска, судно, граница, застава, запасной, ротный командир, окоп, канонерская лодка, дюймовый, отступить һ.б. Шулай ук бераз башка төр рус сүзләре дә бар: лесопильня, окончательно, завтрак, участка һ.б. Төп тексттагы мондый рус сүзләре һәм гарәп-фарсы алынмалары, мөмкин булган урыннарда, хәзерге әдәби телебезгә күчерелеп бирелде.

Искәрмәләр:

1. Сөрген хатлары / төз. Мәрданов Р.Ф. — Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2013. — Б.4-6, 13-14, 22, 24-25. — («Татар археографиясе» сериясе; 11 нче китап).
2. Ваһапов Н. Порт-Артур кайтавазы // Чын мирас. — 2013. — №5. — Б. 44-47.
3. Исмәгыйль әфәнде — мәгърифәтче, әдип һәм журналист, нашир, җәмәгать эшлеклесе Исмәгыйль Гаспринский (1851-1914).
4. Һади әфәнде — педагог, галим, журналист һәм нашир, җәмәгать эшлеклесе Әхмәтһади Максуди (1868-1941).
5. Мәрдан Р. Сугыш һәм китап: әсирлектә дәрес укыдык // Мәгърифәт. — 2008. — 8 май.

ЯПОН СУГЫШЫ, ЯКИ ТАТАР СОЛДАТЫ

ГАБДЕЛХАЛИКЪ ӘХМИРОВ

Порт-Артур янында сугыш. 1904 ел

ПОРТ-АРТУРДА БУЛГАН ДӘҺШӘТЛЕ ВАКЫЙГАЛАРДАН БЕР ХАТИРӘ

Бу гыйбрәтле сугышның килеп чыгуына беренче сәбәп: 1895 елда Япония белән Кытай сугышы барган заманда, Аурупа дәүләтләре тыкшынып, Кытай мәмләкәтен җимереп, Пекинга кадәр барып, богдыхан[1] сарайларын талап, басып һәм йолып алып, ниһаять япон һәм Кытай сугышы тәмам булгач, безнең Русия хөкүмәте Ерак Көнчыгышка кул салып (шул җөмләдән Порт-Артурны тагын үз идарәсенә алып) бөтен Ерак Шәрыкне үзләренә каратканнар иде.

Япон-Кытай сугышы бу җәһәттән, 1877 нче елдагы Русия белән Төркия сугышына охшаган иде. Ул заманда да Русия сугышты. Англия Кыйбрисне (Кипрны) алды, Австрия, Буснә, Һәрсәкне (Босния, Герцеговинаны) алды, башкалары да файдаланды. Шуның кебек, 1895 нче елда Япония Кытайга каршы сугыш ачты, инглизләр Тибетны алдылар, руслар исә, һәртөрле ялган сылтаулар белән, Порт-Артур һәм Манҗурияне алдылар. Японнар ул заманда ваемсызлык белән яки белмәгәнгә салышып, тавыш чыгармасалар да, русларның алганын күреп, бер үч алу тиеш булуын эчләрендә сакладылар.

1898 нче елны рус адмиралы генерал Дубасов[2] Порт-Артурдан японнарны чыгарып, шәһәрне тәмам рус идарәсенә

[1] Богдыхан — Кытай императорлары Мин династиясе вәкилләренең (1368-1644) атамасы.
[2] Дубасов Фёдор Васильевич (1845-1912) — Россия империясенең хәрби-диңгез һәм дәүләт эшлеклесе, 1905 елдан — генерал-адъютант, 1906 елдан — адмирал.

алган иде. Японнар һәрникадәр риза булмадылар. Безнең Русия хөкүмәте шул көннән башлап, Порт-Артурны үз биләмәсенә алып, тәмам хәрби порт ясады. Күп миллион акча сарыф итеп, Порт-Артурны Искәндәр кирмәне кебек чыдамлы итеп корды. Японнар, бу хәлләрне күргәч, тәгаен белделәр ки, моннан соң Манҗуриядә японнарга тынычлык юк. Фәкать ул заманнарда японнар сугыш башламадылар, һәм сугышу ихтималын да һич күрсәтмәделәр. Ләкин үзләре астыртын гына хәзерләнделәр, чөнки ул заманда Япониядә диңгез куәте дә аз иде. Шуның өчен япон үз хәлен белеп, тәмам алты ел хәзерләнде.

1900 нчы елда Кытайның кораллы баш күтәрүчеләрен бастыру өчен килгән Аурупа гаскәре, Кытай эчендә булган гауга һәм тәртипсезлекләрне бетергәч кайтып китте, рус гаскәре һаман шул Манҗуриядә калды.

Японнар үзләренең хәрби куәтләрен камилләштергәннән соң, Русияне Манҗуриядән чыгарырга боердылар. Һәм үзе тәмам сугышка хәзер иде, фәкать һәртөрле дәлилләргә нигезләнсә дә, руслар Манҗуриядән чыгарга риза булмадылар. Моның өстенә, бөтен Кытай халкы Русия гаскәренең Манҗуриядән алынуын күңелләре белән теләүдә иделәр.

Шул арада руслар да тик ятмадылар, камил ашыгычлык белән Манҗурия тимер юлларын хәзерләделәр. Һәр җирдә рус шәһәрләре төзелде, һәр шәһәрдә руслар үзләренә махсус күңел ачу һәм бозыклык йортларын салдылар. Бөтен Сибирия тимер юлы Аурупадан Ерак Көнчыгышка исерткеч эчемлек ташыды. Ул арада Япониянең Русиягә каршы сугыш игълан итәчәге, рус белән япон сугышу ихтималы сөйләнә башлады. Русиянең офицерлары арасында һәр заман сугыш ихтималы сөйләнде, ләкин һич хәзерлек күрелмәде, Порт-Артурда бераз ныгытма корсалар да, заманга муафыйк түгел иде. Урыслар Манҗуриядә күп шәһәрләрне төзеделәр, ләкин хәрби хәзерлек һич юк иде. Кайбер җирләрдә комны капчыкка тутырып, шуннан хәрби ныгытмалар ясадылар.

Бервакытлар Япония Кореяга тимер юл салырга фикер итте, Русия аңа да мәйдан бирмәде, үзе Кореяда агач телә торган лесопильнялар корды. Японнар анда да русларның японнарга икмәк ашарга бирми торганын күрделәр. Русларның, хәлләреннән килсә, икенче кешегә кояш нурыннан файдаланырга да юл бирмәячәкләрен бик яхшы белделәр. 1903 нче ел августта японнар Корея мәмләкәтенә гаскәрләрен чыгара башладылар. Күп вакыт үтмәде, Русиянең Кореяда булган лесопильняләрен японнар утка яктылар, ничә миллионнар әрәм булды. Шуннан соң сугыш булачагы катгый мәгълүм булды. Ләкин ни заманда башланачагы мәгълүм түгел иде. Русия гаскәре арасында да бу сүз күбәя башлады. Рус гаскәренең бер өлешен Кореяга таба чыгардылар.

1904 нче елны 27 нче гыйнварда төнге сәгать унбердә, безнең офицерларыбыз һәммәсе генераллар белән бергә җыелышларда иделәр, японнар Порт-Артурга диңгездән килеп, безнең гаваньда[3] торган судноларыбызны — ике броненосны бомбага тотып, мина белән ваттырып киттеләр.

Икенче көнне безнең флотыбыз да күзен ачкан иде. Көндез сәгать уннарда тагын кырык минут микъдары ике тарафтан бомбалау булды, японнарның ике судволары ватылып кайтып киттеләр. Японнарның хәле безгә мәгълүм түгел. Әмма Порт-Артурда булган русларның хәле мөшкел иде. Руслар Порт-Артурда алты ел утырганнар, бер төндә ике судно эштән чыккач

[3] Гавань — суднолар якорь салып тора торган һәм төяү-бушату, пассажирлар утырту өчен уңайлы булган порт акваториясе.

белделәр: боларны төзәтергә урын юк, төзекләндерү верфе юк, Кара тарафында да крепостьлар юк, орудие, тау туплары, кыр туплары да бик аз иде.

27 нче гыйнварда сугыш тәмам башланды. Ләкин бездә хәзерлек һич юк, булса да бик аз иде. Хәтта наместник Алексеев[4], японнар безнең ике судноны батканнан соң, верфьләр ясарга кушты. Шуннан соң крепостьлар төзәтә башладылар, үзләре шулвакыт: «Инша Аллаһ, өч елдан тәмам булыр», — дип көләләр иде. 28 нче гыйнварда безнең Манҗурда булган солдатларны җыярга олуг манифест булып, Манҗур һәм Амур гаскәрен туплады-лар, кайберләрен Порт-Артурга һәм кайсыларын Корея чигенә җибәрделәр.

Сугыша башлаганда безнең гаскәребез дә бик аз иде, шулай булса да, каршы тордык, японнарның әүвәл һөҗүмнәре һәм куәтләрен сарыф кылган җирләре Порт-Артур икәнен күрә торып, бездә булган дүрт полк гаскәрне, Корея чигенә җибәрделәр. Шул сәбәптән Порт-Артурда куәт бигрәк тә аз калды.

Арасы озак булмады, Русиядән һәм һәр тарафтан гаскәр дә килде, батареялар да килде, безгә кирәкле булган куәт Порт-Артурга килде.

12 нче февральдә диңгездә бик шәп сугыш булды, төне буе шәһәргә һәм крепостька аттылар да, таң алдыннан качтылар. Иртәгәсе көнне шәһәргә якын килмәделәр, әмма безнең судноар диңгезгә чыктылар, диңгездә бик куәтле бомбардировка бөтен көн дәвам итте, тик һичбер тарафтан һәлак булучылар мәгълүм булмады. Безнең судноар да исән кайттылар. 27 нче февральдә тагын диңгездә бомбалау тавышы ишетелде, безнең миноноскалардан икесе япон судноларына очрап, шулар икесе дә батты. Икенче көнне сәгать сигезләрдә шәһәргә ата башладылар, икенче тарафтан гаваньга аталар, шәһәрдә бик күп йортлар җимерелде һәм «Ретвизан»[5] өстенә 12 дюймлы бомба төшеп, ике матрос үлде, 18 кеше авыр җәрәхәтле булды, шәһәргә дә бик күп зыян итте.

Аннан соң шәһәр тирәсендә әйтерлек сугыш булмады, башка тарафларда ни булганы безгә мәгълүм түгел, ләкин офицерларыбыз һәр заман бик кайгылы, бик куркып йөриләр.

31 нче мартта диңгез эчендә Порт-Артурдан сиксән чакрым җирдә сугыш булды, шулкадәр арадан гөрләп көне буе туп тавышы килеп торды. Шул көнне безнең адмирал Макаров[6] «Петропавел» броненосы эчендә сигез йөз илле гаскәри белән һәлак булды. Шул заманда әҗәлләре җитешмәгән илле матрос йөзеп, исән килеш кырга чыктылар. «Петропавел», Макаров — һәр икесе һәлак булгач, безнең гаскәрнең һәммәсе җанынннан өметен кисте, шул көннән башлап һәркемнең төсендә яшәү әсәре калмады, шуннан соң көлеп сөйләүче булмады, гаскәриләрнең һәммәсен кайгы-хәсрәт басты. Моннан соң безнең судноар диңгезгә һич чыкмадылар, һәммәсен курку басты, мөселман солдатлары һәркөн бер-берсе белән бәхилләшеп, иман кәлимәләрен кабатлап йөрделәр. Кайбер надан солдатлар бар иде, бездән сорыйлар: «Монда вафат булсак, мөселманлыгыбыз ничек булыр икән?» — диләр.

Шуннан соң японнар диңгез тарафында бик иркенләп йөрделәр, безнекеләрдән диңгезгә чыгучы булмады.

22 нче апрельдә японнар Порт-Артур тарафына корыга гаскәр чыгара башладылар, Порт-Артурның артыннан йөз ча-

[4] Алексеев Евгений Иванович (1843-1917) — Россия империясенең хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, 1903 елдан адмирал. Россиянең Ерак Көнчыгыш провинциясе наместнигы, Порт-Артурдагы һәм Манҗуриядәге рус гаскәрләренең җитәкчесе.

[5] «Ретвизан» — рус броненосецының исеме.

[6] Макаров Степан Осипович (1849-1904) — Россия империясенең хәрби-диңгез эшлеклесе, вице-адмирал. Рус-Япон сугышы башлангач, Тын океан флоты җитәкчесе итеп билгеләнә, Порт-Артурга 8 мартта килә, кирмәнне саклауда корабльләр белән идарә итә.

крым җирдән, безнең Порт-Артурда булганнарны кисеп алды, безнең гаскәрнең бөтенесе ике мең булыр: матрос, пехота батареясе — һәммәбез Порт-Артурда калдык, тылыбыз киселде.

Аннан соң безнең гаскәр Кинҗао[7] каласының артында крепостьлар төзеп, Кинҗао тавында сугышырга хәзерләндек. Крепостька җитмештән артыграк туп куелган иде, бишенче полк гаскәр шунда иде, һәм безнең дүртенче дивизиянең охотниклары шунда иде. 13 нче, 14 нче, 15 нче полклар артта иде. Тилнуан крепостьларында һәм Тилнуан ягыннан диңгез ярында дүртенче Запас батальоннар һәр көн заставада иделәр. Шулай ничә көннәр, ничә төннәр көттек — сугыш булмады.

3 нче майда Самсун тавының артында аз гына сугыш булды; 13 нче, 14 нче һәм бишенче полклар Кинҗаодан дүрт чакрым микъдары чыгып сугыштылар.

Шул көнне 14 нче полктан җитмеш кадәр яралы булды, унберенче ротаның командиры югалды. Бишенче полктан алтмыш яралы булып, алтынчы ротаның командиры һәлак булды. Дүртенче батареядан яралылар бик күп булды. Соңра безнең гаскәр Кинҗаога кайтты, Кинҗао артында охотниклар арасында аз гына сугыш булды.

13 нче майда Кинҗао крепостендә бик көчле, дәһшәтле сугыш булды, японнар Кинҗао каршысына йөз егерме дүрт орудие куйганнар, һәм сулагай яктан диңгездән канонер көймәсе[8] белән килеп ата башладылар, арттан миноноскалар белән килеп зур тупларны җибәрәләр. Сәгать унга кадәр безнең крепостьта булган тупларның һәммәсен ватып бетерделәр, безнең гаскәргә Кинҗаода һич каршы торыр хәл калмады. Карадан йөз егерме дүрт орудие белән һичтуктаусыз бомбардировать иттеләр, күзләр һичнәрсә күрмәс булды. Бөтен дөнья гөрләп, дерелдәп торды: шрапнельләр[9], һәртөрле гранаталар[10] акылларны хәйран итә торган һөнәр һәм сәнгатьләр иде.

Адәм баласы шрапнельләр, гранатларның һавада ярылганын күрсә, һичшиксез, кыямәт хәлләрен искә алыр иде. Шулай көнозын сугыш-кырылыш дәвам итте. Кич сәгать сигезләрдә, японнар Кинҗаоны да басып алдылар. Кинҗао да безнең кулдан китте. Һәлак булган сугышчыларыбызны да алырга мөмкин булмады. Безнең тарафтан меңгә якын һәлак булды, диләр. Дөресен Аллаһ белер. Японнар шул көнне алты мең һәлак булганнар.

Кинҗаодан соң бер ай сугыш булмады, безнең гаскәр Артур тарафына кайтып, Артурдан егерме чакрым ераклыкта, бик биек тауларда: Ипилаз, Койнсан, Зелёный тауларында окоплар казып, японнарның киләчәкләрен көттек. Ничә көннәрдән соң японнар кабат күренә башладылар.

13 нче июньдә японнар тагын һөҗүм итә башлады, бер-ике таудан безнең позицияләрне алдылар. Һәр хәрәкәт булганда, гомумән, рус гаскәре арасында солдатлар никадәр гайрәт күрсәтсәләр дә, офицерларның йомшаклыгы күренә иде.

Аннан соң 20 нче, 21 нче июньдә безнең гаскәр бер гайрәт белән япон өстенә һөҗүм итеп, 13 нче июньдә калдырган үз позицияләребезне кире алдык. Өч көндә өч меңнән артык сугышчыбыз һәлак булды. Аннан соң кабат сугыш булмады. Без тагын крепостьларны ныгыттык, Артурдан унбер чакрым җирдә кабат окоплар казып, тагын позиция ясадык. Ләкин безнең гаскәребездә шулвакытта җан әсәре калмаган иде. Японнар исә бик лаф

[7] Кинҗао — Кинжоу (Цзиньчжоу шәһәре).

[8] Канонер көймәсе — зур калибрлы бер, ике, өч кораллы ишкәкле яки пар судносы.

[9] Шрапнель — кирмәндәге дошман сугышчыларын юк итү өчен эшләнгән артиллерия ядрәсенең бер төре.

[10] Граната — кыр тубы ядрәсе.



оралар, безнең гаскәр арасында төрле язулар таралды: «Артурга окончательно һөҗүм кылып алабыз, иртәгә сезгә завтракка барабыз, безнең килүгә мунча ягып куегыз» дигән язулар таралды. Безнең рус гаскәре үз-үзеннән курка торган булды.

13 нче июльдә япон гаскәре тагын һөҗүмгә башлады. 14 нче, 15 нче июльдә туктаусыз батарея белән җәһәннәм утын яудырдылар: Ипилаз белән Койнсанның һәр икесен япон басып алды, яралыларның, һәлак булучыларның хисабын Аллаһ белсен.

Без тагын икенче җирдә позиция тоттык, японнар тагын һөҗүм иттеләр, 17 нче июльдә япон гаскәре кара болыт кебек басты, каршы торырга хәл калмады. Иртә белән караңгы таңда һөҗүм итәргә башлаганнар иде, көндез сәгать унберләрдә кабат безнең позицияне яулап алдылар. 13 нче, 14 нче полклардан гаскәрләр позициядә калдылар. Яралы һәм һәлак булучылар бик күп булды, япон кулында әсирләр дә күп китте.

Моннан соң безнең сугышчыларның кайберләре крепостька кайттылар һәм кайсылары Тугушань[11] тавына бардылар. Дүртенче запас батальон Тугушаньның уң тарафында окоплар казып, японнарның һөҗүмен көтәләр иде. Шул көнне Япониянең атлы

[11] Тугушань — Порт-Артурдан 4,5 чакрымдагы бу тауда саклану фортының чиге узган. Әлеге тау «Дагушань» дип тә йөртелгән.

гаскәре һөҗүмгә килгәндә фугаска[12] очрап, бик күп һәлак булып, һөҗүм итмичә, кире киттеләр.

24 нче июльдә Запас батальоннан 16 нчы полкның өченче батальоны алыштырылып, Запас батальон шәһәргә кайтты. Шул заманнарда солдат арасында һич исән калырбыз, дип әйтерлек өмет юк иде.

26 нчы июльдә япон гаскәре Тугушаньга һөҗүм итте, бу һөҗүм дә бик көчле иде. 27 нче июльдә дә диңгездән окопларга аттылар, хисапсыз сугышчыны һәлак иттеләр: кайбер ротадан 35 солдат һәм кайберләрендә кырык кына солдат калды.

Япон гаскәре дә, ничә җирдә фугасларга туры килеп, бик күп һәлак булдылар. Пулемёт һәм туплар белән дә күп һәлак иттек, япон гаскәреннән дә ун мең кадәр гаскәри һәлак булуын сөйләделәр.

Безнең калган гаскәребез һәммәсе Тугушаньнан шәһәргә кайттылар, шулвакыт тәмам кырык ике мең гаскәриебез калган иде. Аннан соң беренче августта, Порт-Артурны өч көндә алабыз дип, бик каты һөҗүм иттеләр. Бу һөҗүм һич туктаусыз 8 нче августка кадәр дәвам итте, безнең гаскәребезнең яртысы яралы булды. Һәлак булучылар өч меңнән артык иде. Крепость туплары җиде йөздән артык иде, осадный туплар, кыр туплары 172 иде. Безнең судноларыбыздан да аттылар. Японнар моңа каршы алты йөздән артык туп куйдылар, ләкин японнарның осадный туплары аз иде. Күбрәге кыр тубы иде.

Бездә тау аша ата торган мортиралар[13] бар иде, 9 дюймлы, унынчы дюймлы, 6 дюймлы туплар бар иде. Судноларда 22 потлы 12 дюймлы туплар бар иде. Күп бомбалар, гаҗәеп 18 потлы бомбалар бар иде. Болар атылган заманнарда җирләр селкенеп, дөньялар гөрләп тора иде. Бөтен дөньяда һичбер вакытта моның кебек сугыш булган юк, диләр иде.

Японнар безнең шактый позициябезне алдылар һәм сул тарафтан тагын бер тауны алдылар. Японнарның яралылары-вафатлары илле мең кадәр булды, диләр. Бездән яралы-вафатлар унбиш мең булды. Моннан соң тәмам бер ай сугыш кылмыйча тордык, японнар да һөҗүм итмәделәр. Безнең кайбер җиңел яралыларыбыз төзәлеп чыкты, окоплар казып, тупларны күбәйтеп, бераз куәт алдык. Японнар да яхшы гына хәзерләнделәр.

28 нче августта, безнең судноларга Владивостокка китәргә әмер булды, шул заман безнең судноләр Владивостокка китәргә чыкканда, японнар каршы килеп, бик зур сугыш булды. Бу юлы диңгездә булган сугыш гаять дәһшәтле иде, эскадра командиры шул сугышта һәлак булды, шуннан соң безнең судноләр таралып качтылар. Кайберләре Порт-Артурга кайтты һәм кайберләре Кытай суларына качты, кайсылары кайда җан коткарырга мөмкин — шунда качтылар.

Бу судноларны чыгарудан асыл максатлары, судноларны коткарып, Владивосток лиманына[14] җибәреп, Порт-Артурны Япониягә тапшыру иде. Бу да уйлаганнарынча барып чыкмады.

Аннан соң Порт-Артурга кайткан судноларның туп һәм коралларын алып, тауларга, крепостьларга куйдылар. Шуның белән безнең тау тупларыбыз мең ике йөз кадәр булды. Кайбер яралы гаскәриләр дә сәламәтләнеп, мәйданга чыктылар, шуның белән безнең Карада булган куәтебез тагын бераз артты.

6 нчы сентябрьдә японнар гаскәрен хәзерләп, кабат һөҗүм итәргә башлады. Яңадан дүрт көн туктаусыз һөҗүм иттеләр. Шул арада бер тауны алып,

---

[12] *Фугас — гаять куәтле бер дары, аны гаскәрнең килә торган җиренә, юлга күмәләр. Дошман, белмичә, шуңа туры килсә, ул ярылып адәмне тузан кебек очыра, никадәр генә гаскәри булсын — фугаска туры килсә, калу юк. — Г.Әхмиров искәрмәсе.*

[13] Мортира — кыска көпшәле туп.

[14] Лиман — тирән булмаган, сай диңгез култыгы.

безнең окопларга япон гаскәре керде. Фәкать япон гаскәре аз булганлыктан, окопларга ятканнар. Шул чакта безнекеләр бомба, мина ташлап, бөтен япон гаскәрен һәлак иттеләр. Бу тауга һөҗүм заманыннан башлап, шул безнең миналар белән янып һәлак кылганнарыбыз унсигез мең микъдары булды диделәр. Бу тауда булган утны Ходай күрсәтмәсен, бөтен япон гаскәре янып бетте. Японнар бик зур һәлакәт белән кире кайттылар. Безнең гаскәрдә бу юлы югалтулар күп булмады. Японнар да моннан соң тиз һөҗүм итмәделәр, без дә үзебезгә окоплар казып, яхшы позицияләр алдык.

Японнар да хәзерләнүне дәвам иттеләр, бик зур мортиралар утырта башладылар. Ундүрт мортир утырттылар. Һәркөн мортир белән шәһәргә һәм крепостька аттылар. Без һәр җәһәттән зәгыйфь булдык: снаряд аз калды, гаскәр эченә хасталык керде, ашарга ит-май калмады, һәрнәрсәне сатып алырга булды. Итнең кадагы[15] — алтмыш-җитмеш тиен, ул да булса ишәк ите, суган — кадагы дүрт сум, сарымсак — бер данәсе 25 тиен булып, гаскәр арасында цинга[16] — ачлыктан хасталык килеп чыкты. Солдатның аяк атлап йөрергә хәле калмады, шул хәл белән бик зәгыйфь, чак җаны бар, шул хәлдә позициядә торалар. Японнар шул вакытларда туры штык белән керсәләр, кул күтәреп каршы торыр кеше берәү дә юк дәрәҗәсендә иде.

7 нче октябрьдә японнар 3 нче порт белән 3 нче укреплениенең каршысында һөҗүм итеп, безнең бер-ике окопны алдылар. 16 нчы полкның икенче батальоны кабат бетте. (Ул Тугушаньда беткән ике йөз илле солдаттан 38-40 кеше калган иде.) Бу юлы кайбер ротадан сигез кеше һәм кайберләреннән ун кеше калды. Японнар бик зур туплар белән атып, һәммә окопларны һәлак иттеләр. Шулай итеп, октябрь эчендә бик күп һөҗүмнәр булды, хисапсыз гаскәрине һәлак иттеләр. Шулай булса да, позициядә безнең гаскәр дә яхшы тырышты. Әмма зәгыйфьлек соң чигенә җитте, һәр җәһәттән эшебез мөшкелгә калды: ашарга да юк, атарга да юк, хасталар көннән-көнгә арта, хастаханәләр тулды, японнар һаман мортир белән аталар, урамга чыгып йөрер хәл юк, күрсәләр һаман аталар, соңра солдатларның тешләре шешә башлады, ашарга да мөмкин түгел, йөрергә хәл юк, хастаханәләр кабул кылмый, урын юк, диләр. Башка җир юк, хасталарны ары-бире урамда ике-өч көн йөртәләр, ниһаять, вафат булалар. Җирләргә кеше юк. Җеназа юк, иман бармы-юкмы — Ходай белсен!

8 нче ноябрьдә японнар кабат һөҗүмгә башладылар. Икенче портка һәр тарафтан һөҗүм иттеләр, дәһшәтле сугыш булып, безнекеләр дә соң көчләрен салып тырыштылар, японнарның һөҗүм кылган гаскәреннән тере калучы бик аз булды, һәр тарафта, кырчын ташы (комташ) кебек, себерелеп ятып кала торганнар иде. Безнең дә полкларда солдат бик аз калды, һәммә сугышыбыз кул бомбасына калды, башка зур корал калмады, мина, пулемёт, мылтык калды. Бомбаны үзебезнең иске тупларның снарядыннан ясап бирделәр. Японнар якын килә башласалар, шуны ташлыйбыз. Бер ротага берне ташлаганда, яхшы туры килсә — һәммәсен һәлак кыла.

Пулемёт шундый нәрсә, пуляны насостан су сипкән кебек сиптерә, бер адәмгә бер җиргә әллә ничә пуля керә, һәр минутта дүрт йөз илле пуля ата. Японнар шулкадәр һөҗүм итәләр — һичтуктаусыз, ял итәргә бирмиләр. Көне-төне тырышалар: көндезләрен бөтен көн туп белән атып, безнең окопларны ваталар, төн булгач, үз тарафларында окоплар ясыйлар. Без дә бөтен төн японнар көндез ваткан окоп-

[15] Кадак — 409,5 граммга тәңгәл килә торган авырлык үлчәү берәмлеге.
[16] Цинга — С витамины җитмәүдән була торган авыру.

ларны төзәтәбез. Безгә дә тынычлык юк, җаныбызны кулда тоткан кебек тотабыз. Төнлә булса — капчыкларга ком тутырып, ватылган окопларны төзәтәбез, иртә белән ничек якты була башлады — японнар ватарга тотыналар, бөтен көн атып туздыралар. Ниһаять, төн-көн рәхәтлек булмагач, безнең солдатларда хасталык, ачлык башланды, һәммә хастаханәләр тулды, гаскәребез азайды, окоп ясарга капчыклар калмады. Аннан соң материя һәм һәртөрле мануфактурный маллардан (сәүдәгәрләрнең ташлап чыккан малыннан) капчык тегеп, шуларга ком тутырып окоп ясадык.

Шундый заманнар буладыр иде, адәм баласы җаныннан бизеп, бераз вакыт алданрак вафат итсәм, рәхәттә булыр идем, бу михнәтләрне күрмәс идем дип, үлемне тели иде.

13 нче ноябрьдә 3 нче порт белән 3 нче укреплениегә японнар һөҗүм иттеләр, бу һөҗүм дә гаять дәһшәтле һөҗүм иде. Һәм курганлы батареяга бик зур куәт белән бөтен көн караңгы булганчы һөҗүм иттеләр. Ләкин һичбер җирне басып алырга ирешмәделәр.

14 нче ноябрьдә биек бер тауга һөҗүм итә башладылар. Монда тоташтан туктаусыз унбер тәүлек сугыш булды. Безнең генералларыбыз бу сугышта шулкадәр инсафсызлык кылдылар, һичбер вөҗдан моны кабул итмәс иде: һәммә хастаханәләрдә булган яралы һәм хасталарның һәммәсен бу тауның башына алып бардылар. Күбесенең йөрергә хәлләре юк, бер кулында мылтык, бер кулында таяк, таяна-таяна баралар һәм кайберләрен арбага төяп алып баралар, һәммә хасталарны, һәммә хастаханә хезмәтчеләрен, шул тауда сигез мең гаскәрине, һичшөбһәсез, барысын кырдырдылар. Бичара, мескен солдатның бармаска ихтыяры юк, теләр-теләмәс, әманәт җанын үз кулы белән итеп, японнарга тапшырудан башка чарасы юк. Бу сугышта бездән яралы булып кайткан адәм бик аз иде, һәм һичбер сугышта бу унбер тәүлектә һәлак булган кадәр югалтуларыбыз булганы юк иде.

Һич шөбһәсез, японнар безгә караганда ике тапкыр артык һәлак булганнар. 24 нче ноябрьдә японнар шул биек тауны алдылар, һәртөрле зур тупларны шул тауның башына кордылар. Японнар өчен иң мөһим нокта яулап алынды димәк ки.

Безнең сугышчыларның сәламәт калганы бик аз иде. Аларның да күбесе икешәр мәртәбә, өчәр мәртәбә яралы булган гаскәриләр иде һәм кайберләре ачлыктан цинга хасталыгына төшкән. Сәламәт булган солдатларда да җан һәм яшәү әсәре калмаган иде. Ашарга юк, эчәргә юк, акчага бернәрсә табып булмый. Һичбер адәмгә крепостьтан чыгып күренергә хәл юк — японнар биек тауның башыннан мортир белән яудыралар, кая барсаң да, биек таудан күрәләр дә аталар. Әллә ничә көннәр бер җирдә камалып тордык, гаскәребез үз-үзеннән бетә башлады, цинга хасталыгыннан үләләр.

Бик зур зәхмәт һәм мәшәкать белән ноябрь ае үтте. Беренче декабрь дигән заманда японнар тагын мортир белән бомбалый башладылар. Тупның тавышына да түзү мөмкин түгел иде. Бер тарафтан гаваньга аталар — безнең гаваньда булган судноларыбыз бата башлады, бер тарафтан складларга аталар — складлар яна башлады. Шул дәрәҗәдә дәһшәт булды — адәм һәр секундта җаныннан өмет кисеп, «нәфси, нәфси![17]» диюдән башка чара калмады. Хәтта шул дәрәҗәгә барды — безнең гаскәрдә үзара мәрхәмәт калмады: солдатның һәрбере бер кашкыр (дала бүресе) кебек булды, һәммә солдатлар бере-икенчесенә палач булды, адәмдә төс калмады — саргайды. Адәмнәрнең һәрбере берәр вәхши хайван кебек булдылар. Унбер ай кан эчендә, бигрәк

[17] «Нәфси-нәфси!» — «Үзем, үзем!». Автор сугыш дәһшәтен кыямәт белән чагыштыра, ягъни һәркем бу көндә үзе өчен генә куркыр.

тә, бу соң вакытларда ачлыкның әсәре һәр нәрсәдән артык иде. Ит юк, атнасына бер мәртәбә өч солдатка бер банка консерва бирәләр иде, соңыннан ул да калмады. Ишәк, ат үлсә — җаны чыкмастан, солдат ашый башлый иде. Бер заманнар Кытайның ишәккә ашата торган борчагын ашадык.

Кайбер вакыт кытайлар һәртөрле колбасалар китереп саттылар. Хәтта эт итеннән ясалган колбаса — кадагы бер сум егерме тиен булды. Ишәк ите, ат ите — бер сум илле тиен, тавык — унике сум, бүдәнә — бер сум егерме тиен, каз — утыз биш сум. Ак күмәчнең чирек кадагы — егерме биш тиен, аракының шешәсе — 3-5 сум. Солдатка аракы эчәргә рөхсәт юк иде. Суган-сарымсак кебек нәрсәләр һич булмады. Бер адәмгә бер ашар өчен сигез сум-ун сум акча кирәк иде.

Шул хәл белән байтак вакытлар тордык, һичбер тарафтан хәбәр юк иде һәм хәбәр килергә мөмкин дә түгел. Шулай булса да, үзебезгә генераллар һәркөн «ике-өч көннән Куропаткин[18] отряды килә», диләр иде. Күпме вакытлар, балалар кебек, шуңа ышанып йөрдек. Аннан соң берзаманнар «Балтыйк диңгезенең эскадрасы килә», дип сөйли башладылар. Ул заманнарда өмет белән алдандык, аннары һич ышанмый торган булдык.

Японнар һаман мортирны яудыралар, безнең крепостьларда булган тупларны ватып бетерделәр: портларда җан саклар җир калмый башлады. Японнар безгә шулкадәр якын килделәр — окопларда сөйләшкән тавышлары безгә ишетелә иде. Шулкадәр бер җирдә ике ай кадәр яттык. Безнең гаскәрдә һичнәрсә юк, чыкмаган җан гына бар иде. Шулай булса да, безнең хәлне белмәгәч, японнар штыкка килергә куркалар иде. Безнекеләр бер батальон гаскәрдән бер рота ясадылар, ротада солдат бик аз иде. 17 нче декабрьдә японнар җир астыннан казып килеп, безнең 3 нче укреплениене ваттырдылар. Анда безнең йөз илледән артыграк сугышчы бар иде, кайберләре һәлак булды һәм кайберләре японнарга әсир булдылар.

19 нчы декабрьдә тагын җир астыннан килеп бер портны ваттылар, безнекеләр бу портны ташлап кайттылар, инде безнең гаскәрнең хәле өметсез булды. Безнең гаскәр 20 нче декабрьдә Кытай стенасыннан[19] да чигенделәр.

Безнең генераллар да, барлык солдатлар да җаннарыннан бизделәр, һич өмет кылырга юл калмады. 21 нче декабрьдә үз арада мәслихәт һәм киңәш кылып, Порт-Артурны японнарга бирергә карар бирделәр. Безнең сәламәт гаскәриләребез барлыгы дүрт мең биш йөз калган иде. Барлык җанлы гаскәр егерме биш мең кеше иде[20].

22 нче декабрьдә Порт-Артурны японнарга тапшыру өчен ак флаг күтәрделәр, җаны сәламәт булган гаскәриләр һәммәсе шатланды. Японнар килеп, солых һәм капитуляция кәгазьләрен хәзерләп, рәсми рәвештә Порт-Артурны алдылар. Һәммә складларда никадәр әсбап һәм калган нәрсәләрне һәммәсен дәфтәргә берәмберәм язып алдылар. Безне ашатып-эчертеп, сәламәт булганнарыбызны туйдырдылар. Хаста һәм сырхауларны

[18] Куропаткин — 1898-1904 елларда Россиянең хәрби эшләр министры, ә 1904-1905 еллардагы рус-япон сугышы вакытында рус гаскәрләренең хәрби җитәкчесе булган генерал А.Н.Куропаткин (1848-1925) турында сүз бара. Япон сугышында катнашкан һәм, әлеге генерал исемен еш телгә алып сөйләве сәбәпле, «Куропаткин» дигән кушамат тагылган татар кешесе дә булганлыгы тарихта билгеле (Мәрданов Р. Тарихта тибрәлгән Тәбәрле. — Казан: Тамга, 2011. — Б.378.).

[19] Кытай стенасы — Порт-Артурны көнчыгыш һәм төньяк тарафлардан саклау өчен элек кытайлар корган ныгытмаларны тоташтырып торган балчык валның атамасы. Тик Порт-Артур русларга күчкәндә ул ныгытмалар хәрби әһәмиятләрен югалтып, фәкать исем-атамалары гына сакланып калган.

[20] Тарихи хезмәтләргә караганда, Порт-Артурда япон әсирлегенә төшүчеләр барлыгы 26 мең кешене тәшкил иткән.

һәммәсен тикшереп, хастаханәләргә, казармаларга яткырдылар, цинга хастадыгы да бик күп иде. Порт-Артурны тәмам биш көндә алып, сәламәт булган солдатларның һәммәсен 27 нче декабрьдә, хосусый пароходка утыртып, Япониягә юлладылар. Без шул сәламәтләр җөмләсеннән Япониягә киттек. Бездән калган хасталарны да һәр атна тикшереп, аз гына сәламәтләнгән солдатларны Япониягә җибәреп торганнар, безнең артыбыздан һәр атна килделәр. Февраль ахырына кадәр килеп тәмам булдылар.

Япониягә баргач һәммә солдатны төркемнәргә бүлеп аердылар. Шулвакыт һәммәсен дин-кавем буенча үзенә башка урнаштырдылар.

ФИКЕР-НӘТИҖӘ

Әгәр дә японнар 13 майда Кинҗаоны алгач та, туктамыйча, безнең гаскәрнең артыннан басып килсәләр иде, ихтимал ки, ун көндә тәмам Порт-Артурны алган булырлар иде. Чөнки шулвакытларда Порт-Артурның Кара тарафыннан крепость укреплениеләре бер дә юк дәрәҗәсендә иде. Японнарның Кинҗаоны алгач, айлар буе тукталып торуы безнең өчен бик зур файда булды, без шул арада көне-төне эшләп, крепостьларны, укреплениеләрне һәммәсен позициягә ярарлык кылып алдык. Һәм дә японнар безгә бомба кулลануны күрсәтмәгән булсалар, безнең бомба белән сугышка хәзерлегебез юк иде. Хәлбуки, соң вакытларда без японнарны бомба белән харап иттек. Бездә снаряд калмады, ялгыз бу ышанганыбыз — бомба иде. Шул ике җәһәттән японнарның кимчелеге күрелде.

Безнең рус гаскәренең коралы — снарядлар биш кенә айга җитте, әгәр без һөҗүм иткән булсак, өч айда тәмам булыр иде. Без сугышның ахырында алты айдан соң күбрәк вакытларда япон тарафыннан атылган бомбаларны туплап, шуның белән сугыштык. Хәтта кайбер вакыт япон мортираларыннан атылган снаряд ярылмый калса[21], шуны алып, «Золотая Гора»га — Алтын Тавына чыгарып, үз мортираларыбызга салып атадыр идек. Шулай булгач, ничек сугышырга кирәк, менә акыл ияләре шуларны үлчәүгә салсалар, әлбәттә, Порт-Артурның унбер айга чыдавы да бик гаҗәп.

ӘСИРЛӘРНЕҢ ХӘЛЛӘРЕ

Русиядән әсирләр февраль ахырына кадәр Япониягә тәмам килеп тордылар. Мукденда[22] плен алынган ун мең кадәр рус гаскәрие килде. Һәммә әсирләрне һәр шәһәргә таратып куйдылар, Аскафурда егерме меңнән артык солдат әсир иде. Дүртенче участкада ун мең кадәр әсир бар иде, болардан алты йөз илле кеше мөселман иде. Һәр җирдә безнең мөселманнарны башкалардан аерып куйдылар. Шуның өчен, асыл әсирлек авыр булса да, безнең мөселманнарга бераз җиңелрәк булды. Чөнки японнар безне башка милләтләрдән аердылар, үзебезгә аерым казарма бирделәр, намаз укырга урын бирделәр, ашарга-эчәргә — һәммәсе үзебез теләгәнчә булды.

Әсирләрнең Япониядә бик озак калачаклары башта мәгълүм булгач та, безнең мөселман солдатлары үзара тупланып берләштеләр дә шул әсирлек заманаларын буш кичермәскә карар бирделәр.

Безнең арабызда яхшы мәгълүматлы һәм гыйлемгә иҗтиһадлы егетләр бар иде: Самар губернасының мулла Әхмәтҗан Котлыәхмәт улы, уфалы учитель[23] Морадетдин Фәйзуллин һәм башка яхшы мәгърифәтле егетләр

---

[21] Тарихи чыганаклардан билгеле булуынча, япон армиясенең 11 дюймлы мортираларыннан атылган снарядлардан фәкать 20 проценты чамасы гына шартлаган.

[22] Мукден — хәзерге Кытайның төньяк-көнчыгышындагы Ляонин провинциясе үзәге. Хуанхэ елгасы буенда урнашкан.

[23] Учитель — бу очракта рус-татар мәктәбе укытучысы мәгънәсендә.

бар иде. Шуларның гыйлем һәм мәгърифәтләреннән файда итәргә уйладык, киңәшләшеп шул фикергә карар биреп, дәресханә өчен үзебезгә тәгаен ителгән казарманың бер өлешен билгеләдек.

Тик бездә китап юк иде. Үз арабызда Коръәннең беренче кисәге, «Мөхтәсарел-викайә», ысулдан «Зөбдәтел-әсрар», «Тарикаи Мөхәммәдийә», «Карабаш» тәҗвиде, «Гакаиде Исламийә», «Гыйбадәте Исламийә», кайбер хикәяләр — болар да фәкать берәр нөсхә булганлыктан, боларның нөсхәләрен арттыру өчен үзара акча туплап, ун сум илле тиенгә Браль матбагасы (циклостиль) алдык. Шул машина белән бастырып, әйтелгән китапларны йөзәр — йөз иллешәр нөсхә кылып алдык.

Шуннан соң ул китаплар белән үзарада дәрес укыдык. Кайбер дәресләрне телдән сөйләп өйрәттеләр. Шул дәресләрне дә үз машинабыз (циклостиль) белән басып тараттык. Японнар безнең бу хәлләребезне күреп, бик мактап, афәрин укыдылар. Даими безне күргәндә «хорошо» дип китәләр. Ашауэчү — иң яхшы, чәй-шикәр — никадәр теләсәң, шулкадәр бирәләр. Ләкин бер дә үз илебездән хәбәр алып булмады. Сугышның нәтиҗәсеннән хәбәр алырга мөмкин түгел. Ул яктан без сукыр кеше кебек.

Берзаман әсирләр арасында сүз чыкты: Балтыйк эскадрасы килсә, безне коткарыр өметендә иделәр. Күп вакыт кичмәде, «Балтыйк диңгезе эскадрасы батты», дигән хәбәр чыкты, солдатларның күбесе бу хәбәргә ышанмадылар. Аннары әсир матрослар килеп, бу хәлнең дөреслеген хәбәр бирделәр. Берзаманнар Сахалиннан биш меңнән артык әсир килде. Япониядә барлык әсирләр җитмеш меңнән артык булды.

Әсирлекнең бер үзенчәлеге — эшсезлек. Без шул эшсезлектән файдаланып, дәрес укып, дәрес укыттык, арабызда һич укырга-язарга белмәгән кешеләр өч-дүрт айда укырга-язарга өйрәнделәр. Фәкать бездә шул җитешсезлек бар иде, безнең арабыздан бер дә япон телен өйрәнүчеләр булмады. Һәрхәлдә, шунда вакыт бик күп сүзләрне һәр солдат белгән иде.

Әсирләрнең тагын бер үзенчәлеге — һич җирдән дөрес хәбәр алып булмый. Һәртөрле ялган хәбәрләр һәркөн әсирләр арасында күп була. Берзаманнар солых хәбәрләре чыга башлады. 1905 нче елның август ахырында солых хәбәре бөтенләй таралып, һәркөн яңа хәбәр килә башлады[24]. Шул арада японнардан кайбер адәмнәр килеп, «солых булса, илегезгә кайтырсыз, монда калырга теләүчеләрегез юкмы?» — дип сорый башлыйлар. Ләкин безнең мөселман солдатлары арасында калырга уйлаган кеше мәгълүм булмады, рус солдатларыннан калырга сораганнар булды, һәммәсенең исемнәрен язып алдылар. Ахыры ничек булгандыр — безнең һич хәбәребез булмады.

Белгәнем кадәр яздым, хатасы булса — гаеп итмәгез?!

Оренбург губернасы, Орски өязенең
Габделхаликъ бине Гайнетдин Әхмиров.
1905 ел, 5 октябрь. Аскафурда.

Текстны басмага
***Раиф Мәрданов** хәзерләде.* ■

[24] Бу сугыш иске стиль буенча 1905 елның 23 августында (яңача 5 сентябрьдә) тәгәлләнгән.

Йортларның да җаны бар

САМИГА СӘҮБАНОВА

Бауман урамындагы 19 нчы йорт... Матбугат йорты... Башкалабыз Казан шәһәренә, тормышта үз урынымны табам, дип укырга килгәч, музейлар — театрларның гына түгел, шушы бинаның да ишеген ачтым мин. Коридорларыннан йөрдем, китаплардан гына күреп белгән язучыларның үзләрен шушында күрдем, икенче катта әдипләргә карата төртмәле «Тынгысыз каләм» газетасы эленгән иде. Янында озаклап укып басып тордым.

Башка язмаларны хәтерләмим, ә менә шагыйрь Нури Арсланның кызлар яратуы турында шигырьме, язмамы — бик яхшы хәтеремдә... Аңа җирлеге дә булган — сокланып, җырлар язарга илһам бирүче кызга багышлаган, соңыннан халык тарафыннан яратып җырланган «Казан кызы», «Нәсимә» дигән җырларын язарга илһамландыручы үзе дә шунда эшләгән... Бу өлкән кешенең аталарча яратуы гынадыр бәлки. Ә җыр тууга сәбәп булган. Нури ага үзе дә олпат гәүдәле, чибәр кеше иде.

Матбугат йортының ишеге ябылып тормый һәм теләгән һәр кешегә ачык иде. Ишек төбендә хәзерге кебек саклар да юк, утырса, шул аерым будкасында швейцар гына утырды, ул пенсия яшендәге яисә авыр эшкә ярамаганрак өлкәнрәк кеше иде. Аскы катында саклык кассасы бүлеге, чәчтараш. Шулай булгач, анда иртәдән кичкә кадәр биредә эшләүчеләр генә түгел, якын-тирәдәгеләрнең барысы да йөрде. Өченче катта ашханә, медпункт, теш табибы. Икенче катта — буфет. Табибка керер өчен дә бернинди документ кирәк түгел, фәлән редакциядә эшләвеңне генә әйтәсе. Биредә эшләүчеләрнең туганнары, танышлары да тешләрен каратып-дәвалатып китәләр иде.

Миңа анда эшләүчеләр җир кешеләре түгел, ә айдан төшкәндәй күренделәр. Юк икән, бер дә алай түгел, ике аяклы, ике куллы, нәкъ безнең кебек кешеләр икән...

Моның шулай икәнлеген үземә дә бу бинада эшләү бәхете элаккәч кенә аңладым.

Мин эшләгән «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре икенче катта, ә без — анда басыласы әсәрнең беренче укучылары, машинисткалар — бишенче катта — Тукай клубының сәхнә арты ягында — утырдык. «Казан утлары»н Мәгъмүрә апа белән мин, «Идел» альманахы авторлары белән Сафия апа эшли, Язучылар берлеге кәгазьләрен Мәдинә яза, ә безгә каршы өстәл артында Тукай клубы директоры Лариса апа утыра.

Клубта кичләрен һәр атнада диярлек шагыйрьләр, артистлар катнашында җомга кичәләре, көндезләрен төрледәнтөрле җыелып җитди сөйләшүләр, җыелышлар булып тора. Ә аларны оештыручылар, анда чыгыш ясаучы олпат кешеләр безнең аша уза иделәр.

Кемнәр генә булмады безнең бүлмәдә... Башкортстаннан Мостай Кәрим, Әнгам Атнабаев та, үзебезнең сәнгатькярләр вә әдипләребез Венера Шәрипова, Эмиль Җәләлетдинов, Сара

Садыйкова, Таһир Якупов, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Мөхәммәт Мәһдиев... Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри... Чыңгыз Айтматовны да шушында якыннан күрдек.

Шунда эшләгән чаклар турында көндәлегемә дә язгалаганмын:

15 гыйнвар 1971 ел

Бүген Себер татарларының халык иҗатына багышланган җыр кичәсе булды. Клубта Такташ портреты бөтен залны тутырып, урындыклар өстенә җәеп салынган. Аны алып куярга кирәк иде. Астан (икенче каттан) Гариф Ахунов менде. Сафия апа, мин булышырга кердек.

Матур портрет. Рәссам аны 4 көндә ясап бетергән һәм 312 сум алган (ул

Башкортстаннан Мостай Кәрим, Әнгам Атнабаев та, үзебезнең сәнгатькярләр вә әдипләребез Венера Шәрипова, Эмиль Җәләлетдинов, Сара Садыйкова, Таһир Якупов, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Мөхәммәт Мәһдиев... Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри... Чыңгыз Айтматовны да шушында якыннан күрдек.

чагында редакция хезмәткәрләренең айлык хезмәт хакы 100 сумнан артмый иде). Әле буяулары да кибеп бетмәгән бу портрет 12сендә Галиәсгар Камал театры бинасында үткәреләсе кичәдә сәхнәгә элеп куелачак.

5 февраль

Бүген Казанда яшәүче чуваш язучысы, тәрҗемәчесе Юдинга 60 яшь тулуга багышланган кичә булды. Клуб директоры Лариса Сәйфуллина берничә көн инде артистлар чакырып төрле җирләргә шалтыратты. Концерт оештырырга кирәк иде. Ә бу эш комиссия әгъзасы Кави Латыйпка тапшырылган булган. Ике көн кала ул: «Артистлар таба алмыйм», — дип шалтырата. Сөйләшү буенча күп кеше катнашырга тиеш иде. Ләкин бер-бер артлы телефон шалтырый торды, нинди дә булса сәбәп табып, килә алмауларын хәбәр иттеләр. Концерт булмый калу куркынычы туды. Чувашларның үзләренең дә артистлары килергә тиеш, дип бераз тынычландырдылар.

Әмма ни генә булмасын, юбилей икән, кичәне оештырырга кирәк иде. Өлкә комитетыннан Мусин да: «Әйбәтләп уздырмасагыз, кирәгегезне бирермен», — дип, басым ясап әйткән. Язучылар Союзыннан Юрий Белостоцкий, Хәсән Сарьян утлы табага баскандай йөриләр. Ләкин бер көндә генә кая ул?

Таһир Якупов — гастрольгә китәргә тиеш. Сара Садыйкова авырый, үзе килә алмый. Көчкә-көчкә Флёра Сөләйманова белән элемтәгә керелде.

Бәхеткә, Таһир китәргә өлгермәгән булып чыкты. Флёра, Таһир, баянчы Рифкать Гомәров килергә булдылар. Сәгать 7. Башланыр вакыт. Залда 3-4 кеше. Артистлар борчыла. Хәсән Сарьян, Белостоцкий әрле-бирле йөриләр. Лариса апа утлы табага баскандай. Обком кешеләре килергә тиеш.

Ниһаять, барысы да җайлана бугай, халык җыелды, җиңел суларга була.

Сәхнәгә Чувашстан вәкилләре, юбиляр, комиссия әгъзалары чыгып утырды. Юбиляр соргылт көрән костюм кигән, ап-ак чәчле, яп-ябык. Хәсән Туфан да президиумга чакырылды. Зәки Нури да шундагы урыннарның берсенә кунаклады.

Юбиляр миңа таныш түгел. Ул чувашча яза, чувашчага тәрҗемә итә. Шуңа күрә әсәрләрен белмим.

Аңа матур теләкләр теләп, тантаналы өлеш тәмам булгач, концерт өлешен Флёра Сөләйманова башлап җибәрде.

Язучылар Союзында эш гөрли... М.Хәбибуллин, Ш.Галиев, Ф.Миңнуллин, Г.Рәхим, И.Юзеев, Г.Ахунов (рәис), Р.Мингалимов. Узган гасырның 80 нче еллары

Үзешчәннәрдән бер егет татар биюе башкарды, берсе матур гына җырлады, чуваш халык артисты — бер ир кеше — 3 җыр башкарды һәм Таһир Якупов чыкты. Ябык, чибәр, яшь. Моң.

Таһир матур җырласа да, тиз-тиз сөйләшә, таныш булмаган кеше аңламаска да мөмкин. Ул радиода 3 җыр яздырган, шуны катушкага урау белән мәшгуль булды. Гомумән, һәркемнең үз мәшәкатьләре бар иде.

...Имеш, безнең язучылар, артистлар Мәскәүгә баргач, Сергей Михалковка Эмиль Җәләлетдиновның җырлавы ошаган һәм ул Мусинга:

— Ни өчен аңа народный артист исеме бирмисез? — дигән. Тегесе: «Учтём», — дип җавап биргән. Таһир белән Флёра матур җырлый. Нигә Флёрага әзрәк юл ачмыйлар икән?

25 март

Бүген Сара Садыйкова партия турында язган җырын безгә рояльдә уйнап күрсәтте. Ләкин бу көй, минемчә, партия өчен әрәм шикелле. Аннан соң кабатлаулар да бар.

Сара апа: «Мәхәббәт җыры»н (Хәй Вахит) карадыгызмы? — дип сорады.

Мин:

— Премьерага бардым, — дидем.

— Искиткеч! Хәй Вахитның «Кайда соң син?» спектаклен үзгәртеп, иске пальтоны әйләндергәннәр дә, җиңнәре, якаларына ак мех беркеткәннәр, матурлаганнар, халыкка ярардай әйбәт әсәр килеп чыккан, — диде.

Аннан минем алкага күз төшерде.

— Менә син, алка таккач, бөтенләй икенчеләнгәнсең, моны салсаң, гапгади буласың да каласың. Хатын-кыз бизәнергә, украшениеләр тагарга тиеш, ләкин ни өчендер безнең халык моны кулланмый, — диде.

Ул бик тә энергияле, җилт-җилт килеп йөри торган хатын. Ә тавышы — чишмә чылтыравы кебек. Аның яшендәге кешегә бу соклангыч!

Сара апа Тукай клубына еш керә, озаклап сөйләшеп утырырга ярата иде.

Шәүкәт Галиев, Ләбибә Ихсанова, Венера Ихсанова һәм Зәкия Туфайлова – Тукай клубында. 70 нче еллар

Үзе дә калфаксыз, бизәнмичә йөрмәде. Берсендә, узган гомере турында сөйләшеп утырганда, сугышта хәбәрсез югалган ире турында сүз кузгалгач:

— Сара апа, әгәр ул исән булып, берәр хатын белән яшәп ятканын белсәң, нишләр идең, — дигәч:

— Алай булсамы? Ут эченнән исән-имин калырга ярдәм иткән өчен мин ул хатынга рәхмәт кенә әйтеп, сөенеп кенә яшәр идем, — дигән иде.

30 март

…Алкага Сара апаның күзе тиде ахры — ял көнне югалттым — төшереп калдырганмын…

14 февраль

Җомга көнне Татар ашлары йортыннан Юныс Әхмәтҗанов килде. Ул кызык кына итеп бер сәгать буена ризыкларны ничек тәмле итеп пешерергә икәнен өйрәтте. Аннан соң талкыш кәләвә авыз иттек. Соңыннан кулинария йорты үзешчәннәре кызыклы концерт куйдылар.

24 февраль

Көтмәгәндә Ибраһим Гази үлде. Мин аны кич белән эштән киткәндә сау-сәламәт килеш күргән идем. Ул минем артымнан кайтырга чыкты.

Бик кызганыч, әлбәттә. Ходай Тәгаләгә дә әйбәт кешеләр кирәктер, күрәсең.

Кичә аны күмү ыгы-зыгысы белән үтеп тә китте. Мин дә бардым. Ишек төбендә почётный каравылдан чыгучы кешеләрнең повязкаларын чишеп тордым. Аннан соң үзебез дә бастык. Табутта Ибраһим абыйның ятуына гына ышанасы килми. Үзгәргән шикелле,

мин белгән, күргән Ибраһим абыйга охшамаган да иде. Әмма минем күңелемдә һаман да киң күңелле, сабыр, мөлаем, тормышның караңгы якларыннан да матурлык эзләүче булып гомергә яшәр. «Онытылмас еллар», «Гади кешеләр» авторының (иң яраткан әсәрләрем) арада юклыгын күңел кабул итәргә теләми. Мин аны татарның хәзерге чорында иң бөек, иң ихтирамга лаек коммунизм кешесе, дияр идем. Коммунизм турында сүз буа буарлык булса да, андый кешеләр санаулы гына.

Арча зиратына күмделәр. Кабере ошамады. Сай гына, тар гына итеп казылган, саргылт балчыклы җир. Җире дә исәпле шул. Хәтта анысын да кызганалар. Елаучылар күп булды.

Язучының иҗатын зурлап, аны соңгы юлга озатырга килгән авылдашларының, халык таралгач, кая барырга белмичә аптырап калуын күреп, озату эшләрендә катнашкан Лирон Хәмидуллин аларны машина белән озатып җибәрү мөмкинлеге булмавына бик кыенсынган иде. Нишлисең, безнең илгә язып кына түгел, марҗа хатынга өйләнгәч, аңа ярарга тырышып, улына үз фамилиясен дә бирә алмаган әдип үлгәч, үзе белән бергә, авылдашларының да кирәге беткәндер шул.

Берничә елдан соң, йомышым төшеп, шәһәр поликлиникаларының берсендә Сердинский дигән фамилия язылган табличка эленгән ишектән әдипнең үзенә ошаган табибның чыкканын күрдем. Язучының улы иде бу. Әтисенең фамилиясен йөртмәгән бу урыс кешесе татарча сөйләшә белмәгән кебек, без елый-елый укыган ул китапларның ни турындалыгын да белмәгәндер әле...

Тукай клубында мәшһүр иллюзионист Игорь Кио да булып китте.

1973-1974 елларның җәе иде. Кио фамилиясенең ничек алынганын да аңлаткан иде. «Әти чит илгә чыгышлар белән баргач, кинотеатр бинасында Кино дип язылган тактада «Н» хәрефе бозылып, Киога әйләнүенә игътибар иткән, үзенә псевдоним итеп алган. Безнең фамилия шуннан», — дигән иде.

Кио безгә идәндә яткан бауны вертикаль итеп таяк сыман бастырды. «Бу номерны үзләштерер өчен ел ярым вакыт китте», — диде. Аннан соң җиң очыннан тере үрдәк китереп чыгарды.

1959 елда Татарстан китап нәшрияты Нәби Дәүлинең шушы бинада чыгарган «Яшәү белән үлем арасында» китабын елый-елый укымаган бер кеше дә калмады. Күз яшьләре тама-тама укый торгач, китап битләре теткәләнеп беткән иде. Бу затлы китап миндә әле дә күз карасы кебек бик кадерләп саклана.

Әдип тә бу бүлмәдә безнең белән чәй эчәргә ратты.

Әтисенең фамилиясен йөртмәгән бу урыс кешесе, татарча сөйләшә белмәгән кебек, без елый-елый укыган ул китапларның ни турындалыгын да белмәгәндер әле...

Ул тоткынга эләккәч, концлагерьга алып китәсе юлын күпкә алдан — сугышка киткәндә поездда йокымсыраганда күрүен сөйләгән иде. «Өскә ишелеп төшәрдәй булып торган авыр болытлар, караңгыга тоташкан поезд юлы иде. Соңыннан шул юл белән безне концлагерьга алып киттеләр», — дигән иде ул.

***

Тукай клубындагы кичәләр еш кына халык белән шыгрым тулып, анда басып торырга урын калмаган чакларын да хәтерлим.

Клубка керә торган бишенче катта Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучыларның исемнәре язылган истәлек тактасы куелган иде.

Язучылар берлеге белән «Казан утлары» икенче катта, кара-каршы бүлмәләргә генә урнашкан иде. Аңа хәтле

бер-берсе белән иҗат планнарын уртаклашканнар, урыс һәм чит ил язучыларының классик әсәрләрен татарчага тәрҗемә иткәннәр, рухи культурабызны үстерүдә фидакарьләрчә хезмәт куйганнар.

«Казан утлары» журналы хезмәткәрләре, бүтән басмалар белән бергә, 1974 елда Декабристлар урамындагы яңа бинага күчте. Яңа бинаның үзенең яңа тарихы башланды.

inkazan.ru

Милләтебезнең рухи бишеге булган, зур корабны хәтерләтеп, әллә кайдан үзенә дәшеп торган бинабыз хәзер безнеке түгел. Ул халыкның рухын баетуга түгел, табыш янчыгына әйләнергә тора.

«Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Ялкын» журналлары, өстәге катларда республикага тарала торган абруйлы татар һәм рус газеталары редакцияләре, китап нәшрияты бүлмәләре тезелеп киткән. Бу бүлмәләргә татар әдәбиятын югары күтәргән, татар милли рухын тәрбияләгән әдипләр үз әсәрләрен күтәреп килгәннәр, фикер алышканнар,

Бернәрсә дә мәңгелек түгел. Коммунизм турындагы иллюзияләребез юкка чыккан шикелле, милләтебезнең рухи бишеге булган, зур корабны хәтерләтеп, әллә кайдан үзенә дәшеп торган бинабыз хәзер безнеке түгел. Ул халыкның рухын баетуга түгел, табыш янчыгына әйләнергә тора.

Йортларның да җаны бар. Үткәннәрен кадерсезләүгә җаннары әрнемәсен иде. ■

ӘДӘБИ МИРАС

Һәрзаман сүз башланыр «Бисмилла» дип,
Һәрвакыт эш башланыр «Бисмилла» дип.
Яхшылар «Бисмилла»сыз эш кылмаган,
Эш тәмам «Бисмилла»сыз һич булмаган.

Мифтахетдин Акмулла

КУТАДГУ БИЛИК*

*(Котайткыч белем)**

ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИ
(ЙОСЫФ ХАСС-ХАҖИБ)

ИЛБИК ҮГДЕЛМЕШКӘ ҮГЕТ БИРӘ

Айтулдының ясын[1] үткәрде илбик.
Юатты углын һәм нәсыйхәт бирде.

«И угыл, — диде ул, — артык кайгырма,
Сөенеч алмашка килә кайгыга.

Бу кайгы-сагышта син түгел ялгыз,
Миңа да кул сузды бу кайгы-сагыш.

Артык кичеренмә, үзеңне юат,
Миңа елыш хәзер, хезмәткә юллан.

Атаң үлгәч, синең атаң инде мин,
Син угыл бул миңа, аталык итим».

Җир үпте Үгделмеш, әйтте: «И, илбик,
Күп яшә идарә итәрәк илне.

Мин бер тугрылыклы хезмәтчең-колың,
Минем җаным булсын илбиккә йолым.

Атамның җаны да йолым булды ла,
Йолым итсен Тәңре ошбу колны да».

Чыгарды атасы бөтеген углы,
Вәкарь белән генә илбиккә сонды.

Илбик алды, ачты, укыды хатны,
Сүзен аңлап, әйтте: «Кара ахмакны,

Һәрвакыт йөрдең дә син миннән алдын,
Ишек шапылдаттың, урын буш калды.

Тереклегеңдә син миңа йөз тоттың,
Үлгәндә дә мине уйлап, кайгырттың.

Үти алмадым мин син — дустым хакын,
Илаһым үтәсен һәм ярлыкасын.

Никадәр сөенеч китерсәң миңа,
Шулкадәр шатлыклар Хак бирсен сиңа».

Сүзен кисте илбик, күзе яшьләнде,
Чыгып китте, күрче, яшереп хәлне.

Тагын керде өйгә — күңеле төшкен.
Көн буе утырды бикләп ишеген.

Айтулдының углы җуын[2] уздырды,
Ярлыларга хәер — ефәк, бүз — бирде.

Бераз үтеп киткәч ата кайгысы,
Төрле яхшы кеше белән танышты.

Ата үгетенә булгачтын тугры,
Үзе котлы булды, көннәре нурлы.
Ни ди, ишет, әнә, акылдар кеше
(Башыннан кичергәч күптөрле эшне):

«Ата нәсыйхәтен каты тот, каты,
Булыр кот — бәхетең, көннәрең татлы.

Атаңны-анаңны сөендер һәрчак,
Төмән меңчә артык әҗер булачак».

Илбик тә тырышты шул көннән ары,
Идарә эшләрен яхшырта барды.

---

* Дәвамы. Башы журналның 2013 елның 10-12, 2014 елның 1, 2 нче саннарында.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.
[1] Яс — җеназа мәрасиме (татар сөйләшләрендә дә бар).
[2] Җу — мәҗүси матәм мәрасиме (борынгыча — йогъ).

Баеды халык һәм ил алга китте,
Дога кылды һәркем хуплап илбикне.

Утырды илбик беркөн ялгыз үзе,
Китабын ташлаган, гарештә күзе.

Зиһене чуалды — аңлый алмады,
Сорарга теләде — кеше булмады.

Уйлап Айтулдының ирдәмлекләрен
Әйтте: «Их, бар иде ирләрнең ире!

Капуымның күрке, дустның изгесе,
Илгә файда иде аның һәр эше.

Урыны буш калды, таркала эшем.
Бармы минем тагы шундый бер кешем?»

Үгделмеш хакында уйлады бераз:
«Егетне дә миңа онытмау фарыз.

Үлгәндә Айтулды тапшырды углын,
Мин аны да, ахры, онытыр булдым.

Атасы үлсә дә, углы тиз үлмәс.
Берсен җуйдым, берсен тотып калыйм, бәс».

Тиз үк Үгделмешкә җибәрде чапкын,
Ишеген япты да, уйланып ятты.

Бераздан ишеккә Үгделмеш килеп,
Сөенечле хәлдә күренде кереп.

Илбик каршылады сорау бирәрәк:
«Ни хәлләргә салды сине бу фәләк?

Сөйлә бу көннәрдә ниләр булганын,
Туры йөрисеңме, кыек юлданмы?

Атаңны озаткач, ниләр кичердең?
Сагышлымы көнең, сөенечлеме?»

Үгделмеш сүз ачты: «Бәхтияр илбик,
Озын-озак яшә, даның җәелеп.

Синең хезмәтеңнән мин ерак инде,
Заман каш җыерды һәм йөз чөерде.

Шактый вакыт илбик йөзен күрмәдем,
Сагышта йөрдем, көлеп йөрмәдем.

Бүген менә мине илбик чакырды,
Яхшы ният, дәүләт өчен, ахыры.

Илбик чакырганын ишеткәч үзем,
Көнем иге булды, яктырды күзем».

Шуннан илбик төрле белек сорады,
Үгделмеш тә телен бәйләп тормады.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ХЕЗМӘТКӘ КЕРҮЕ

Илбик әйтте: «Инде, углым, буш йөрмә,
Миңа хезмәттә бул, күңлең төшермә.

Игелекләр бик күп күрдем атаңнан,
Ул китте, бурычым өстемдә һаман.

Хәзер мин бурычны үтәргә тиеш,
Миңа, юкса, кеше гайбәте тияр.

Өчурда[3] хакиме, ишет, ни дигән,
Тел төбенә төер салып белдергән:

«Кеше сиңа ярдәм итсә, билгеле,
Онытма, булмасаң бөтенләй үле.

Кешелектән чыкма, и асыл кеше,
Кешелек итү чын кеше кылмышы.

Кем хезмәте керсә синең эшеңә,
Әҗер итеп күбрәк хезмәт ит шуңа.

Кешелек белән, күр, кеше таныла,
Кеше арасында кеше дан ала.

Хайван кебек йөрмә, кеше кебек бул
Кешегә кеше бул һәм игелек кыл».

Үгделмеш җир үпте: «Әйтим иң элек:
Илбик игътибары — миңа игелек.

Табынган колыңмын, ә син биемсең,
Яхшы бәге кылмас колын кадерсез.

[3] Өчурда — борынгы төрки дәүләт.

Теләсәң кыйммәт бел, теләсәң очсыз,
Үземне багышлап сиңа тотам йөз».

Торып чыкты акрын капкага килеп,
Бераз йөреп барды өенә тиклем.

Шуннан соң Үгделмеш билен баглады,
Тайпылышсыз хезмәт көнен башлады.

Таңнан кичкә кадәр урнында калды,
Яткакта[4] ашады, кич йоклап алды.

Яраса илбикнең күңленә эшең,
Ишек ачып, кулын бирә бәхетең.

Ни ди, әнә, хезмәт итеп йөрүче,
Хезмәт итеп, хөрмәт атын менүче:

«И, бәкләр шатлыгын теләүче кемсә,
Бар эшеңне кыл син бәк теләгәнчә.

Бигә ярамас эш кылса әгәр дә,
Кол үзе гаепле — калса бәлагә.

Әгәр ошатмаса эшеңне бәгең,
Зая булыр шундук бар ирешкәнең».

Якын итте илбик, күр, Үгделмешне,
Аңлатып, тапшырды аңа күп эшне.

Бер көнен утырып моңайды илбик:
«Әрәм булды, Ходай, йә нинди ир!» — дип.

Халаек җыелмыш, сәрайга тулган,
Тик кая бер эшкә яраклы углан?

Белеп эшли торган иде һәр эшне.
Кая бер хезмәткәр шуның рәвешле?

Сынамыш кешеләр әнә ни диләр
(Яман һәм яхшыны күргән кешеләр):

«Җитәкче бар эшне башкара ала,
Тик осталар башы шәп булсын аңа».

Буй күрсәтеп йөргән егетләр әзме?
Ләкин ышанычлы егет юк хәзер.

Арада кирәк эш күверүче юк,
Файда китерим дип тә йөрүче юк.

Ни, ди, ишет әнә шигырь тезүче —
Сүзен тирән мәгънә белән төзүче:

«Ярамсаклар күп тә, яраклысы юк.
Яраклы табылса, ярашмый холык;
Хәтсез карабаш һәм хадим-хезмәтче,
Шунда бер генә дә ярдәмлесе юк».

Хәтерләде илбик тапкыр мәкальне:
«Нәселле зат үлер — калыр нәселе».

Бу Айтулды углы — кем соң ул болай?
Атасы урынын бирергә була!

Атасы китте һәм урын буш калды,
Шул урынга углын утыртып карыйк.

Аны тәрбияләп кеше итикче,
Эштә белсен — нинди була чын кеше.

Сынап күргәнемчә, кеше булырлык,
Яшьлегеннән үзгә кимчелеге юк.

Халыкта абруйлы берәү ни дигән
(Ул үзе бәхетле дә була белгән):

«Күтәрсә бий колны, булмас бик начар:
Корал башы булыр һәм урынбасар».

Якынлаштырса бий коллардан берне,
Ул кол хезмәтенең кадерен белер.

«Үтимче, — диде бий, — атасы хаккын,
Кешелекле булу һәрнидән артык.

Атасы күп хезмәт күрсәтте миңа,
Кайтарыйм әҗерен аның углына.

Асылзат икәнен онытмыйк аның,
Асылзат нәселен корытмыйк аның».

Ни ди, абышканың[5] ишет бу сүзен
(Абышка тугры сүз әйтә, и, кузый):

---

[4] Яткак — кальга яисә сәрай капкасында каравылчы гаскәриләрнең ял бүлмәсе яки бинасы.
[5] Абышка — шут; хәзерге татар-башкорт сөйләшләрендә «хатынсыз калган ир, кыз алалмаган егет».

«Игелек кыла тор, и иге кеше.
Иге эш картаймый, мәңгедер яше.

Игелек картаймас, тузып ертылмас,
Аның яше озын — тиз онытылмас».

Хөрмәтләде илбик, күр, Үгделмешне,
Сынап, аңар барча, тапшырды эшне.

Ачык күңел илә күтәрде аны,
Фәләк уңай килде, мач килде канун[6].

Уңарды тәртип һәм дәүләти табуг[7],
Ачылды тотыктан[8] теләлгән капу.

Үгделмеш ни әйтсә, сүзе сүз булды,
Илбик исә аңар колак-күз булды.

Илбик әйтте: «Булды теләгән эшем.
Төзекләнде илнең эче һәм тышы.

Һәр эшнең йөләге[9] була билгеле,
Моңарчы мин үзем ялгыз җигелдем.

Менә табылды мин теләгән кеше,
Тагын һәйбәтләнер җитешкәч яше.

Булдырасы углан — сугыш яганы[10],
Кечедән билгеле сәләте аның.

Бу хакта борынгы бер бәйтне[11] укы
(Тыңласаң, мәгънәсе ачылыр тагы).

Үгделмеш утырып һәм торып эшләп
Көндез эш бетмәсә, утырды кичләп.

Авыр, четерекле эшләр башкарды,
Күп булды файдасы тигән чаклары.

Котылды илбик тә, бетте имгәге,
Ил килере артты — кимеде йөге.

ИЛБИКНЕҢ СОРАВЫ, ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Чакырды илбик беркөн Үгделмешне,
Сынады егетнең ниләр белмешен,

Илбик әйтте: «Ишет инде, и угыл,
Мин синнән сүз сорыйм, син җавапта бул.

Менә син әйтеп бир: нәрсә файдасыз
Һәм нәрсә файдалы, кайсы вә кайсы?»

Үгделмеш әйтте: «И бийем, син үзең
Гыйлем хәзинәсе, кеше игесе.

Ике галәмдә дә яхшы шул ике:
Эшең булсын юньле, ә холкың ипле.

Аннары ихсан вә оят[12], тугрылык —
Шул өч белән инсан бәхетле булыр.

Холкың гүзәл булса, яратыр һәркем,
Тугрылыклы булсаң, түргә үтәрсең.

Оятлы ярамас эштән тыелыр,
Оятсызлык ирдә — гафүсез кылык.

Оят һәм тугрылык, иге эш бергә
Бәхет китерәчәк сиңа гомергә.

Һәр эшең-гамәлең булса саф, иге
Ике дөньяда да котайтыр сине».

Илбик әйтте: «Ярый, монсын аңладым,
Әйт хәзер кешенең яман якларын».

Дәвамы бар ■

[6] Фәләк — монда «йолдызнамә күрсәтүче», канун «гомуми гармония, язмыш, туры килеш».
[7] Табуг — буйсыну; дисциплина.
[8] Тотык — «наместник, губернатор», монда — борынгы бер мәкаль.
[9] Йөләк, йөлен — умыртка баганасының түбәнге өлеше, һәр эшнең иң авыр, терәк моменты.
[10] Яган — сугышка өйрәтелгән фил, монда мәкаль составында.
[11] Бәйт — «дүртьюллык шигырь»; үзе китерелмәгән — төшеп калган.
[12] Оят — күңелдән, эчтән начарлыктан тыелу, ихсан — тыштан, кыланышта әйбәт, матур булу.

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

АРСЛАНОВ ГОСМАН ВӘЛИ улы (1897-1941) — рәссам-график, иллюстрацияләр ясаучы рәссам, карикатуралар авторы. 1920-1930 елларда Тукай әсәрләренә күпләгән иллюстрацияләр иҗат итә. Аның «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле китабында (Казан: «Гажур», 1926) беренче мәртәбә дөнья күргән 43 иллюстрациясе цинкография техникасында (гравёр — Назаров) башкарылган. Алар арасында «Су анасы» поэмасына (1 ил.), «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына (5 ил.), «Шүрәле» поэмасына (3 ил.), «Мияубикә» (12 ил.), «Тройка», «Яшен», «Борын», «Ысулы кадимче», «Мулланың зары», «Номерга төшкән искеләр» һ.б. шигырьләренә ясалган иллюстрацияләр бар. Г.Арсланов рәсемнәренә билгеле бер дәрәҗәдә дилетантлык хас булса да, иллюстрацияләре тудырган типажларның холкын дөрес тотып алуы белән, татар халкының көнкүреш үзенчәлекләрен төгәл чагылдыруы белән аерылып тора. Аларда гротеск элементлары кергән юмористик һәм сатирик интонацияләр өстенлек итә. Аркылы ксилография (гравёры күрсәтелмәгән) техникасында башкарылган әлеге иллюстрацияләр Тукайның 1920-1930 елларда дөнья күргән башка басмаларында да кулланыла: «Шүрәле» (Казан, 1927); «Шүрәле» (Казан: Татгосиздат, 1936). Әлеге басма өчен Г.Арсланов ике төрле төсне файдаланып, яңа тышлык ясый. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» (Казан: Яңалиф, 1927), «Мияубикә» (Казан: Яңалиф, 1927), 1935 елгы «Мияубикә» (Казан: Татгосиздат, 1935) басмаларына цинкография техникасында башкарылган иллюстрацияләр урнаштырыла. 1937 елгы «Мияубикә» (Уфа: Башгосиздат, 1937) басмасында исә 1935 елгы китабындагы цинкографияләр кулланылган. «Су анасы» поэмасы өчен ясалган 2 иллюстрация Тукайның «Академик басма»сының I томына (Казан: Татгосиздат, 1943) кертелгән. Рәссам ясаган иллюстрацияләр 1960-1970 елларда Тукай тормышы һәм иҗатына багышлап чыгарылган альбомнарда да урын алган.

Әдәбият

Ишморатова С. Тукай иҗаты иллюстрацияләрдә / Габдулла Тукай. — Казан, 1948. — Б.232-238; Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. — М., 1978. — С.190; Зарипов Э.Я. Художники книги // Здравствуй, книга! — Казань, 1989. — С.165; Шагеева Р.Г. Живописные сады Тукая // Казань, 2006. — №7. — С.128.

Ольга Улемнова,
сәнгать фәннәре кандидаты

Фото М.Макаров архивыннан

Финляндия президенты белән тантаналы очрашу вакыты.
Сулдан уңга: Венера Шәрипова, Айрат Арсланов, Илһам Шакиров, Рөстәм Яхин, Гомәр Таһир, Марс Макаров, Марат Әхмәтов, Урхо Кекконен. 1968 ел.

ТАТАР МОҢЫ ИЛЧЕЛӘРЕ

— Бу фоторәсем 1968 елның май аенда Хельсинкида төшерелгән. Тарихи ел — милләттәшебез, Хельсинки университетының төрки телләр галиме, профессор Гомәр Таһир Тукай оешмасына нигез салган ел, — дип сүз башлады Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, мәшһүр композитор һәм виртуоз музыкант **Марс МАКАРОВ**, — Ул «Совет-фин дуслыгы» оешмасына мөрәҗәгать итеп, Татарстанның сәнгать әһелләрен кунакка чакырды.

– «Салкын сугыш» чоры. Илнең «тимер пәрдә»дә чагы... Шул мәлдә капиталистик илгә сәфәр чыгуы – үзе үк бер могҗизага тиң гамәл ләбаса.

— Әйе... Башта КГБда: «Ватан серен чишмәскә!» — дип лекция укыдылар. «Илһам Шакиров бер үк телен тыйсын! Теләсә нәрсә сөйләмәсен анда!» — дип тә колакка тукыдылар.

– Чит илдәге милләттәшләребез белән Совет чорында иң беренче рәсми очрашу да булган икән әле бу.

— Ул елларда Финляндиядә биш йөз татар гаиләсе бар иде. Татар мәктәбе, балалар өчен театрлары гөрләп эшли. «Ислам йорты» да татарлар кулында! Иң хәтердә уелып калганы — үзебезнең татарлар булды. Төркиядән, Германиядән, Канададан, Америкадан ук килгәннәр безне күрергә, тыңларга дип! Илһам Шакиров «Карурман»ны җырлаганда меңәр татар елап утыра. Күңелгә тәэсир итә торган гаҗәеп күренеш... Рәшит Ваһаповның абыйсы белән, шулай ук Хәйдәр Бигичевнең өчтуган абыйсы — Финляндиянең иң бай кешесе — Усман Али белән дә күрештек.

...Вокзалга безне озатырга бала-чагасы, олысы — һәммәсе төшкән иде. Бөтен фин татары, чит илдән килгән кардәшләр... Мин баян уйныйм, Илһам Шакиров: «...Сау булыгыз инде...» — дип үзәк өзгеч моң белән җыр суза, халык исә... елый... елый... Менә шундый хатирәләр...

Әңгәмәдәш — ***Морад Дусай***

МӘРЬЯМ

ЗАРИФ МӨЭМИНОВ

(Повесть*)

Рәхимә җиңги мине үз өенә алып чыкты. Зур чиста бүлмә. Дивардагы сәгать сигезне сугып, унбиш минут киткән иде. Унлы лампа балкып тора. Бүлмә эче яп-якты. Җиһазлар һәммәсе дә үз урынында. Җиңги миңа өс киемнәремне салырга кушты һәм мич артыннан озын кунычлы киез итек китереп бирде.

— Ыргыт ул каткан чабаталарыңны! Менә бу киез итекне ки, — диде. Тимер мичкә ягып аш җылытты. Каз итләре кыздырды. — Нык итеп аша, туйдыр тамагыңны, — ди.

Мин, Хәким бабайларда бик тартынып, артык ашамаган идем. Җиңгинең ашы тәмлерәк, калҗалары симезрәк булганга, яхшы ук ашап куйдым. Җиңги үзе ашарга утырмады. Тик мине генә кыстап торды. Мин ятсынып утырдым. Аның болай туп-туры кыю итеп каравы мине куркыта иде. Кайсы якныкы булуым, нинди гаиләдә үсүемне сорашты. Ул мине шундый үткер күзәтә ки, хәтта бармак очындагы тырнакларымны да карый, шунда да минем нәрсәдәндер куркуымны сизә булса кирәк. Үзе, берни булмагандай, сөйләнеп ала:

— Иркенләп утыр, үз өеңдә кебек бул. Мин кыю кешеләрне бик яратам, үзем дә бик кыю мин, — диде. Аның кыюлыгын Хәким бабайларга килеп керүеннән үк белгән идем инде.

Йокларга әзерләнә башладык. Җиңги миңа урынны бүлмә кырыеннан салып бирде. Үзенә түрдәге караватка урын хәзерләп, эшне тәмамлагач:

*Ахыры. Башы журналның 2 нче санында

— Әйдә, Мәрьям, тышта йөреп керик тә ятарбыз. Син дә арып-алҗып килгән кеше, — диде.

Ишегалдына чыктык. Мин барам, бер адым калмыйча, җиңги бара. Чиннек алдына килеп туктадык. Эшебезне тәмамлап, өйгә кергәч, җиңгидә үзгәрәк бер төс барлыкка килгәнен шәйләдем. Ничектер, миннән шикләнә башлады булса кирәк. Куркуга калдым. Чынлыкта, бер-беребездән мин дә, ул да куркабыз төсле сизелә иде. Җиңгинең куркуын мин куып таратырга тиеш булсам да, булдыра алмыйм инде, әлбәттә.

Урынга яттык. Җиңги унлы лампаны сүндермәде, тик беркадәре басып кына куйды. Мине бу да бик гаҗәпләндерде. Җиңги минем йокымны саклый булса кирәк. Дөресендә, ул мине сакларга бик тиеш. Үз-үземне шундый бичара бер ятим кыз итеп күрсәтүемә беркатлы кеше дә ышанмас шул. Мин билгесез, әллә нинди кеше бит. Хуҗасын суеп, йортын талап китүчеләр юкмыни бу дөньяда?! Ни булса, шул — җиңги шикләнмәсен өчен, үз иркем белән ныклап йокларга булдым.

Юлда арыткан да иде, каты йокланылган. Уяндым. Җаным табан астына йөгерде — ничек булгандыр, «абзар капкаларым» шар ачык. Ә җиңги изрәп йоклый — шау-гөр килеп, тын алып ята. Буласы хәл булган инде. Белмәмешкә салышып, тыныч кына ятам. Әгәр дә җиңги эшне зурга җибәрергә теләсә, ничек кенә булса да, качармын, дип фикер тупладым. Борчу эчендә ята торгач, тагын йоклап китканмен. Иртән уянганда, җиңги торып самавырын куйган һәм кичтән калган ашларны, итләрне җылыткан. Һәнүз йоклаган булып ятам. Җиңги кырыма килеп, янбашымнан йомшак кына селкетеп алды:

— Йокың туйдымы? Тор инде, Мәрьям. Чәй эчеп алыйк… — Тавышы ниндидер иркә һәм моңсу иде.

— Чыннан да арыганмындыр ахры. Бик тәмле итеп, бик каты йокладым. Бөтенләй кайда йоклавымны да белмәдем, — дип, урынымнан тордым һәм комган тоткан булып, тышка чыктым. Таң яңа гына беленгән иде. Мин кереп, юынып, өстәл кырына утыргач:

— Нинди төшләр күрдең? Саташмадыңмы? — дип сорады җиңги.

— Бик тәмле итеп йоклаган чагында бернинди төш тә күрмим мин, җиңги, — дидем.

— Бу төндә төшемдә бик гаҗәп нәрсәләр күрдем, — диде җиңги.

Куркудан үз-үземне оныта яздым һәм тотлыгып:

— Булыр, җиңги. Кайчакларда йокларга ятканда «Әгузе бисмилла» әйтеп яту онытылып китсә, җеннәр-шайтаннар саташтыралар, дип, абыстайдан ишеткәнем бар иде, — дигәч, җиңги кычкырып көлеп җибәрде һәм көлүен дәвам итеп:

— Чыннан да, мин үткән төнне бисмилла әйтеп ятарга гел онытканмын. Мине төн буена шайтаннар саташтырып чыкканнар икән, — диде. Мин аннан күргән саташуларын сөйләвен көттем. Сизәм, курку катыш оялуымнан йөзләрем кызарды, тәнемә тир чыкты. Ләкин җиңги күргәннәрен сөйләмәде. Бик уңайсыз хәлдә калуымны тоеп булса кирәк, сүзне шунда ук икенчегә борды һәм чын-чынлап мине кыстап ашатырга кереште. Аның мине куркытырга теләмәве сизелә иде һәм мин дә тынычланырга тырыштым.

— Мәрьям, — диде җиңги, — бүген керләр юып алырбыз. Синең дә өс-башларың керләнеп беткәндер. Киемнәреңне алыштырырсың, кичкә мунча ягарбыз. Эшне өс-башны чистартудан башларбыз, — диде.

— Шулай итәрбез, җиңги, — дидем боек тавыш белән. Җиңгинең хәзер үк

түгел, әкренләп-әкренләп киләчәк өчен төрле тозаклар корачагы мине ул хәтле куркытмыйлар. Бәлки, бу җиңги белән булачак алыш-биреш эшләре минем моңа хәтле Анюта җиңгидә яшәгәндә уйланылган татлы хыялларымның җимеше булып куймасын. Егетлекне тыштан яшереп булса да, эчтән яшереп булмый шул. Хисләр кабынып китеп, нидер тели, очына, шашына, дулый... Ашыгып, йөгәнсезләнеп китүдән бик сак булырга кирәк дип, үз-үземә акыл бирәм. Җиңги менә дигән — кызлар кебек бик чибәр, таза хатын.

Шулай да ул мине йоклаган вакытымда нәрсә уйлап тикшерде икән? Инде үземне тәмам хатын-кызларча йөрергә күнектем, дип уйлый идем. Әле Анюта җиңги белән очрашканга кадәр берәүнең дә: «Син хатын-кызлар киеме кигәнсең», — дип әйткәне булмады. Кем генә булмасын, барысы да «кызым» дип эндәштеләр һәм эндәшәләр. Ә бу җиңги мине тоткан да тикшергән. Үзе белән бер түшәктә ятмасам да, тикшергән. Авдотья кебек чүбек күкрәккә генә һушы китеп калмаган. Бар җиремне дә тикшергән. Бу хәл мине чамадан тыш гаҗәпкә калдырды. Кичә кич үзенә асрауга алыр өчен ничек тырышты ул! Теше-тырнагы белән ябышуыннан ук каушап калган идем. Күрәсең, мине фаш итү теләге бөтенләй юк. Һәрьяклап файдаланырга теләведер, диясе генә кала. Ни гаҗәп, бу хәл мине артык куркытмый.

Җиңги ниләр уйлый торгандыр, анысы әлегә караңгы. Тик ул минем егет кеше икәнлегемне белә! Онытылып, әллә инде серле һәм ягымлы караш белән:

— Мәрьям, — дип эндәшүе үк иkenче. Ул гына да түгел, һәрчак төрләндереп, «Мәрьям, акыллым...», «Мәрьям, дустым», «Мәрьям, сөеклем» — дип эндәшә. Миңа сокланып карап туя алмый.

Өйрәнгән яңа хезмәтләрем файдага ярый. Бөтен шартын китереп, селте кайнаттым. Җиңги кызлар күлмәге бирде, караңгы җиргә — гөлбәчкә — кереп, өс алмаштым. Җиңги мине һич борчымады. Шаярып та, мин өс алмашкан җиргә килмәде генә түгел, миңа таба күз дә салмады. Белгән нәрсәсен ул ник яңадан тикшерсен? Аңа бу «белгәне» белән дөресен файдалана алуы гына кирәк. Чибәр җиңги хакында мин шулай уйладым. Җиңгинең миңа алмашка биргән күлмәге үзенең кыз чактагы күлмәге булды бугай. Биш катлы бәби итәк, иңсәләре кабарынкы һәм чатыр кебек итеп, түгәрәкләп, канатлар чыгарып тегелгән. Үзе шундый җыйнак.

— Менә, ичмасам, чынлап та кызлар кыяфәтенә кердең, — диде. Димәк, җиңги белән минем арада аерма калмады. Ачу да кабарды, имеш, мин моңа хәтле кызлар кыяфәтенә кермәгәнмен.

Шәп итеп керләр юдым һәм мунча яктым. Байларның байларча, коры әрдәнәсе, су алу өчен шунда гына коесы — барысы да хәзер. Җиңгинең олы гәүдәле ике аты бар. Ләкин атларга тәрбия җитмәве әллә кайдан күренеп тора. Сыер һәм сарыклары утар тулы, аларны рәтләп караучы да юк. Ындыры тулы иген эскертләре, ә малларга салам юк. Бу хакта мин җиңгигә бүген үк әйтеп куйдым. «Иртәгәдән дә калмыйча, бер эскертне сугарга кирәк, җиңги», — дигәч, ул да каршы әйтмәде. Ашлык сугучыларны эзләргә чыгып китте. Озак та үтми, кешеләрне табып кайтты, җиңен сызганып күәс изәргә кушты. Күәсне изеп, ындыр табагын чистартып куйдым. Кич булды, мунча җитеште. Җиңгинең утыннарын китереп бирүче Гыйльми бабай бар икән. Ул аны мунчага чакырды. Карчыгын ияртеп, Гыйльми бабай килде. Мунчадан соң Гыйльми бабайлар аш ашарга өйгә керделәр. Гыйльми бабай сүзчән кеше түгел икән.

— Егетләр шикелле нык кыз. Кайсы авылныкы бу? — дип кенә сорады. Минем килүем хакында җиңги сөйләп бирде. Гыйльми бабайлар аш ашаган арада,

җиңги миңа мунчага барырга кушар инде, дип уйласам да, эндәшмәде. Бергәләп кичке ашны ашадык. Гыйльми бабайлар киттеләр. Аларны озаткач:

— Ярар, Мәрьям, — диде җиңги берни булмагандай. — Бергәләп мунча кереп кайтыйк. Аннан соң самавыр куеп чәй эчәрбез, — диде.

— Өйне бикләп китәрбезмени? Мин ярлы кешеләр йортында да, хуҗалар мунча кереп чыкканчы, өйне саклап кала идем...

— Ярлы кешеләрнең йортларын бассалар, бернәрсәсез калалар. Минем Аллаһка шөкер, алып китеп бетерә алмаслар, —дип көлеп куйды. Тик шулай да үзе белән мунчага барырга теләмәвемә артык аптырау күрсәтмәде. Йөземдә борчылган төсемне күреп, башка кыстамады, берүзе генә китте. Бары кайтуына самавырны кайнатып торырга кушты. Аның: «Алып китеп бетерә алмас», — дигән сүзе миңа да кагылган кебек иде. Чөнки мин әле сыналган таныш кеше түгел бит. Ул мунчага киткәч, йортны талап, мин качсам... Җиңгинең кыю тәвәккәллеге монда да нык сизелә. Моңа хәтле белмәгән-күрмәгән кешегә йорт ташлап, мунчага китү өчен тәвәкәллек кирәк, әлбәттә.

Самавыр кайнап чыкты. Җиңги мунчадан кайтты һәм миңа барырга кушты.

— Курыкмыйсыңдыр? — дип сорап та куйды.

Мунчадан соң чәй эчәргә утырдык. Җиңги сүз башлап:

— Синең, Мәрьям, бер дә күңелең күтәренке түгел. Ташлап торырга булмыймы инде ул кайгыларыңны? — диде.

Мин дә аңа:

— Чәйдән соң бөтен кайгыларымны ташларга, дип уйладым әле, — дигәч, җиңги, сүземнең чын мәгънәсен аңлап җиткермичә, көлеп җибәрде. Көлә-көлә:

— Таныштык бит инде. Мин дә, син дә! Бер-беребездән ятсынып торырга урын калмады. Мунчага бергә бармаган булдың, — дип, башында кайнаган уйларын җиңги бер тында әйтеп бетерә язды.

Чәйдән соң мин матур тавыш белән җырларга керештем. Җиңгинең һушы китте. Ул мине мактап алды.

— Бер грамафон алдырырга дигән уем да бар иде, син булгач, миңа грамафонның кирәге калмады. — Әкрен тавыш белән миңа кушылып җырлый башлады. Аның да тавышы матур иде. Шулай җырлашып, төннең күп кенә өлешен үткәрдек. Бай хатын кул эше белән шөгыльләнми. Шулай булгач, эч пошыргыч тик утырудан котылдым мин.

Җиңги йокларга урын хәзерли башлады.

— Бүген ике урында йокламыйбыз. Бер урын икебезгә дә җитәр, — дип кистереп әйтте һәм мамык түшәкләрен, мамык ястыкларын кабартып салды.

Аның талпынып-талпынып урын хәстәрләвен көлемсерәп карап тордым. Эчемнән:

— Үлемнән алда актык минутлар! — дип көрсенеп тә куйдым. Җиңги мамык түшәккә чумып ятты һәм лампаны сүндерергә кушты. Лампаны сүндереп, җиңги кырына мин дә яттым. Җиңги минем төрле җирләремнән кытык эзли башлады. Чынлап та, мин кытыклауны белми идем. Тәнемне катырып тик ятам. Мин җиңгигә төрлечә ялына-ялвара башладым. «Зинһар уен уйнамасана», — дим.

— Син, — диде җиңги калтыранган тавыш белән, — миннән шикләнмә. Егет кеше икәнлегеңне баштан ук белдем. Сине кешеләргә начарлык эшләүче явыз качкын дип уйламыйм һәм курыкмыйм да, шикләнмим дә. Син сугышка алынудан куркып, шулай кызлар сурәтенә кереп йөрисеңдер, дидем. Чыннан да, сине бу һөнәрең белән мактарга кирәк. Курыкма, сине фаш итәсем юк. Алдагы көннәрдә

сине үземнән дә ныграк саклаячакмын. Үз-үзеңне генә тота бел, йөгәнсезләнмә. Качышлы уенын бетерик, арада сер калмады. Чамалыйм, син ак күңелле егет. Бәлки, сөйгән кызың да булгандыр. Ләкин сиңа хәзер үз башыңны бу һәлакәтле сугыштан коткарып калу кирәк. Акылың алтын синең, моны ныклы егетләр генә эшли ала, — дип миңа тагын да сырыла төште...

Җиңгинең акыллы сүзләре йөрәккә май булып ятты. Аннан яшеренер җирем калмаган иде инде. Шулай да аңа үпкәләбрәк берничә сүз әйттем. Ул аңлатып сөйләнде. Беренче күрүендә үк күңеленә шик йөгергән икән. Тавышым аңа кызлар тавышы булып яңгырамаган. Шулай да мин һаман бөтен серне чишмәдем. Кайсы авылныкы икәнен тәгаен дөрес әйтмәдем, чын исем-фамилиямне дә яшердем. Кыскасы, бу төнне мин җиңги белән бер ястыкка яткач, аю егардай мәрдәнгә әйләндем, иртән торуга, кабат Мәрьям булдым.

Тормышым күңелләләнеп китте. Кайчак ачы-төчеләре дә булгалады. Болар хакында сөйләмичә булмый, егетләр... Аллага шөкер, дияргә кирәк, җиңги мине нык саклады — өстемнән кызлар киеме төшмәде. Утардагы атларны яхшылап тәрбияли башладым. Язгы сабан туйларына җиткәндә йончыган булып күренмәсеннәр, дим. Шулай да мине җиңги ашлык сугарга бервакытта да чыгармады. «Кеше шикләнмәгәе», — ди. Ул да курка серем чишелүдән. Көч кызганыч түгел, җан кызганыч. Җиңги дә шулай уйлый.

Вакыт уза. Матур яз җитте. Кояш кыздыра, карны эретә. Эшләкиләр сайрый. Рәхимә җиңги бигрәк тә шат. Аның минем аркада бар эше дә җитеш. Кешеләр белми генә торсыннар, яшь кенә егет-кияве дә бар бит аның! Бигрәк тә дәртле, мәхәббәтле, гашыйк кияү булып чыкты бу! Кияү һәрвакытта аның күзләренә генә карап тора, җитмәсә, кулыннан бөтен эш килә, тырыш нәрсә. Байлыгы да җитәрлек. Әйткәнемчә, ике аты, ике үгезе, өч сыеры бар. Киләчәге дә өметле: абзарда маяга калган казлары, үрдәкләре дә йомырка салып, бәбкә чыгарырга хәзерләнәләр. Борай, бодай оннарының исәбе-хисабы юк. Язгы сабан өчен дүрт-биш йөк ашлыкны үзем тартып куйдым. Җиңги өч сыер гына сава. Вак терлекләре дә бик күп. Сүз арасында:

— Мәрьям, син булмасаң, минем терлекләрем кырылып бетәләр иде, — ди. Бик дөрес шул. Иртәдән алып кичкә хәтле гел терлекләр арасында йөрим. Ашатам-эчертәм. Йорттагы аш-су хәзерләүләр, килүче-китүчеләрне сыйлау, Коръән ашлары үткәрү — андыйларны Рәхимә җиңги үзе башкара. Ул миңа булган мөнәсәбәтен ят кешеләр бар чакта һич сиздерми, бу эшне иң югары осталык белән башкара. Мин бер асрау кыз — бетте-китте! Җиңгинең кунаклары миңа сокланмыйча калмый. Кем генә булмасын:

— Бигрәк уңган кыз, таштай нык, егетләр кебек һәммә эшкә дә оста, үзе карусыз, шундый күндәм. Бар икән дөньяда булдыклы балалар! — дип, мине мактыйлар. Арада кайберләре арттырып та җибәрәләр. — Ике улымның берсе кайтса иде, кайткан көнне үк Мәрьямне килен итеп ярәшер идек, — диләр. Алардан шул сүзләрен ишетү белән, оялган булып, эшемә чыгып китәм. Йортта нәрсә булса да бер эш табып кына торам. Кыш һәм яз көннәрендә җиңгине туган-тумачалары берничә тапкыр кунакка чакырсалар да, бармады.

— Өемдә бик яхшы кунак мин. Күңелем ачкычы — йөрәк баскычым үз янымда. Күтәренке күңелемне төрле куркынычларга куеп, йортымны ташлап йөрисем юк әле, — дип кенә җибәрә үзара сөйләшеп-сөешеп ятканда. Ә чакыручыларга:

— Дөресе, Мәрьямгә ышанам, рәхәтләнеп, кунакка китәр идем. Шулай да асрау асрау инде ул. Һичбер вакытта да үз кешең була алмый, — дип җавап бирә.

Җиңгинең бу сүзләре бик акыллы һәм бик төпле булуын да мин яхшы аңлый идем. Китеп югалуымнан курка ул. Вакыт-вакыт:

— Кулымнан ычкынып китмәгәең! — дип, сөйләнеп ала. Тагын бернәрсә бар — сер беленмәгәе, кешеләр алдында хур булмагаем, дип тә курка иде.

Язгы сабан коралларын кар эри башлау белән рәткә китереп куйган идем. Татар халкында тыныч чорларда хатын-кызларның сабан сөреп йөрүе гадәти эш булмаганга күрә, кырга китүемне бик гаҗәп иттеләр. Тик бу тыныч вакыт түгел бит, ил кырылып герман патшасы белән сугышып ята. Озын күлмәкне ыштан бөрмәсенә кыстырып, сабан сөреп йөрим. Миннән күрмәкче яшь киленнәр, кызлар да сабанга, тырмага йөри башладылар. Хәким бабайның өйдәге килене Сабира җиңги дә миңа ияреп йөри башлады. Мин аны ат җигәргә, сабан көйләргә өйрәтәм. Болай осталыгымны рус-керәшен арасында күп йөрүдән дип беләләр. Шунлыктан һәр эшкә оста булуымда гайре нәрсә күрмиләр. Җен кебек таза атлар белән мин ике күләм саен алтмышлыга бер дисәтинә җирне каплап кына куям. Ә өйрәнчек килен-кимчәкләр начар атлары белән ике күләмгә көчкә бер чирек яки бер ярты дисәтинә сөрәләр.

***

...Хәким бабайның өйдәге килене Сабира җиңги белән сабан сөрәбез. Рәхимә җиңги Хәким бабайның олы улы Галим абыйның хатыны булганлыктан, аларның җирләре Хәким бабай җирләре белән янәшә. Сабира җиңгинең атын җигешәм, сабанын көйләп бирәм. Шулай эшләр бергә булгач, ашау-эчү дә бергә. Дөресен әйтергә кирәк, хәзерләнгән ашамлыклар бертөсле булса да, пешерү ягыннан Рәхимә җиңги хәзерләгән ашамлыкка тигезләшми, әлбәттә. Рәхимә җиңги пешергән күмәч тә, сумсалар да тәмлерәк була. Сез моны Рәхимә белән дус булудан гына шулайдыр, димәгез. Ачуланып әйткәндә, Сабира җиңги Рәхимә җиңгигә караганда аюга охшаган. Ә Рәхимә җиңгине, алсуланып торган алмага яки иң чибәр мәк чәчәгенә охшатсаң да, чагыштыру аксый дип уйлыйм — Рәхимә җиңги чибәррәк булыр иде. Сез көләсез. Һәнүз шул. Сабира җиңги белән бергә эшлибез, бергә ашыйбыз һәм бергә ял итәбез. Сабира җиңги таза тәнле булса да, чибәр түгеллеген аңладыгыз булса кирәк. Мин Рәхимә җиңгинең асравы булгач, ул да миннән ятсынмый. Хәтта ял итәргә туктагач, чәч тарашабыз. Берберебезгә үләндер, кәстер ыргытышып, шаярып та алабыз. Яңгыр ява башласа, бер үк чикмәнне бөркәнеп, Сабира җиңгинең майлы тәненә сыланып та утырырга туры килә. Якында гына яшь малайлар, картлар да була. Алардан ерак йөрергә тырышам. Яшь малайлар авызыннан: «Мәрьям апа түгел, Мәрдән абый икән бу!» — дигәнне бер дә ишетәсе килми бит...

Сабира җиңги белән уйнап-көлеп эшләп йөргәнне Рәхимә җиңгигә ишеттергәннәр. Кырда уттай эш өсте булса да, авылда берне биш итеп, сүз балалатып йөрүче карчыклар беткәнмени? Рәхимә җиңгигә Хөсни әби сөйләгән икән. Ул аны гайбәт йөзеннән түгел, шәфкатьле, ярдәмче кешеләрне кызгана алуым хакында мактап сөйләгән. Хөсни әбинең бу сүзләре Рәхимә җиңгигә начар тәэсир иткән. Сабаннан кайтып кердем. Башка көннәрдәге кебек атларга башак хәзерләнмәгән, башакны хәзерләп, атларга ашарга бирдем. Өйгә кердем. Рәхимә җиңги сөйләшми. Элеккечә бөтерелеп тормый. Юыныйм дип кулга комган алсам, комган эчендә җылы су түгел, бозлы су да юк. Мин бик каты курка башладым. Чөнки хәзер инде башымнан яулыгымны тартып алып, шап итеп бүрек кигерәсе генә калды бит. Йөрәгемнең иң нечкә җиреннән чыккан ялварулы моңсу тавышым белән:

— И чибәр җиңгәм, матурым, гүзәлем, тормышымның тоткасы! Сезгә нәрсә булды? Кай җирем ошамады тагын? — дип иңрәдем.

Җиңги шуны гына көткән икән. Зәһәр белән тулган шешәсе шартлап, бөкесен атып җибәрде:

— Хәзер инде мин синең чибәр җиңгәң дә, матурың да, гүзәлең дә түгел. Син миннән туйдың инде. Минем иркәләүләремнең кадере бетте. Син хәзер кысыр хатыннарга сырыласың, — дип, үксеп-үксеп еларга кереште.

Ай-һай-һай!.. Бик каты бозганнар моны, төзәлер микән? Башта шундый уйлар гөжли. Аптырап торып булмый, ипләп кенә:

— Җиңги, зинһар өчен аңлат. Миңа ни өчен ачуланасың? — дип сорадым.

— Сабира белән нәрсә эшләдең? — диюдән башка бер сүз дә әйтмәде Рәхимә. Сүз чираты миндә иде. Барысын да сөйләп биргәч, җиңги акылына килде һәм гафу үтенеп, мине үбеп торганда, әлеге йөзе кара Хөсни җиңги ишек төбендә басып тора иде.

— Исәнмесез, балалар, күңелле тормышыгызга шаклар катып торам инде менә! — диюе булды, җиңгәм яшь боландай читкә атылды.

Искәрмәстән, шаркылдап көлеп җибәрдем.

— Мин дә бер генә үбим инде, җиңги, Хөсни әби мин үпкәнне дә күрсен, — дидем.

Хөсни әби тагын ачыла төшеп:

— Һәй уңган бала, шаян кыз!.. Менә сине мин дә бер генә тапкыр үбәр идем, үпкәләвеңнән куркам, — дигән булды.

— Мин үпкәләүне белмим, әби. Иркәләнеп үсмәдем. Иркә халыкларда гына була бугай үпкәләү гадәте, — дидем.

— Акылың да бар шул, кызым. Бу хәтле акыллы булырсың икән... — диде һәм үз йомышын исенә төшереп, Рәхимә җиңгине өйалдына алып чыгып китте.

Рәхимә җиңги, Хөсни әбине озатып кергәч:

— Мәрьям, син миннән дә үткеррәк икәнсең. Үземне моңа хәтле иң үткен хатын дип саный идем. Миңа үпкәләвеңне ничек шунда ук оныта алдың? — диде.

— Син дә шунда ук оныттың бит, җиңги. Миңа гаҗәпсенәсең...

Аннан соң сүз Хөсни әбигә күчте. Рәхимә җиңги әбинең нигә керүен аңлатты.

— Хөсни әби әгәр ике улымның берсе сау-сәламәт йөреп сугыштан кайта икән, Мәрьямне шул көнне үк киленлеккә ярәшер идем, ди. Сине эшкә сорап килгән. Иртәгә Мәрьям берәр дисәтинә җиребезне сөреп бирә алмас микән, ди. Бодаебыз соңга кала. Башкаларын карт үз көченә күрә чәчәр иде, дип әйтә, — диде.

— Син нәрсә дидең соң?..

— Мәрьям белән киңәш итәрмен. Ул авырсынмаса, ат көчләрем кызганыч түгел. Үзебезнең иртә чәчәсе ашлыкларыбыз күптән чәчелеп бетте. Аннан соң да әле бер дисәтинә каенаталарныкын чәчеп бирдек, дип әйттем.

— Алай киленлеккә алмакчы булгач, сөрермен, җиңги, — дидем.

Казылык турап пешергән ашны көлешә-көлешә ашадык.

— Чынлап, Сабира тәре белән шаярып йөрүеңне ишеткәч, бик ачуым килгән иде. Гел хата ачуланганмын икән, гафу ит инде, Мәрьям, — диде җиңги яратып карап.

— Тегеңә дә, моңа да сер ачып йөрергә минем башым ике түгел бит. Җаным кадерле, башымның саулыгы кыйммәт. Синнән дә назлы кеше бар микән ул? Тик торганнан сиңа хыянәт итсәм, көн күтәрмәс — якты дөньядан туйганым юк әле. Хәер, башымда хатын-кыз кайгысы түгел иде бит миндә. Теге чакта юл

йөреп, арып китүем сәбәпле, түзә алмыйча йоклап кына тотылдым. Ләкин бу тотылуыма үкенмим. Сиңа күп рәхмәтләр укып йөрим. Һәр эшне сөенеп эшлим. Башымны моңарчы ашамадың. Соңгы көннәрен Ходай үзе белсен. Шуны беләм: сине беркайчан да үпкәләтмәскә тиешмен, — дидем.

Шулай да хатын-кызлар чыш та пыш киләләр, җиңги хакында сүзләр бик каты куера башлады. Ире Галим белән өч ел торып, Рәхимәнең авырлы булганы юк иде, менә хәзер йөккә узган икән дип, очраган бер хатын-кыз миннән сораша.

— Әллә аның бер-бер яшерен сөяркәсе бар микән? Бергә торгач, син яхшы беләсең инде. Яшермә инде, әйт, — дип йөдәтәләр. Хәтта аерым аулакларда Хәким бабай карчыгы да шул сорау белән тинтерәтә башлады. «Белмим, мин хезмәтче генә, хуҗа кешедә катнашым юк. Шикләрегез хакында бернәрсә дә әйтә алмыйм», — дип котылырга тырышам. Миңа ышанмыйлар. «Рәхимә аны куркыта икән, серләре бер икән», — дигән сүзләр дә ишетелгәли. Йөрәгемне таракан кимерә. Ләкин җиңги бирешми, бик нык тора, һич курыкма, бернәрсә дә булмас, ди ул. Үзенең көмәнле икәнлеген ире ишетсә, шатланачагын гына әйтә. Хәтта, берсендә, уйнапмы-чынмы:

— Ичмасам, бер ару гына кешедән бала ясатып алмыйсың, — дип тә куйган чагы булган.

Рәхимә җиңги, чынлап та, бер дә таушалмаган, кыз чактагы буй-сыннары һәнүз шул килеш. Кызлардан да чибәр иде. Минем башта уйлар кайный. Рәхимә җиңгигә ышанып бетү — саламга ябышып, суга батмаска тырышу белән бер. Белмәссең, хатын-кыз бит ул, юк өчен генә ачуланыр да, кемлегемне фаш итеп тә куяр. Алдагы көннәрдә тыныч кына яшәвемә ышаныч кимеде. «Батыр үлеме марҗадан», диләр бит. Курку көчәя, үз шәүләм үземнән калмый, торган саен зурая, озыная бара. Андый чакта зиһен томалана...

Язгы сабаннар бетү белән, пар җирләре сөрергә керештем. Көн кызгач, өйгә кайтам, көн сүрелү белән, басуга куна барам. Урман кырындагы басу янына бөтен авыл сабанчылары кунарга җыелалар. Картлар һәм үсмер малайлар, кызлар-киленнәр булалар. Зур итеп ут ягабыз, кайсы аш пешерә, кайсы чәй кайната. Төрле сүзләр сөйлиләр: сугыш хәлләре, тормыш авырлыклары, толлар, ятимнәр хакында, кайгы-хәсрәт, ачлык-җимереклек — берсе дә калмый. Салих бабай сугыш хакында болай дип сөйләде:

— Николай Николаевич Романов болай ди икән әле: «Алтмыш яшьтәге кешеләр карт түгел, унбиш яшьтәгеләр яшь түгел. Менә мин җитмеш биш яшемдә булсам да, сугыш хезмәтемне кимчелексез үтим», — ди икән. Унбиш яшь белән алтмыш биш яшь арасындагы мужикларның сугышта кырылып бетүләре министрларга файда гына китерә шул. Аларның итәге янмый, безнеке яна. Мужик халкы кырылып бетә, авыллар җимерелә. Ләгънәт төшкән патшага, сенат-санатларга бәйрәм бу сугыш. Сугыш байларның кесәләрен калынайта шул. Безнең мужикларның күбесе шуны аңлап җиткерә алмыйлар әле. Колакка ирешкән сүзләргә караганда, эшчеләр патшага да, санатларга да, боярларга да, купецларга да каршы икән, диләр. Завод эшчеләре әйтә икән, ди,патша байларны яклап, шундый һәлакәтле сугышларны чыгара да тора икән. Патша һәм аның яклы булган түрәләр, байлар булмаса, сугышлар да булмас иде, дип әйтәләр, ди. Патшаны төшерергә кирәк, байлардан властьны алырга кирәк, дип әйтәләр, ди. Бу хакта яраланып сугыштан кайткан бер солдат сөйләде миңа, — дип, Салих бабай сүзен очлады.

— Патша беткәч соң?.. Рәчәйне кем җитәкләр? — дип кыдрачланды Сәйфи

бабай. Аңа Салих бабай ачык җавап бирә алмады. Бераз уйга калып торганнан соң:

— Правительство, хөкүмәт җитәкләр, дип әйтә теге солдат, анысы нинди кеше була торгандыр, мин аңламадым бу хәтлесен, — диде.

Картларның сүзләре бетте. Тавыш басылды. Арыткан, патша кайгысы юк монда — хырылдап йоклау башланды. Һәркөнне алдан торып, атларымны тотып, сабан сөрә торган җиргә китә идем. Бүген Салих бабайның гаҗәп тирән сүзләреннән уйга чумдым. Көн кыза башлаганда җирем сөрелеп тә бетте. Кайтыр юлга чыктым. Авыл ерак булмагач, рәхәтләнеп сузып җырларга да өлгермәдем, кайтып җиттем.

Өйдә мине каршы алучы булмады. Башка көннәрдә Рәхимә җиңги купшы киемнәрен киенеп, ачык йөз, тәмле сүзләр белән каршы ала иде. Бу хәл мине куркуга калдырды. Шулай да җиңги өйдә булса кирәк. Нindидер кунак бар төсле күренә. Нинди кунак микән соң ул? Мин атларны туарып, коедан салкын су эчердем һәм лапас күләгәсендәге улакка башак болгатып, атларны ашарга куштым. Мин юынып торганда яныма җиңги килеп чыкты. Аның йөзендә шатлык белән катнаш сәер төс бар иде. Дөресен әйткәндә, ул мине куркытмаска тели иде. Ул миңа елмайган килеш күз кысып, каш сикертте:

— Нихәл, Мәрьям, кайттыңмы? Үткән кичне Галим абыең кунакка кайтты. Әле өйдә юк. Бабаңнар чакырып алырлар, — диде.

— Бик әйбәт, җиңги. Озак куанычка булсын...

— Чәй кайнаган. Өйгә кер, Мәрьям, — диде җиңги.

Мин өйгә кереп чәй эчтем. Чәйдән соң купшы киенеп, бер көянтә чишмә суы алып кайттым.

— Ял ит, Мәрьям, башкасына үзем дә җитешермен, — диде җиңги. Ул аш пешерә иде. Казанда симез тәкә ите кайный.

Лапаска чыгып, кабык сәндерәгә менеп яттым һәм бик тирән уйга чумдым. Бу җиңгинең ире юкка гына кайтмагандыр. Өч ел буена үзеннән авырлы булмаган хатынын ул «буш» калдырмас. Мине дә тикшертер һәм табар. Бетте минем баш. Мәрьям дигән исемне минем белән бүген үк җиргә күмәрләр, дигән уй тынгы бирми. Яткан урынымнан торып утырам. Өй эчендә шау-шу купмадымы икән дип, еш-еш тыңланам. Кич булуны ашыгып көтәм. Билгеле, андый чакта көн өстенә көн ялганган кебек, вакыт озак үтә. Җиңги, аш мәҗлесе җыеп, муллаларны китерәбез дигән иде. Ял итүемнең рәте булмады. Башымны гына диңкеттем. Җанны төрле уйлар кимерә. Сәндерәдән төштем, юындым, киендем, кызларча купшыландым. Тагын бидрә-көянтәләремне алып, чишмәгә киттем. Үзем соңгы минуткача «кыз» икәнлегемне истән чыгармаска тиеш мин. Җиңги белән күзгә-күз карашмаска тырышам. Бакчадан ашка турау өчен яшел суган җыйнап кергәндә, Галим абый миңа каршы чыкты. Юан, таза гәүдәле, төскә Хәким бабайның карчыгынарак охшаган. Зур саргылт мыеклы кеше икән.

— Исәнме, сеңлем, — дип, алдан үзе кулын сузды.

— И, Галим абыкаем, исән-сау кайттыңмы? — дип, ак алъяпкычымдагы суганны күкрәгемә кысып, ике куллап күрештем. Болай караганда, Галим абыйның йөзендә явызлык эсәре күренми. Ул алдында чибәр кыз торуын күреп, кәперәя төште.

— Хуҗалыкны таркатмагансың. Монда синең өлеш зур икән, рәхмәт, сеңлем, — ди бу миңа.

Безнең янга Рәхимә җиңги чыкмады. Ул шик-фәлән булмагае, дигәндер. Өйдә миңа тиешле эшләр бетте бугай.

— Парга сөреләчәк җирләрең сөрелеп бетте, җиңги. Иртәгә нәрсә эшләргә кушасың? Атларны болынга җибәримме? — дидем мин.

— Атларны әрәмәлеккә илт, иртәгә эш юк, — диде җиңги. Ашка җыйнала калдылар. Мин атларны әрәмәлеккә алып киттем.

...Болынга бардым. Матур әрәмәлек эченә атларымны утлауга җибәрдем. Куе булып үскән бер зирек агачы күләгәсенә кереп утырдым. Башымнан үткән барлык хәлләремне бер-бер артлы исемә төшердем. Әти-әни, туганнарым һәм газиз авылымны сагынып җырладым. Алдагысы хакында төрле куркынычлар белән уйландым.

Бу җиңги белән күп вакыт сердәш һәм тату торуым, көтмәгәндә үз иренең кайтып килүе, сабан сөреп кунып ятканда, Салих бабайның сөйләгән сүзләре — бу җиңгидә моннан соң да шулай тормыш итә алмавымны күрсәтәләр иде. Шулай булгач, бүгенге мөмкинлектән ныклап файдаланырга кирәк, дигән фикеремне ныгыттым. Бу йортта җиңгинең ире белән — ике тәкә башы булып, бер табакка сыймабыз. Минем тарафымнан алыш-биреш төгәлләнгән, теләгәнчә тикшерсеннәр, дигән карарга килеп, бу авылны, сөекле җиңгәчәемне, туачак сабыебыз белән бергә калдырып, ташлап китәргә булдым. Үзем ял итеп, төрле уйлар белән утырган сердәш зирек агачының бер ботагына ике каеш йөгәнемне элеп куйдым. Ничә айлар минем моңлы күңелемне юатып йөргән атларыма соңгы саубуллашу караву белән күз ташладым. Керфек арасыннан бөртек яшьләрем тәгәрәштеләр.

— Сау бул, Сараш авылы, сау бул йомшаклыгың, үткенлегең, юмартлыгың, матурлыгың белән мине, берчә җылы-йомшак, берчә каты әчеле-төчеле иркәләүләрең белән моңа хәтле сау-сәламәт саклаган җиңгәм! Моның өчен һәрвакыт рәхмәт укырга бурычлы мин сиңа!

Озак юанып торасы юк, атларны калдырып, туп-туры руслар яши торган авылга таба юл тоттым. Кешеләр йөри торган юлдан түгел, урман эченнән киттем.

***

Көн сүрелде, кояш баеды. Урман юлыннан барганда, Рәхимә җиңгигә атап, түбәндәге җырларны җырладым:

Өзелеп-өзелеп сөйдең, җиңгәчәй,
Ак өеңдә эчтем соңгы чәй.
Кайталмыйм сиңа, өзелеп көтмә,
Рәнҗеп калма, матур җиңгәчәй.

Сабаннардан кайткач, очрашканда,
Сүзләрең бар иде әйтәсе.
Көтәлмәдем, кирәк булды
Сау башымны алып китәсе.

Хуш, исән бул, бәгърем, җиңгәчәй,
Бергә утырып эчәлмәдем чәй.
Син ул хәтле үк түгелдерсең,
Миңа килде бигрәк моңлы җәй.

Рәнҗеп калма, бәгърем, бәхил бул,
Бәлки сине тагын күрәлмәм.

Матур кара чәчләреңне
Толымнарга сузып үрәлмәм.

Онытмамын, җаным, онытмамын,
Син яшәрсең минем уемда.
Егетлегем калды куеныңда,
Кул эзләрем булыр муеныңда.

Таң атканчы, ял итәргә туктамыйча, унбиш чакрым урманны үттем. Урманны үтеп, өч чакрым барганнан соң, телеграмм баганалары тезелеп киткән канаулы юлга чыктым. Бу юл шәһәргә илтә иде.

Кояш күтәрелде һәм көн кыза төште. Арытты, йокым килә башлады. Авырайдым. Юлның ул ягыннан әрәмәлек сузылып килә. Мин әрәмә буена төштем. Үзәнлектән елга ага икән. Елгадан су эчтем һәм битемне, күзләремне юып, күләгәлеккә ятып йокладым.

Берзаман печән эскертләүче кызлар һәм картлар тавышына уяндым. Алар руслар икән. Русча сөйләнәләр. Урынымнан торып, янә юындым һәм өс-башларымны төзәттем. Олы юлга кире менеп һәнүз алга киттем. Ниһаять, зур чиркәүле рус авылы күренде. Көн төштән узган иде. Авылга килеп җиттем. Сусадым, карыным ачты. Авыл урамыннан хәтсез килгәч, бер йортка кердем. Ишек төбендә бер карт чабата үреп утыра. Аның тирәсендә унлап бала бар. Юкә кабыгыннан уенчык ясап, мәш киләләр, бер-берсен үчекләп, үртәшәләр. Карт, баш күтәрмичә генә, балаларны тавышларыннан танып эндәшә тора:

— Чү, Иван! Үртәмә, Дунька! Елама, Ленка!

Балалар бабайның кисәтүле тавышын колакларына да элмиләр.

Белгән урыс сүзләремне эшкә җигеп, бабайдан исәнлек сорадым. Ул, башын күтәреп, эчкә баткан күзләре белән миңа карады. Бер карауда татар кызы икәнемне аңышып, үзе белгәнчә татарчалап сорый башлады:

— Кызым, сиңа нәрсә кирәк? Нәрсә эшләп йөрисең? — диде.

— Эш эзлим, бабай, — дигәч, бабай калкынып куйды.

— Эшче кирәк кешеләр күптер. Эш күп булса да, без үзебез эшче тота алмыйбыз, — диде бабай балаларга ишарә итеп. — Гаилә ишле бит... Безнең авыл бик зур. Йөре, сораштыр. Эш табылыр.

Карт яныннан чыккач, авыл уртасында базар була торган җиргә килдем. Базарга каршы зур йортларның берсенә кердем. Өйдә бер яшь кенә хатын утыра. Хәл белешкәч, хуҗа хатын миннән сораштыра башлады. Хатын бер генә сүз дә татарча белми икән. Минем дә теге чактагы урысчам онытылып бетә язган. Шулай да эш эзләп йөрүем хакында аңлата алдым. Ул, гозеремне аңлап, мине каядыр алып китәргә җыена башлады. Куркуга калдым. Әллә үрәтник каршысына алып барамы бу марҗа? Ул мине ияртеп, күршедәге зур йортларның берсенә алып керде. Монда мундир кигән кеше каршы алыр инде дисәм, зур трубкасыннан төтен бөркетеп утырган ак сакаллы бер картны күрдем. Әлеге хатын хәлемне картка сөйләп бирәч, карт минем белән саф татарча сөйләшә башлады:

— Нихәл, кызым? Эш эзлисеңме?

— Бабай, дөньялар шушы хәлгә калдырды. Кичәдән бирле ашаганым юк. Теләнеп йөрергә оялам. Сугыш аркасында бөтен дөнья гарипләр, балалар, толлар, ятимнәр белән тулды. Аларны тәрбияләргә дә күп кирәк. Кыз бала булсам да, таш ватардай тазалыгым бар. Ни кушсалар, иренмичә, теләп эшлим. Минем

дә бердәнбер абыем сугышта һәлак булды. Йорт көтәргә рәтем калмагач, ил өстендә йөрим…

Бабайга сүзем ошады. Шаяртып:

— Сиңа, кызым, берәр егетне эләктерергә кирәк, кияүгә чыксаң, болай интегеп йөрмәссең, — дип көлә башлады.

— Шәп егетләр бары да сугышта бит, бабай, бик барыр идем, булыр-булмас белән кушыласым килми, — дип, бабайга кушылып, елмайгандай иттем.

— Шаярып әйтәм, кызым, үпкәләмә. Менә бу апаң — минем киленем була. Аның кияве дә сугышта әфисәр булып йөри. Аңа эшче кирәк. Син аена күпме сорыйсың? — диде.

— Хак сорап эшкә кергәнем юк, бабай. Эшләткән хуҗа эшемне яратса, ачялангач итмәсә, шул бик җитәр иде.

— Сүзеңә ышанырга була, кызым. Өс-башларың бик чибәр. Моннан алдагы хуҗаң сине бик тәрбияләгән булса кирәк. Әгәр дә хуҗаңны талап, качып китмәгән булсаң… Кыяфәтеңә карап әйтүем. Числы күренәсең — тырышып киендергәннәр сине!.. — Бабай, кинәт исенә килгәндәй, күзен чепиләндерде. — Ә нәрсә эшләп, уттай эш өстендә ул хуҗаңны ташлап, монда килдең? Кайсы авылныкы син?

Бабай һушлы күренә, йөрәгемә төшә бит болай булса. Мондый сорауларга җавап хәзерләмәгән идем. Шулай да кыю гына җавап бирдем:

— Дөнья бит ул, бабай. Кешеләрнең төрле чагы була. Хуҗа начар түгел иде, тәрбиядә тотты, ашау-эчү ягына бик юмарт иде, тик аны ташлап киттем…

— Гаҗәп, — диде бабай. — Ашаткач, эчерткәч, киендергәч, тагын нәрсә ошамады? Әллә хуҗаның егете булып, сиңа каныктымы? — Йөземә алсулык йөгертергә тырыштым. Барып чыкты, ахры. Бабайның күзе яктырды. — Егетне ник яратмадың соң? Бик ямьсезме әллә? Авырумы, булдыксызмы? Ник шундый хуҗага килен булып калмадың? — дип бабай шаркылдап көлеп җибәрде.

Тәмам оялган булып:

— Бабай дөнья күргән кеше, барын да белә икән. Ошамаган егетләрдән бик куркам мин, — дидем. — Бабай, әгәр дә киленең мине эшкә алса, һич курыкмасын: эшемне һәм турылыгымны хезмәтемдә күрер. Хак сорамыйм, үзе теләгән хакын бирер. Әгәр дә ике арада килешү төзим ди икән, анысы сезнең ихтыярда, дидем.

Карт ышана башлады.

— Ярар, кызым, договор да төзеп тормабыз. Ә син ни эшли аласың?

Булдыра торган эшләремне тезеп киттем:

— Йорт эшләре кайда да бер инде ул, бабай. Өйрәнгән эшләр. Сабанын да сөрәм, чәчүен дә чәчәм, печән чабам, урман кисәм, ташыйм, урак урам, ашлык сугам, мал-туарны тәрбияли беләм, кер юам, су китерәм, мунча ягам, җеп эрлим, чөлкә бәйлим, самавыр куям, ашын, ипиен пешерәм — барын да булдырам. Яшь чагым бит, бабай!

Бабай, гадәтенчә, шаркылдап көлеп җибәрде:

— Вот, кызымка, чистый егет икән! — дип кычкырып куйды һәм килененә карап, — мондый кызны син, ил бетереп тә, таба алмыйсың. Бар, өеңә алып чык, тамагын туйдыр, бүген ял итсен. Иртәгә эшкә кушарсың, — дип әмер бирде.

Без әлеге бабайның килене Надежда җиңгиләр өенә чыктык. Ул мине ашатты, эчертте, ял итәргә кушты.

Икенче көнне Надежда җиңги мине сабан сөрергә илтте. Атлар монда миңа бик ошадылар. Башта сабанны тирәнгә көйләп, буразна сызып чыктым. Аннан

сабанны гадәттәгечә көйләп җибәрдем. Надежда җиңгигә эшем бик ошады булса кирәк. Ул, матур елмаеп, миңа фатиха бирде дә кайтып китте. Кәефем күтәрелде. Атлары, кораллары шулхәтле шәп. Бөтен дөньясын каплап алырдай булып, дәрт белән сөрәм. Көн кызып җиткү белән, күлгә кайттым. Безнең татар халыклары арасында хатын-кызның атка менеп йөрүләре гаеп эш булып саналса да, руслар арасында гаеп булып саналмый. Шунлыктан мин сабан арбамны басуда калдырып, атларымның берсенә атланып, берсен җитәкләп күл буена төштем. Бу кадәресен дә Надежда җиңги мактады. Имеш, мин ат җанлы, аларның көчен кызганам, янәсе. Кирәкмәгәнгә арба сөйрәтеп йөрмим. Атларны эчергәч, башак бирдем. Азрак ял иткәннән соң, печән чабып алып кайттым. Шулай итеп, көзгә кадәр Надежда җиңгидә эшләдем.

***

...Миңа Сараштагы тормышым тынгылык бирми иде. Миннән соң да анда кояш чыгудан туктамаган бит. Анда нинди хәлләр булган? Боларны, белгән кадәремчә, чит кеше исеменнән сезгә сөйләп китим. Шулай дөресрәк булыр.

...Рәхимә җиңги татар халык йоласы, дөресрәге, ислам дине йоласы буенча биатасы Хәким карттан тел яшерә иде. Хәким карт алдында яулык почмагын авызына кабып йөри иде. Солдат ире кайткач, аш мәҗлесенә килгән карт-коры, муллаларны озаткач, Галим солдат әти-әнисен һәм күрше-күкертләрен алып калып, өр-яңадан сыйларга кереште. Рәхимә җиңги бу мәҗлескә дә катнашмады. Ул, чыннан да, ат җибәрергә киткән Мәрьямнең кайтуын өзелеп көтә иде. Чөнки биаталары белән ире Галимнең яңа өйдә утырулары сәбәпле, аш өе аулак иде. Рәхимәнең ире киткәнче кулы бәйдә, алдагы көннәрдә Мәрьям белән нинди мөнәсәбәттә булачагы хакында, «кыз» белән аулакта калып, киңәш итәсе бар иде. Мәрьям кайтып кергән солдаттан шикләнә, чыгып югалуы да бар. Аның башына нинди уй килмәс?.. Шул сәбәпле җиңги Мәрьямнең сабаннан кайтуын зарыгып көтте. Ләкин кояш баеп, караңгы төшсә дә, Мәрьям кайтмады.

Рәхимә җиңги бу авылдан җиде чакрым ераклыкта булган бай тормышлы крестьян кызы иде. Биш ир бала арасында бердәнбер кыз булып, бик иркә үсте. Уртача буйлы, тулы тәнле, шомырт кара күзле, кыйгач кашлы, алсу йөзле. Нәфис бармакларында бриллиант кашлы йөзекләр елык-елык киләләр.

Галим солдаттан кайтканда, Рәхимә унбиш яшен тутырып, уналтынчы яшькә яңа гына чыккан иде. Кияүгә чыгу исенә дә килми иде, кисәк кенә Галимгә ярәшеп тә куйдылар. Рәхимәне шушы авылда туып-үсеп, кайчандыр Сарашка килен булып төшкән Гыйльми кортка димләгән икән.

Галим, белгәнебезчә, Хәким картның иң олы улы булып, призывка икенче разряд льгота бирсәләр дә, авыл солдат нәрәтен тутыра алмагач, Галим исемлектәге призыв нумиры белән чиратка эләгеп, солдатка алынган иде. Егет төскә түгәрәк йөзле булуы белән әнисенәрәк охшаса да, салмак табигате белән нәкъ Хәким картның үзе иде.

Рәхимә җиңги ирен бик ярата. Өч ел яшәп, бер-берсенең мәхәббәтләренә кимчелек китерерлек хәл күрсәтмәделәр. Шунлыктан, әнисенең Рәхимә хакында язган ят хәбәрләр Галимне ярсытмадылар. Галим төнлә кайтып кергәч, Рәхимәсе янында тик Хөсни әбине генә очратты. Ул кунакка кайтачагы хакында хат белән алдан хәбәр итмәгән иде. Моның өчен ул сөеклесе Рәхимә алдында гафу үтенергә теләде. Үзенең якын күргән сердәшләреннән дә андый-мондый буталчык хәбәр ала алмады. Рәхимәнең үзе юкта дөньяны таратмас өчен җан тырышканлыгы ту-

рында күп яхшы хәбәрләр ишетте. Акыллы хатын, тормышның серен белә торган хатын, дип мактадылар Рәхимәне. Димәк, шикләнергә бер сәбәп юк! Шунлыктан, төрле яман уйлар Галимнең башыннан чыгып очтылар. Каяндыр, ничектер килеп ирешкән начар хәбәрләрне көнчелек галәмәте дип кабул итте. Аның Рәхимәсенә булган мәхәббәте тагын да арта төште. Җитмәсә, хатыны күзгә күренеп тулылана төшкән ич. Бер җай табып, Галим хатынының биленнән җиңелчә эләктереп алды.

— Әллә син... югыйсә? — дип кинаяләп сорады ул.

— Мин дә шулай микән әллә? — дип кызара төшеп елмайды Рәхимә. Ачыклык кертәсе итте. — Үткән көз, октябрь азакларында өяздән кайтып, кунак булып киткәнеңне онытмагансыңдыр бит?.. Шуннан соң нидер булды инде, мин бер көйчәгә әверелдем. Ходайдан вакыт җиткәндер, күрәсең...

Рәхимәнең бу җавабы төпле һәм нигезле булып, бәйләнергә урын калдырмады. Галим сөекле хатынына карата шик төшерергә азапланган әнисенә нык итеп әйтте:

— Борчылма, әнкәй, үзеңә сөенчегә нәрсә бирермен микән, димен әле. Ходай Тәгаләнең миңа биргән беренче бүләгенә тап төшерерлек бер сүз чыгарма! Рәхимәне бу хакта хурлар урын юк. Бөтен кайгым — сугыш хезмәтеннән ничек итеп тизрәк котылу турында. Сабыебыз туа бит, әнкәй, бәби көтәбез!

Галимнән бу сүзне ишеткәч, әнисе дә үзен улы каршында гаепле санап, гафу үтенгәндәй, сөйләнеп алды.

— Хәерле булсын, куаныч күп булсын, — дип куйды. Галим әти-әниләрен озаткач, Рәхимә янына керде.

— Мәрьям атларны болынга илтергә китүдән кире кайтмады. Ни булгандыр? Әллә атларны урлап качты микән? Бик яхшы эшләсә дә, ул безгә билгеле кеше түгел бит, — диде Рәхимә аптыраулы тавыш белән.

Рәхимәнең сөмсере коелуын күргәч, Галим бичәсенә кушылып кыбырсып алды:

— Атларны алып качмасын, йә, сагынуына түзә алмыйча, авылына кайтып китәр... Болай үзе тыйнак, карусыз кызга охшаган иде, бер дә усаллык төсе күрмәдем. — Аннан хатынын тынычландырырга кереште. — Ярар, бүген ял итик инде, иртәгә нәрсә булса да билгеле булыр. Бәлки, белеш-танышлары белән кич утыра торгандыр, кайтыр әле, — диде.

Рәхимәгә Галимнең бу сүзләре бер дә ошамаса да, җавап кайтармады. Хатында сиземләү көчле булып, Мәрьямнән колак кагып калуы хакында эчтән чын-чынлап кайгыра башлады.

Иртәнге якта, үсмер малайлардан берәү, зирек ботагыннан табып, ике каеш йөгәнне китереп бирде һәм атларның әрәмә арасында ашап йөргәнлеген әйтте. Мәрьям үзе күренми икән.

— И бичара кыз! — диде Галим кайгырып. — Авылын, туган-тумачасын сагынгандыр инде. Кайтып килергә теләге барлыгын әйтсә, пар атымны җигеп озаткан булыр идем. Яшьлек-юләрлек... Башына уй килгән дә, эшкә дә ашырган, — дип, Рәхимә җиңгигә күтәрелеп карады. Хатыны күңелсезләнә иде.

— Кабат килү исәбе белән китмәгәндер ул. Кызу эш вакыты җиткәч кенә мине ике кулсыз итте бу явыз! — диде Рәхимә ачынып.

— Ник алай дисең? Әле монда киләчәк ул кызый! Әллә соң, кызып китеп, әрләштергән, рәнҗеткән чакларың да булгаладымы? Эшләгәне өчен алдан түләп куясың калган, бичәм, ялгышкансың. Аласы хакы булса, килми калмас иде.

— Нәрсә түлим тагын? Бер тиен акча биргәнем булмады. Өс-башын бай кызлары кебек карагач, аңа акча нәрсәгә тагын? — диде Рәхимә җиңги чәпчи төшеп. Галимнең фикерен ныгыту теләге белән, сүзен дәвам итте. — Язгы чәчү

беткәч тә: «Берәр атнага авылга кайтып киләсе иде, җиңги!» — дип котырынган иде. Кайтып кил, дидем. Ул, кире уйлап: «Авылга кемне күрергә кайтыйм инде? Кем көтә мине анда? Минем беркемем дә юк», — дип елап, җанны ашаудан туктаган иде. Ә кичә үзең ишеттең. «Пар җирләре сөрелеп бетте, иртәгә нәрсә эшлим микән?» — дип торды. Бер дә кайту турында сөйләмәде, — диде Рәхимә.

Мәрьямнең эзе суынды. Сараштa, күпләр исенә төшереп, сагынып сөйлиләр иде кызны. Эчтән генә янып-көюче Рәхимәнең хәлен аңлаучы юк иде.

Отпуск көннәре үтү белән, Рәхимә җиңги ире Галимне озатты. Галим белән бу аерылышу Рәхимә җиңгигә шундый авыр булды. Ярдәмчесез, берүзе калачагын күңеле сизә иде. Рәхимә җиңги хуҗалык эшләренең артка түгел, һәнүз саен алга баруын ярата иде. Бердән, Галимнең кайтуы аны гайбәтләрдән саклап калса, икенче яктан Мәрьямнән колак какты. Бөтен эшне җиренә җиткереп үтәүче Мәрьямдәге фил көчен сагына иде Рәхимә җиңги. Моны үз тәнендә татыган хатын-кыз гына белә шул. Мәрьямнең саубуллашмый да китеп баруы ачуын да китерә. Ничек җиңел ташлап китте ул аны, ә? Хәзер исенә дә кереп карамый микән Рәхимә аңа? Туачак сабыен да уйламый микән? Рәхимә җиңгинең күзеннән мөлдерәп яшь ага. Галим китеп бара, «Мәрьяме» юкка чыкты... Тулы бәхетенең җимерелүе иде бу. Рәхимә җиңги белән саубуллашкан вакытта Галимнең:

— Исән бул инде! Үпкәләп, рәнҗеп калма. Дөньяның хәлен белеп булмый, хәер-фатихаңнан ташлама, — дип, Рәхимәнең балаларныкы кебек матур кулларын кысып тотты. Бичә, башы әйләнеп, һушыннан китә язды. Моны күреп, Галимнең дә ихтыярсыз ике күзеннән яшь атылып чыкты. Яу кырына китеп бара бит. Шушы йортын, чибәр кәләшен, туачак сабыйны калдырып, сугышка китә. «Дөньяның хәлен белмәссең...» — диюе дә дөрес. Һәркөнне сугышта һәлак булучылар хакында хәбәрләр килеп кенә тора.

Галим китеп бер атналап үткәч, Галимнең энесе — Сабира җиңгинең кияве Габделкәримнең — сугышта һәлак булуы хакында хәбәр килде. Сабира җиңгине бу хәбәр каты хәсрәткә дучар итте. Аның җыерчыкка баткан күзләре күп елаудан шешенде, пешеп чыкты. Хәким картның йортыннан кайгы уртаклашучы дус-иш, кардәш-ыру өзелми. Кеше килгән саен кайгы да авырая, өелә генә бара сыман.

Шушы кайгылы көннәрдә мулла да килеп керде. Ул мәеткә укый торган «Иннәлилләһи»не укып битен сыйпады. Хәким картны шундый зур кайгыга сабыр итәргә, түзәргә кушты.

— Падишаһымыз әгъзам хәзрәтләре хезмәтендә сугышларда һәлак булган бәндәләр шәһит үтәләр. Алар сигез оҗмахның түрендә булалар. Дөньяны сөймәскә кирәк. Ахирәт — безнең төп максатыбыз. Шулай булгач, сугышта һәлак булучылар иң бәхетле кешеләр булалар, — дип, бик озак такмаклаганнан соң Хәкимгә борылды. — Габделхәким абзый, ошбу сугышта һәлак булган улың Габделкәрим өчен гүр садакасын һәм фидаясын бирмичә калма! Кыямәт көнендә дәгъвасы калмасын. Хосусән, шул турыда искә төшерим дип килдем, — дип, зур эш башкарган сыман авыз эченнән нидер укый-укый чыгып китте.

Рәхимә җиңгинең әтисе — Хәким картның кодасы шунда иде.

— Бу муллалар кайда да шул икән. Мәет исен әллә каян сизәләр, — дип ачуланып сөйләнеп алды. — Сугышка китеп һәлак булганны мактыйлар. Монда калган ятимнәрнең актык сыныкларын авызларыннан тартып алалар. Менә сугыш кемнәр өчен бәйрәм икән. Улың да үлә, йортың да тарала һәм талана, — диде.

Хәким карт эндәшмәде. Ул фидая өчен ни-нәрсәләр бирү хакында уйлый.

Чөнки тәртипне белә: әгәр фидая бирелмәсә, мулла аны духовное собрание аша юллап алачак.

Хәким карт фидая бирергә өлгерә алмый калды, духовное собрание муллага бер ат, бер сыер бирергә кушып, болай гына бирмәсә, үрәтник белән кереп алачакларын кисәтеп, боерык язуы җибәрде. Мулла да эшне соңлатмады — Хәким картның утарыннан бер атын, бер сыерын җитәкләп чыгып китте.

***

Надежда җиңгинең күршесендә бер бик чибәр, таза кыз бар иде. Бу кыз ярлы кызы булганга, Надежда җиңгиләргә кергәләп, өй җыештырып, кер юып, башка вак-төяк эшләр эшләп йөрүче, тиктормас шаян кыз иде. Мин Надежда җиңгигә урнашып, эшли башлагач та, кызый бу йортка ныграк ияләште. Мине русча сөйләшергә өйрәтә башлады, үзе дә миннән татарчага өйрәнә иде. Миңа бернәрсә хакында русча әйттертә дә, шуны миннән татарчага кабатлата. Исеме — Наталья. Аның белән тату йөрибез. Бергәләп печән чаптык, җыйнап, эскертләргә салдык. Урак урдык, ашлык суктык. Ниһаять, игеннәр җыйналып бетте һәм озын көзге төннәр килеп җитте. Наталья Надежда җиңгиләргә һәр төн саен кич утырырга керә. Кич утырганда, сузып-сузып җырлап җибәрә. Мин дә элек белгән рус җырларын искә төшерәм, яңаларын өйрәнәм. Төрле кызык рус халык әкиятләре сөйли. Минем дә русчам әйбәтләнә бара. Сөйләшкән саен тел шомара бит ул. Тормыш матур гына бара иде. Надежда җиңгидән китүемнең сәбәбе дә Натальяның шаянлыклары булды. Аны Надежда җиңги дә, башка дус-ишләре дә Наталья, дип әйтмиләр, Наташа, диләр. Кеше исемен бозып эндәшергә күнмәгән телем алай әйтергә мәслихәт итмәде. Һәрвакыт тулы исеме белән Наталья дип йөрдем.

...Русларның көз көне үтә торган бер зур бәйрәмнәренә хәзерләнәбез. Покрау дип атала. Наталья белән бергәләп өй җыештырабыз: идән, сәке, караватлар юабыз. Тел бистәсе Наталья шаян сүзләр сөйли, көлдерә. Башка вакытта ул алай котырмый гына шаяра торган иде. Ә бүген бөтенләй йөгәнсезләнде, оят сүзләрне тутырып, кыю ычкындыра. Надежда җиңгинең берничә тапкыр кисәтүе дә аны юашлатмады. Мин, үземне кызлар дип нык ышаныч белән хыялыма китерсәм дә, Натальяның болай кылануы шикләндерә башлады. Мин һәнүз саен төшенкеләндем. Ә Наталья отыры минем шикләнүемне сизгән сыман, котырына. Кат-кат килеп мине кысып коча, иреннәремнән үбә.

— Ник минем белән бәйдән ычкынгандай шаярасың? — дип, үпкәләгән төсле аннан читтәрәк йөри башладым.

— Син егет кеше бит. Мин сине шуның өчен үбәм, — дип, шаркылдап көлде Наталья.

— Төшеңдә күрдеңме әллә? Саташасың түгелме? — дидем мин ачуланып.

— Төшемдә дә күрдем, өнемдә дә күрдем. Мин сине йоклаган чагыңда берничә тапкыр тикшердем инде. Син сугыштан качып, хатын-кыз киеме киеп дизертирлыкта йөрүчеме? — дип, Наталья чын басым белән сөйләнергә кереште.

Натальяга җавап бирүдән гаҗиз калдым. Ныклап бәхәс куертырга да, бу хакта эндәшмәвен үтенеп ялварырга да курыктым. Натальяның сүзләрен ишетмәгән дә кебек, бөтенләй санламыйча, матур озын көйгә саф татарча җырларга керештем.

Наталья да әлеге сүзләрен ташлап:

— Ну шул татар кызлары җырлаганны яратам да мин! — диде. Үпкәләгән тавыш белән өстәде. — Син дә, дус булып йөргән буласың инде, миңа шушы

җырыгызны да өйрәтергә теләмисең. Күпме рус көйләрен, рус җырларын өйрәттем үзеңә. Бер дә ялындырып тормадым... — диде.

Шушы чакта Надежда җиңгинең килеп керүе сәбәпле, сөйләшү тукталды. Ул безгә аерым-аерым эшләр кушты.

Шунысына сөендем. Наталья берүзе эшләргә калды. Мине Надежда җиңги үзе янында эшләргә алып чыгып китте. Мин эчемнән:

— Явыз кыз Наталья. Надежда җиңги белән минем серне бер икән дип тә уйламый калмас әле. Бу йорт миңа тар ахры. Кич булу белән, чарасын күрми булмас, — дип уйладым.

Кич булды. Минем бәхеткә, Надежда җиңги авылдагы апаларына китте. Мин бу аулак өйдән файдаландым. Кичке эшләрне пөхтә итеп, җиренә җиткереп эшләп куйдым. Өйдән ичмасам бер ашарлык ипи дә алмадым. Өстемдә Надежда җиңги биргән киемнәр. Ишекне йозаклап, ачкычын мүккә — Надежда җиңги үзе кыстыра торган урынга кыстырып, һичкемгә күренмичә, абзарлар аша ындырга, аннан басуга киттем. Бик җәһәтләп бара торгач, ун чакрымдагы бер кечкенә рус авылына, кешеләр ятып беткәнче, барып кердем һәм фатир сорап кунарга кердем.

— Шәһәргә эш эзләп барам, татар кызы мин, — дидем.

Бу авылда кунып, иртән иртүк торып, шәһәргә киттем. Әйтүләре буенча, авылдан кырык биш чакрым ераклыкта икән ул шәһәр.

Кичкә каршы шәһәргә барып кердем. Анда да, монда да базар. Халык күп. Бер карчык белән сөйләшеп, хәлемне белдергәч, әби мине бер зур һәм биек өчкатлы өйнең бүлмәсенә алып керде һәм аш пешерүче кызга хуҗа хатынны чакырырга кушты. Озакламый симез хатын килеп керде. Карчык аңа:

— Авылдан эшкә сусап килгән бер кызны китердем сиңа, — диде. Симез хатын (әфисәр марҗасы) минем белән нинди хезмәтләр итә алуым хакында сораштыра башлады һәм ул:

— Миңа ирләр эше эшли торган кеше кирәк. Утын китерә аласыңмы? — диде. Мин: «Утын, су ташу, печән китерү ише эшләрне генә эшләргә яратам», — дигәч, әфисәр марҗасы куанып китте:

— Менә йортта эшләргә бер егет-кызыбыз да булды, — диде һәм аш бүлмәсенә алып керде. Шундагы аш пешерүчеләргә тамагымны туйдырып, үзләре торган бүлмәдән урын биреп, ял итәргә кушып, чыгып китте.

***

Надежда җиңги үз өенә кайтканда ут яктысы күрмәгәч, Мәрьям ял итә микәнни? — дип уйлады. Ишек төбенә килсә, ишек йозаклы. Өйдә ут яндырылмаган, кичке аш та хәзерләнмәгән. Ул ачуланды. Ашарын да онытып, биләмдә йөри. Мине әзерләр, дип уйлый микән? Мин Татьяна апамда сыйланып кайттым. Миңа кичке ашның кирәге юк. Ничек теләсә, шулай үз тамагын туйдырыр дип, бүлмәгә кереп, урынга ятты. Озак вакыт үтмәде, орчык кабасы тотып, Наталья килеп керде. Ул Мәрьямне өйдә күрмәгәч:

— Кайда миннән качасың, Мәрьям? — дип, үз шаянлыгы белән көлеп җибәрде һәм Мәрьямне эзли башлады. Мәрьямне эзләп, бүлмәгә керде.

— Нәрсә тагын? — диде Надежда җиңги. — Көндез шаярып туймадың, төнлә тагын шаярырга керештеңмени? — диде.

— Бәй, Мәрьям кайда качты? Миннән качкан булып, ул шаяра бит әле, — дигәч, Надежда җиңги гаҗәпләнеп:

— Мәрьям кайда соң? Ул сездә түгел идеме әллә?

— Ул безгә кермәде. Кайда йөри икән? — диде Наталья.

Надежда җиңги гаҗәпкә калды.

— Бу кая китте икән Мәрьям? — дип, Надежда җиңги эчендәге ачуын тышка чыгарып эндәште һәм, Наталья кырына килеп: — Син беләсеңдер, ул кая китте? Мәрьям менә кая китүен миннән яшермәкче булып, аны өй эченнән эзләгән булдың. Ник минем белән шаярасың? — дип орыша башлады.

Үз нәүбәтендә Наталья да теге шаяруның сәбәбен сөйләп биргәч, Мәрьямнең кич белән билгесез югалуы расланды. Наталья бик кыю кыз иде. Ул Мәрьям хакында барын да сөйләргә кереште. Надежда җиңгинең тәнендә ярты җаны гына калды. Һәм авыр сулап:

— Минем Мәрьямне син качыргансың икән, алай булгач, Аллаһка күп шөкерләр. Котылуым яхшы, ә син, Наталья, телеңне тый. Ул хакта беркемгә бер сүз сөйләмә. Миңа оят китерерсең. Үз кешең дә түгел бит. Татар... — дип, бу вакыйгага нокта куйды.

***

Бик ашыгып килгәнгә, арган идем. Ашап тамак туйдыргач, бернәрсә белмичә йокладым. Мин уянып, торып утырганда, бүлмәдә ут яндырылган иде. Шулвакыт гимназистлар киеме кигән, унбиш яшьләр чамасында булыр, бер малайны ияртеп, хуҗа хатын керде. Малайның күзләре бик үткер карыйлар. Малай төсе-сөяге белән хуҗа хатынга бик нык охшаган.

Малай:

— Паспортың бармы? — дип сорады миннән.

Каушап калдым.

— Мин туган авылымнан чыгып киткәндә, нәрсәнең ни өчен кирәклеген белми идем. Хәтта бер сүз дә русча белмәдем. Бернинди паспортым юк. Авылларда ике ел эшләдем. Паспорт сораучы булмады, — дидем.

Малай минем каушаганымны белеп:

— Курыкма, паспортны үзем табып бирермен. Тик бездә яхшылап эшлә. Ялкауларны без бер көн дә тотмыйбыз, — диде һәм түш кесәсеннән блокнот алып яза башлады:

— Кайсы губерна? Кайсы өяз? Кайсы волость? Кайсы авылда туып-үстең? Чын исем һәм фамилияң? Хәер, татарларның фамилияләре булмый. Атаң ни исемле?

Малай язып алды да чыгып китте.

Шәһәр тормышы авыл тормышына караганда башка төрле икән. Киемсалымның пөхтәлеге, бит-күзнең чисталыгы нык игътибарга алына. Шунда да пычрак эш эшләп, бөтенләй пычранып беткән кешеләр дә күренгәли. Ике-өч көн эшләгәч, мине дә шәһәр кызлары кебек итеп киендерделәр. Миңа ат җигеп эшләргә куштылар. Урманнан утын китерәм, мичкәгә су ташыйм.

Кайсы көннәрдә шәһәр урамында котычкыч хәлләр була. Кызыл флаглар күтәреп, бик күп халык урамга сыймыйча йөриләр. «Бетсен сугыш, бетсен патша! Хезмәт һәм икмәк бирегез!..» — дип кычкырышалар. Шулхәтле күп халыкка каршы жандармнар ат атланып, кылычларын болгап кычкырына һәм мылтык тавышлары яңгырап тора.

Яз җиткәндә бер көнне урамга: «Патша төшерелде! Яшәсен социалистик революция!» — дип язылган кәгазьләр ябыштырып чыктылар. Озак та үтмәде, тагын кузгалыш башланды.

***

Октябрь аендагы революция турында берничә сүз.

...Салих бабайның, кырда кунып сабан сөргән чагында, бер солдаттан ишетеп сөйләгән сүзләре һәнүз саен чынлыкка чыга бара. Эшчеләр чынлап та патшага да, завод-фабрика хуҗаларына да һәм байларга да, патша чиновникларына да каршы чыктылар, ул гына да түгел, патша хөкүмәтен яклый торган сугышка да каршы тора башладылар.

Көз көне иде. Хәбәр таралды: «Петроград эшчеләре, солдатлар белән берләшеп, патшадан соңгы вакытлы хөкүмәт башлыкларын кулга алганнан соң, Русиядә эшче-солдатлар Советы төзелгән. Совет власте башында эшчеләрне һәм ярлы крестьяннарны яклый торган зур гыйлемле Ленин исемле кеше тора икән».

Шушы хәбәр таралу белән, әлеге әфисәр хатынының барлык хезмәтчеләре, аш пешерүчеләре китеп бетте. Бер мин генә калдым. Әфисәр хатыны мине аш пешерүче итеп куйды.

Дөнья кызды. Гражданнар сугышы башланып китте. Кайбер генераллар, солдат җыйнап, эшчеләр һәм революция яклы булган солдатларга — кызыл гаскәргә каршы сугыша башлады. Һәр җирдә кызыл гаскәрләрнең җиңүен сөйлиләр.

Бервакыт, кызыл гаскәрнең һөҗүм итүенә каршы тора алмагач, чигенеп килгән аклар шәһәргә килеп тулды. Әфисәр марҗасы — хуҗа хатынның да ире кайтып керде.

— Большевиклар бик каты куа. Себер ягына чигенәбез, — диде. — Өч көннән соң, әгәр вакыт мөмкинлек бирсә, сезне Себер ягына, Иркутскига озатам. Шәһәрне озаграк тотып булмаса, иртәгә үк озатам, — дигәч, хуҗа хатын үксеп еларга кереште.

Кичкырын әфисәрнең иптәшләре шушында ашарга-эчәргә җыйналды. Араларындагы бер бик ямьсезе, мине кыз дип белеп, шаяра башлады. Мин аш-су китереп йөрим. Ә ул кочакларга итә. Мин аны әрләргә керештем.

— Күрәсең бит, кызу сугыш бара. Уйнар-көләр вакытмы бу? — дип кычкырдым.

Әфисәр ачуланып:

— Ишетәсезме, бу кыз миңа каршы ничек кычкыра? Большевисткадыр! Бу кызыйны, шәһәр чигендә атып үтереп китәрмен! — дип гайрәт чәчкән була.

Хуҗа хатын мине бүлмәдән чыгарып җибәрде. Әфисәрне тынычландырырга тырышып, мине яманлый:

— Ул, аңгыра нәрсә, кемнең кем икәнен дә аңламый. Шундый инде ул. Аңгыра булмаса, башка хезмәтчеләргә ияреп, чыгып киткән булыр иде. Бернәрсә дә аңламавы белән әле дә йөри, — диде. Әфисәрләр шаркылдап көлделәр.

Теге ямьсез әфисәр:

— Мине кызың янына җибәр әле. Аны сынап карарга кирәк, — диде. Шуңа хатын нәрсә дип җавап биргәндер, анысын аңламадым.

Кич булгач, әлеге әфисәр минем бүлмәмә басып керде. Ул шулхәтле исергән иде, көч-хәл белән аягында тора. Үзе:

— Мине кунак ит, туташ! — дип кабатлый иде.

Аны ягымлы каршы алган булдым. Чишендереп, караватка яткырдым, барлык киемнәрен үземә кидем. Бар коралын алдым һәм әфисәр булдым. Коридордагы аяк тавышлары басылгандай итте. Ишек һәм капка төбендә икешәр сакчы солдат

торганын белә идем. Үзалдыма русларның бер көен сызгыра-сызгыра, чыгып киттем. Сакчы солдатлар, честь биреп, озатып калдылар.

Кызыл гаскәрләрнең шәһәргә ерак түгел бер авылда торуларын ишеткән идем. Шәһәрдән чыгып китәргә юлларның бикле икәнен дә беләм. Шәһәрдән чыгу өчен юлсыз җирдән үтәргә кирәк. Капка асларыннан, койма өсләреннән үтеп, ниһаять, шәһәрдән чыктым һәм инеш буйлап болыннар, әрәмә араларыннан бара-бара, шәһәрне яхшы ук артта калдырдым.

Су тегермәненә килеп җиттем. Һау-һаулап этләр каршы алдылар. Кешеләр килеп чыктылар. Алардан:

— Монда аклар солдаты яки кызыллар солдаты юкмы? — дип, русчалап сорадым.

— Берәү дә юк, — дип җавап бирделәр. Өйгә кердем. Мине ак әфисәр дип, тегермән тартучылар бер-берсе белән күз кысышып сөйләштеләр һәм чәй эчәргә, аш ашарга кыстый башладылар. Берсе: «Әфисәрне сыйларга кирәк, авылга кайтып самогон алып килергә кирәк», — дип чыгып китте.

Беләм, алар мине кызыл гаскәрләргә пленга тотып бирергә җыйналалар — мин шуны көтәм дә.

Озак та үтмәде, җиде-сигез кызылармеец тегермән өен камап алдылар.

— Иптәшләр, коралларымны алыгыз, мине кызыл гаскәрләр штабына илтегез. Үзем теләп, кызыллар ягына чыгам һәм миндә кызыллар өчен бик кирәкле документлар бар. Курыкмагыз, иптәшләр, — дип, кул күтәреп, яннарына чыктым.

Алар мине авылга — штаб урнашкан йортка китерделәр. Миннән алынган әфисәрнең коралларын, сумкаларын алдылар. Анда акларның сугыш хакында булган күптөрле документлары табылды. Ничек итеп бу якка пленга чыгуымны сөйләп бирдем. Язмышымны сөйләп, әфисәр малае шәһәр идарәсеннән алып биргән Мәрьям исеменә язылган паспортымны күрсәттем. Кызыл Армиягә кабул итүләрен үтендем. Менә шул көннән бирле мин акларга каршы сугышып йөрим. Күп җирләрне гиздем, командирларның ышанычын казандым. Блюхер үзе исемле корал белән бүләкләде. Авылдан чыгып киткәнгә күп сулар акты. Кайбер якын-тирә сала кешеләрен очратып, үзем хакында әти-әнигә хәбәр салдым. Көтәләр алар мине...

P.S. ...Язуы озакка сузылса да, сөйләве шактый тиз, төгәл булды. Сугышчан дустымның тарихын уйлап, ул чакта озак йоклый алмый яткан идем. Кайнар, давыллы елларның истәлеге итеп бу хакта күпләргә сөйлим. Кем ышана, кем ышанмый. Мин исә аңа бик ышана идем. Кайттымы ул авылына? Белә генә алмыйм. Адресын да, исемен дә оныттым. Мин аны Мәрьям буларак кына хәтеремдә йөртәм. Кыю, батыр, куркусыз сугышчан дустым, кайларда йөрисең син?..

Кулъязманы әдәби эшкәртүче һәм басмага әзерләүче —
Факил Сафин

ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА — 105 ЕЛ

ӘДИП ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

Минтимер Шәймиев,

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе

...Әмирхан Еникинең тормыш юлын карап чыктым. Аның гомер юлы бик бай... Татар халкының телен саклап калу, язмышын кайгыртып яшәү, әле авыз ачарга куркып йөргән вакытларда Нәкый Исәнбәтләр белән бергә... Чөнки ул гадәти язучы түгел... Әмирхан Еники ул — акыл иясе... Аның акыллы киңәшләре һаман да колак төбендә, дип әйтер идем... Мине иң гаҗәпләндергәннәрнең берсе шул: 1941-1945 елларда Әмирхан Еники гап-гади, чын солдат булган. Гади,чын солдат булып кала алгач, ул үзе әле бер өйрәнелмәгән темадыр, дип саныйм...

Шундый тирән, сокландыргыч иҗат Әмирхан Еникинең акыллы кеше булуыннан килә. Аксакал әдипнең бай тормыш юлы — республикабыз өчен олуг бер хәзинә!

Марат Кәримов,

Башкортстанның халык шагыйре

ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ

Кайда бакма, мәхшәр, мәхшәр —
Шайтан туе бара илдә.
Башка ил бар. Безнең белән
Яши бер үк параллельдә.

Анда түрдә намус, вөҗдан,
Җанның изге сәгадәте.
Картада юк бу мәмләкәт —
Әдәбият мәмләкәте.

Байлык эзләп, без, бәндәләр,
Әллә кайда казынабыз.
Шушы илдә түгелмени
Сандык-сандык хәзинәбез.

Кемнәр үскән сабый чактан
Җырлар көйләп «Әллүки»гә,
Шулар килә мәмләкәтнең
Аксакалы Еникигә.

Күңел матурлыгы белән
Тулы аның әрҗәләре.
Анда сүзнең энҗеләре,
Анда телнең мәрҗәннәре.

Анда хаклык ахаклары,
Хыял — алтын манаралы.
Алтын манаралы җирдә
Уңа йөрәк яралары.

Кемнәр сабый тәрбияли
Җырлар җырлап милли көйгә,
Шулар рәхмәт сүзен әйтә
Олуг әдип Еникигә:

«Гали татар милләтенең
Тынгы белмәс җаны да син,
Аның изге рухы да син,
Сүнмәс якты аңы да син.

Буыннардан буыннарга
Күчә торган даны да син,
Шушы матур мәмләкәтнең
Әмире дә, ханы да син!»

Кайчандыр Әмирхан Еники яшәгән йорт. 2013 ел

Әмирхан Еники музее булырмы?

ЛӘБИБ ЛЕРОН

Әмирхан Еникинең тууына – 105 ел. Вафатына исә инде унбиш ел вакыт узып та киткән. Казанда мәшһүр әдип исемен йөрткән дүрт-биш йортлы урам барлыгын (Вишневский-Калинин урамнары тирәсендә) исәпкә алмаганда, әдәби вә мәдәни гавамның (һәм, әлбәттә, хакими җитәкчелекнең дә) әдип истәлеген мәңгеләштерүдә, бәһа биргесез мирасын барлау-саклауда әллә ни эш майтарганы юк шикелле.

Узган ел Әмирхан Еникинең туган ягында – әдипне дөньяга иңдергән Каргалы авылында (Благовар районы) һәм язучының бала вә үсмер чагы узган Дәүләкәндә булырга туры килгән иде. Шаккатмалы хәл: кайчандыр Әмирхан ага яшәгән йорт бүген дә исән. Йортның алгы як өлешенә «Бу йортта 1911-1926 елларда Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники (1909-2000) яшәгән» дип язылган истәлек тактасы куелган. Чынлыкта, Әмирхан ага үзе «Соңгы китап»та язганча, аларның гаиләсе бире дә 1918 елның

җәендә генә яши башлый әле: «Яңа йортка — инде үзебезнең йортка (*бер урыс баеннан ошбу өйне сатып алганчыга тикле, Нигъмәтҗан агай гаиләсе Дәүләкәндә дистәгә якын йортка «фатирга кереп» кенә яшәгән.* — **Л. Л.**) без 1918 елның июнь башында күчендек...»

Әлеге тарихи йортта бүген дә бер татар гаиләсе яшәп ята. Күпне күргән, күпне кичергән йорт акрын-акрын гына ташландык хәлгә килеп бара. Аның бүгенге хуҗалары әйтүенчә, йорт турында бөтенләй кайгыртучы юк, эш «Булыр-булыр көе»нә тел сайратудан ары китми икән. Кичекмәстән тотынмасак, бу бәһасез йортның бик тиздән чын мәгънәсендә вафат булуы һәм эзе-нигезе тәмам юкка чыгуы ихтимал. Моңа ике республика җитәкчелеге, һәм татар, һәм башкорт әдәбияты-сәнгате әһелләре бергә кушылып, бердәм тотынса гына, эш күркәм нәтиҗә бирәчәк (*сүз уңаеннан, узган ел Оренбурда Муса Җәлилгә музей ачылды. Аны Татарстан белән Оренбур хакимиятләре бергә башкарды.* — **Л.Л.**). Минем әйтергә теләгәнем: Әмирхан ага үскән әлеге өйне саклап каласы, аны сипләп-яңартып, тиз арада музей-йорт итәсе, шул йорт урнашкан урамга (хәзерге вакытта урам Җиңү исемен йөртә) әдип исемен бирәсе иде.

Музей-йорт дигәннән... Әмирхан ага яшәгән өйдән ерак түгел генә Башкортстанның халык шагыйре Әхияр Хәкимов (1923-2003) музей-йорты урнашкан. Әлеге мәһабәт йортны күргәч, аның эченә үтеп, шундагы экспонатлар белән танышып чыккач, шулкадәр тәэсирләнүдән, дулкынланудан исемә килә алмый тордым. Олпат әдибебез Әмирхан ага Еникинең якты рухы алдында, безне озатып йөрүче дәүләкәнлеләр каршында, шәхсән, миңа бик тә оят иде...

P.S. Язма журналда басылырга әзерләнгәндә шулар мәгълүм булды: Әмирхан ага Еники 1918-1926 елларда яшәгән әлеге йортны музей итү турындагы мәсьәләгә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә игътибар иткән икән. Аның җиңел кулы белән башланган бу эшкә Татарстан мәдәният министрлыгы чын-чынлап тотынган. Шәт, иншаллаһ, моның күркәм нәтиҗәсе булыр, дип ышанабыз. ■

Бер төркем татар әдипләре Башкортстанның халык шагыйре Әхияр Хәкимовның музей-йорты янында. 2013 ел

СҮЗ ХӘНҖӘРЕ КЫНЫНДАМЫ?

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

Рәсемдә (сулдан уңга): Фәннур Сафин, Рабит Батулла, Рөстәм Нәбиуллин (басып төшкән), Разил Вәлиев, Рафаэль Сәхәбиев һәм Равил Шәрәфиев. 1979 ел

Мин аның белән имтиханнар бирер алдыннан (1969 елда) таныштым. Ленин, Толстой кебек даһилар укыган университетның абитуриентлары булу – яшьлектә сулышка каба торган бәхет түгелмени!

Ул шигырьләр яза икән. Күзләренең төсе — гадәттән тыш куе зәңгәр. Җиңел гәүдәле. Елдам, хәрәкәтчән. Сөйләшкәндә көтелмәгән юмор сүзләре кыстырып алырга ярата. Көлсу-соргылт чәч учмасын вакыт-вакыт кискен кул хәрәкәте белән сыпырып куя. Чын шагыйрь чалымнары бар моңарда, дип эчтән генә бәяләп тә куйдым шикелле. Танышкан көннән үк бергә яши башлаган бүлмәбез — дүрт тимер карават куелган, ярлылыкка бай «каютабыз» — безне студентлык чорына да алып керде.

Сүз куәсенә көч биргәндәй, кулын йодрыкламыйча гына бер ритмда селкеп, җылы тавыш белән көйләбрәк шигырь укуы әле дә күз алдымда:

Синең якка карап бер кычкырдым,
Миңа булмас синнән башка яз.
Биек тауга килеп бәрелде дә,
Егылып төште җиргә кайтаваз.

***

Фәннур Шәйхенур улы Сафин 1948 елның 27 июнендә Минзәлә районы Күзкәй авылында туа. 1966 елда урта мәктәпне тәмамлагач, комсомол юлламасы белән Түбән Камага килеп, нефть-химия комбинатында слесарь булып эшли. 1969-1974 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Төрле елларда газета-журналларда әдәби хезмәткәр, мөхәррир булып эшли.

Фәннур Сафинның бик яшьли шигырьләр язып «Ялкын»журналы, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында бастырган, шактый тәҗрибәле каләм иясе икәнлеге студент елларында ук сизелә иде. Ул ирекле яисә ак шигырь язам, дип кысыр алдану белән мавыкмады. Шигъриятнең әлмисактан бирле йөзек кашы булып килгән табигый үлчәмнәренә тугрылыклы калды. Редакция ишекләренең дә ул кайсы якка ачылганын белә, исемле әдипләр белән якыннан аралаша, безне дә кузгатып, әдәбият даирәсенә әйдәкләп алып керә иде.

Батулла үзе алып барган кичәләрдә безгә яшь шагыйрь дип сүз бирсә, Фәннурны исә, баритон тавышы белән аерым басым ясап, шагыйрь дип халыкка игълан итә, курач гәүдәле курсташыбыз җиңел атлап сәхнә уртасына чыгып баса да, җырга тартым, көйле тавышы белән залны йөгәнләп ала:

Хаклык өчен янган шигырьләр бар,
Бар тик ялган өчен макталган.
Ялганнары ләкин сакланмаган,
Янганнары аның сакланган!..

Фәннурның Казан дөньясын гизеп, тулай торактагы бүлмәбезгә кайтып керүе гел бертөрле ритмда була; киемен салып шкафка элә дә ишеген шапылдатып яба, бөтен авырлыгын салып, гөрселдәп, караватына килеп утыра. Әйтеп-әйтеп тә, без аны бу кыланмышыннан туктата алмадык.

Шагыйрьнең бүтәннәрдән үзгә бер сыйфаты булырга тиешлекне дәгъвалаучы мисал иде бу, ахрысы. Фәннур кайтып керүгә үк, аның караваты куркудан сыгылып төшә иде шикелле. Аннары... көянтә кебек бөгелеп килгән шул караватында бераз утыргач, кинәт калкынып тора, кефир шешәсенә су тутырып керә, кырыендагы урындыкка куя да калын тышлы дәфтәрен, каләмен кулга алып, стенага таба борылып ята. Сәгатьләр буе ятып, ул дәфтәр битенә энә төртерлек тә урын калдырмыйча, сызган-бозган, өсте-өстенә язган сүзләр белән тутыра, шулвакыт эчендә өч-дүрт шешә су эчеп бетерә иде...

Бүлмәдәшебез Наис Гамбәр аның «олы дөнья»дан кайтып керүен сурәтләп, болай дип яза: «Хәсән ага Туфанда булып кайттым. — Егетебезнең күзләре ут яна иде. ...Ак бабай дәфтәремне карап чыккан, кайбер шигырьләремне ошатып та калган, ахрысы, яшел кара белән тамгалар да салып киткәләгән... Карагыз әле, Туфан ага гел яшел кара белән яза икән бит... гаҗәп...

Әйе, Фәннур шат, бәхетле иде бу минутларда, «яшел тамгалар» игътибарына чалынган шигъри юллар аны ләззәтле канатларында күкнең җиденче катына алып менеп киткән иде.

Тәгәрмәчләр шпал санап бара,
Баганалар каршы йөгерә.
Һәр багана җирне сөйри, гүя,
Кабельләрен салып иңенә.

Вәт, могҗиза! — «Кабельләрен иңенә салып, җирне алга сөйрәүче ул баганалар» һич тә гади бер чыжым баганасы гына түгел ләбаса, ул — шигърият йөген җилкәсенә салган ашкын күңелле яшь бер шагыйрь ич!» — дип, гомумиләштереп куя сабакташыбыз, шагыйрь һәм тәнкыйтьче Наис Гамбәр.

Студентлык елларында, табигый, хыял канатларыбыз колачлырак иде. Кояшлы, акварель төсләр белән язылган лирика шигърияттнең асылын бар итсә дә, Фәннур Сафин үзенең халкы, милләте каршындагы олы миссияне иңгә салырга кирәклекне тоя, ул дәвернең берни белән дә исәпләшмәгән тыюлык богауларын өзәсе килеп, кайчагында, әрнүен йөгерек юлларга сала, цензура «колагын торгызганчы» үткәреп тә җибәрә иде: *«Шәһитләрен җыеп күтәргәндәй Сөембикә җиргә иелгән».*

Әлбәттә, бүгенге яшь каләмчеләрнең башлангыч иҗаты кыюрак күренә. Дәвер башка... Сүзне боргычлаган богаулар өзелгән чак. Адәми зат асылын игә китерергә алынган философларның хезмәтләрен, иркенләп укып, аңзиһенеңне чарларга була. Ә без студент вакытта фәкать марксизмга ярашлы, кеше җанының төбендә тасланган явызлыкны, җимерү көчен уятучы философларны гына укыталар иде. Дини, фәлсәфи, тарихи белемнән без мәхрүм идек шул. Бар да тыелган, тыелган, тыелган иде.

Янды тән, янды кан — җан калды,
Шуңамы якты бу ак көннәр?
Һәм шуңа ни булыр җавабың? —
Без кемнәр, без кемнәр,
без кемнәр?! —

дип язды Фәннур Сафин.

Әйе, халкыңның тарихын кузгатып, дини хасиятен, милләт рухын калкытып язарга алыну — миналанган кырдан баруга бәрабәр иде: язу түгел, ул хакта уй-гамь йөртүеңне дә сизенеп, мәкерле караш гел күзәтеп торадыр кебек.

Фәннур Сафинның тегермәнче карт турындагы шигыре истә. Ул чорда Наҗар Нәҗминең хәтәр кыю, гимн кебек яңгыраш алган «Татар теле» дигән шигыре бөтен җәмәгатьчелекне тетрәтеп, вулкан кебек атылды. Шигырьгә «Мы в русской мельнице смололи заезжий татарский язык» дигән эпиграф куелган иде (Ярослав Смеляков язмасыннан). Фәннур Са-

Курсташлар арасында. Җитәкчебез – Флёра апа Сафиуллина. 1970 ел

фин тыйнак кына итеп, шуңа җавап рәвешендәдер бәлки, «Тегермәнче» дигән шигырен бастырып чыгарды. Тегермәнче татар картының:

Куллары да канга түгел,
Ап-ак онга буялганнар.
Ул һаман пакь,
Килгән-киткән
Усал җаннар — буян ханнар.

Кирәк бит, «Татарстан яшьләре» каршындагы әдәби түгәрәктә, яшь каләм тибрәтүчеләр җыелган мәҗлестә Тәлгат Галиулин (бүгенге профессорыбыз ул чакта, бәлки, аспирант булгандыр) «Хәзерге татар поэзиясендә хезмәт темасы» дип аталган, фикерлелеккә дәгъва кылмаган сүрән чыгышында Фәннурның әлеге шигырен хезмәткә бәйләп, мактап, мисалга китерде. Фәннур моны ук көтмәгән иде, аптырап калды, безгә дә көләргә сәбәп табылды.

Гомумән, булачак галимебез чыгышыннан көрәк-кувалда-кәйлә тотып эшләүчеләр турында гына язарга тиешлегебезне аңлый башлагач... азагына кадәр ничек түзәсең инде, Белинскийларны кайтып укыйк, ичмасам, — дип, дәррәү кубып, ишекне каты ябып, чыгып кителгән иде (бу да үзенә күрә юаш кына протест булгандыр, бәлки). Без, без инде, шагыйрь әйтмешли:

Алыплар да шомланалар,
Алыплар да җылыйлар...

Фәннур Сафин, чордашлар арасында беренчеләрдән булып, җыр жанрының да кирәклеген аңлап алган шагыйрь. Китап-журналлар аша бик урау юллар белән кеше күңеленә барып җитәсе сүз дәрманы җыр-моң аша бик тиз күңелгә салына. Классик шагыйрьләребезнең — Тукай, Такташтан башлап, Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәргә кадәр һәм алардан соң килгән талантларны да өстәсәң — һәммәсе татар милләтен гомер буена юатып, уятып, уйлатып барырдай затлы җырлар калдырган.

Талымлылык, җыр сүзенең кадерен тою, таләпчәнлек бик югары кимәлдә иде элек. Һәм ул җаваплылык хисе буыннан-буынга имле күчеп бара иде.

Фәннур Сафин, Разил Вәлиев, артта – Габделхәй Сабитов. 1978 ел

Хәтеремдә, бервакыт Фәннур Сафин үз шигыренә шундый матур бер көй язылуына сөенечен уртаклашты да тик менә... бер сүздә генә икеләнеп калган икән:

—Ике вариантта яздым, кайсын сайларга: «Җыр белән юатырмын» диимме, «Җырымда юатырмын» дисәм, отышлырак булмасмы? — ди.

— «Җырымда юатырмын» дигәнең кызыклырак, — дим. Үзем дә шулайрак уйлаган идем дигәндәй, Фәннур, канәгать елмаеп, килешүен белдерде.

Төрле композиторлар белән дустанә, иҗади мөнәсәбәтләрен ныгытып, Фәннур Сафин бинһая уңышларга иреште. Аның шигырьләренә онытылмас көйләр язылды, «Бир кулыңны», «Хушлашырга ашыкма», «Җырымда юатырмын», «Ялгыз көймә», «Мәхәббәт шатлыгы» кебек җырлар халыкның күңел моңына кушылды. Шәп җыр беркайчан да онытылмый, күпмедер вакыт ял итеп кенә тора да, аннары, яңа буыннар килеп, ул җырны күтәреп ала, үзгә төсмерләр салып, кабаттан яңгырата башлый. Уңышлы җыр — шагыйрь һәм аһәңсазның уртак бәхете, җырчыартистның исемен балкыта торган тылсым.

«Сүз хәнҗәрен ал кыныннан — тутыкмасын!» — дип яза Фәннур Сафин үзенең беренче китабында. Әмма сүз белән ул беркайчан да тупас кизәнмәде. Ана телебезнең тәмен белеп, өрфия сүз җанын тоеп язган ягымлы лирикасы, туган җир табигатенә мәхәббәте, Идел-Йортыбызның борынгыдан килгән хуҗасы — халкыбызның гореф-гадәте, гамь-рухы — шагыйрьнең үзе яшәгән чор-заман офыгыннан үрелеп тасвирлана; шигырь-поэмаларында ул ят ритмга, көнлекче фикергә кызыкмыйча, калебенә тугры калып, ак кәгазь кырында каләме белән сызган буразналарга бәрәкәтле бөртекләр төшерү иҗтиһатына ирешә алды.

Шигъриятебез хәзинәсенә Фәннур Сафин үзенчәлекле мирас калдырды. «Кеше юлга чыкса» (1976) дип исемләнгән тәүге җыентыгыннан соң, Татарстан китап нәшриятында аның тагын алты китабы дөнья күрде.

XX гасырның азакны фазасында нинди мөмкинлекләр ачылган иде бит, югыйсә, империя табаннынан

Наис Гамбәр, Нәбирә Гыйматдинова, Фәннур Сафин, Рәшит Хәертдинов, Мөдәррис Әгъләм, Марсель Галиев. 1975 ел

котылып, кардәш төрки халыклар, мөстәкыйльлек яулап, үз дәүләтчелеген төзүгә ирештеләр. Безнең тарафка да азатлык җилләре сирпелеп алды. Матур алдану хасиятендә өмет ярлары киңәеп, тормыш-көнкүрешебез кайнап, дәртсенеп ага башлады. Иркен сулыш алып, язарга да язарга, гамь тулы күңелләрне бушатырга иде югыйсә…

Әмма бу дөньяда бөтен шагыйрьләргә дә уртак бер фал бар: әйтеләсе сүзләре әйтелеп бетмичә гомереннән артып кала шул. Нишлисең… тәкъбирдән өстен — Тәкъдир…

Нидер сизенепме, каләмдәшебез Фәннур «Айлы төндә» дигән шигырендә әтисе рухына дәшеп:

… Нәрсә булыр, әткәй, кешеләргә
Әйтер сүзем белән кичексәм?! —
дип язып куйган булган.

***

Төнге Казан. Истәлекләргә бирелеп, Кызыл Позиция урамыннан яшьлегебез үткән тулай торагыбызга таба атлыйм. Бөтен тәрәзәләрен балкыткан «Титаник» корабы шикелле, мәһабәт булып, торагыбыз каршыга «йөзеп» килә. Купләребез, үз парларын табып, шуннан бит инде олы дөньяга таралыштык. Фәннур да, яңа танышкан алтынсу чәчле, зәңгәр күзле кызыкай белән култыклашып, тормыш лабиринтларына кереп күмелде:

Җирдә азмы андый бәхетләләр
Бу мизгелдә, шушы минутта?!
Бер бушанып нигә үксемәскә
Күңел тулы дулкын булып та,
Йөрәкләргә ялкын булып та.

Язмышының кайсы чатларында язылган булды икән, аны — әле куаныч, әле фаҗига, әле хыянәт көтәсе? Кайсы борылышта көтте икән тома ялгыз каласы? — Болар инде башка поэма…

Тәкъдир аңа кырык дүрт ел гомер биргән. 1992 елның декабрь соңында, Яңа елга керергә сәгатьләр генә калып барган бер мизгелдә… ялгызак бүлмәсендә… кайчандыр: *«Ә сыната калсак, мәктәп безгә кыңгыраулар белән дәшәр күк»,* — дип язган шагыйребезне үкенечле үлем булып килгән әҗәл, кыңгырау кагып, уятмый шул, уята алмый… Төшендә төтенсу томаннар аша малайчак аланнарына омтылган шагыйрьнең җаны, гүя, кошка әверелеп, асмани киңлекләргә, сыктап, очкандыр. Мәңгелеккә…

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ МИРАСЫННАН

ФӘННУР САФИН
(1948 - 1992)

МУЗЕЙ АЧТЫМ...

Мин гаҗәеп музей ачтым.
Анда
Фатих Кәрим язган каләм бар.
Мин өр-яңа музей ачтым.
Анда
Кутуй кайта, дигән хәбәр бар.

Минем музеемда Мөҗәйләрдән,
Алишлардан яңа хатлар бар.
Анда Җәлил ярсып шигырь укый!
Ә янында...
аның башын кискән балта бар.

Музеемда —
канәфер чәчәкләре,
кашкарыйлар,
кыргый гөләпләр.
Ядрә тишеп үткән йөрәкләр бар,
үтерелгән җырлар,
теләкләр...
Музеемда — каен тузы түгел —
ә кешеләр янган мичләр бар,
һәм солдатлар сөйгән хатыннарын
соңгы тапкыр кочкан кичләр бар...
Ярсу хисләр, бетмәс үчләр бар!..

Табалмассыз ләкин ул музейны,
җитсәгез дә җирнең читенә...
Яңа музей — минем йөрәгемдә,
килегез сез аңа,
Кешеләр!..

«СИҢА МОҢСУ ТҮГЕЛМЕ?..»*

Һаман, һаман яңгырый сыман,
Тетрәндереп күңелне,
Һаман шул ук, бер үк сорау:
«Сиңа моңсу түгелме?..»
Шагыйрь канын яңгыр юмый,
Каплый алмый карлар да.
Моңсу сорау йөрәкләрдә
кабатлана, яңара.
Моңсудыр дип уйлаган ул,
әйткәннәре расмыни?
Муса Җәлил, Фатих Кәрим...
Алар бездә азмыни?
Хаклык өчен янды алар,
Ялкыннарга күмелде.
Оча еллар һәм гасырлар...
«Сиңа моңсу түгелме?..»
Җил яралый алыр җанны
кемнәр генә таламый!
Каплананалар амбразурага,
Безгә шунсыз ярамый дип,
Ахры, мәңге ярамый! —
Кемдер җанны яралый.
Капландылар зур шагыйрьләр,
Күпме каннар түгелде.
Әйт, син, дөнья, әйт, кешелек:
— Сиңа моңсу түгелме?..
Йә, күтәрик авыррагын,
Күп күтәрдек җиңелне...
Ак калфаксыз Казан кызы,
Сиңа моңсу түгелме?
Сиңа моңсу түгелме?..
Һәйкәл булып кала ул моң,
Җырлар булып тарала.
Җырны халык отып ала,
Йөрәк түренә сала.

* Ялы Пушкин сүзләре

ЧӘЧӘК ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Мәхәббәтен гөлләр итеп
яшь кыз кулъяулык чиккән.
Ал чәчәкләр белән бергә
йөрәген бүләк иткән...

Йә ялгыз, йә дәррәү кубып,
тәннән, рухтан, чүлләрдән
адәм заты мәңге шулай
бәхет гөлен эзләгән.

Гомер буе сихри гөлне
бер югалткан, бер тапкан.
Бәхет серен эзләгән ул
йолдызлардан, учактан.

Әүвәл коелган корычта да
бәхет гөлен күргән ул.
Шул гөл өчен утларга да,
суларга да кергән ул.
Туракланса, бәхет үлә,
Бәхет тормый калҗадан. —
Мәңгелек булсын дип оста
таштан чәчәк ясаган.

— Сезгә күп сәлам, — дип әнә, —
үткәннән, киләчәктән! —
Ялан буйлап, ярсып-кайнап
йөгерәләр чәчәкләр.

Кушыла алар гомергә
көннәр һәм төннәр булып.
Кинәт яуган кар шикелле,
чәчләрдә кала кунып.
Чәчәк гомере — безнең гомер,
безнең яшәү, дусларым.
Аждаһаңа бирмә ләкин
гөл бакчасын — Җир шарын!

Күк чәчәктәй аяз күген,
Иминлек җырын сакла!
Ил-дәүләтләр яну нигә,
гөлгә күмелер чакта?!

Син күр әнә, йә, күрсәнә:
гел бәхет юрап бары
кыз бала кулъяулык чигә.
Уенда — сөйгән яры.

САГЫНАМ

Мин дәүләтсез падишадай булам
читтә ялгыз калган чагымда.
Кояшларга карап елмаям мин,
сары айга карап сагынам...

Тентүләрдә туздырылган йорттай
тәртипсез уй түгел башымда, —
ераклардан җәһәт кенә килеп,
син торасың кебек каршымда!

Мин каладан авылыма таба
сузылып киткән юлга күз атам.
Тәрәзәмне ачып, уйларымны
туган якларыма озатам...

Ак күгәрчен булып оча хыял
иң бәхетле узган чагыма.
...Кояшларга карап елмаям мин,
сары айга карап сагынам.

ЯШЬ ТАЙ

Давыл булып чаба, тибенә...
Теш кычытканга түгел һич
болдырларны кимерә...

Юашларга карый ятсынып...
Төн пәрдәсен умыра ул,
таң тизрәк атсын дип...

Гамьсезләрдән ерак кача ул...
Упкыннарга очраганда
аягүрә баса ул...

Бары ирек аның иманы...
Йөгән тотып килсәң, — әзер
маңгаеңа тоягы...
Ат йөрәге нидер сизенә...
Теш кычытканга түгел һич
болытларга үрелә!.. ■

МИЛЛИ МӘЗӘКЛӘР

«Шура» журналыннан, 1904-1908 еллар

КУРКЫП КЫНА...

Вәкыйгъ бине Әсвәд Хорасанда вакытында мөнбәргә менеп хотбә укыды вә хотбәсендә: «Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре җир илә күкне алты ай эчендә яратты», — диде. Бер адәм торып: «Хата сөйләдең! Җәнабе Аллаһ җир илә күкне алты көндә яратканы турында хәбәр бирмештер», — дигәч, хатыйб: «Алты айны да азсынып, куркып кына әйткән идем», — диде.

ҮЗЕ БӘРЕЛДЕ

Гарәпләрдән бере үтеп баручының башын таш атып ярмыш иде. Шуның өчен бу гарәпне казый хозурына китерделәр. Казый: «Ни өчен таш атып, бу кешенең башын ярдың», дип сорагач, гарәп: «И казый, тугрысын сөйлим, мин таш илә моның башына атмадым, бәлки бу кеше үзе минем аткан ташка килеп башы илә бәрелде!» — дип җавап бирде.

НИКАХ МӘҖЛЕСЕНДӘ БУЛМАГАН

— Иблиснең хатыны ни исемле? — дип сораган адәмгә Шәгъбә хәзрәтләре:

— Аларның никах мәҗлесләрендә булмадым! — дип җавап бирмештер.

СӘҖДӘГӘ КИТҮ ИХТИМАЛЫ

Фатирда торучы бер адәм йорт хуҗасына барып: «Өй чытырдый, төзәтәсе иде», — дигәч, хуҗа: «Курыкма, безнең өебез Аллаһ тәсбих итмәктәдер!» — дип җавап биргән. Адәм моңа каршы: «Өйнең дәрвишлегендә шөбһәм юк, фәкать кайбер вакыт күңеле бик нечкәреп, сәҗдәгә китү ихтималы бар, шулай була калса, безнең эш харап!» — дигән.

АКЧАСЫ БУЛСА ГЫНА

Тыйб (медицина) мөгаллиме имтихан нияте белән үзенең шәкертеннән: «Бер хастаны карый башлаганда иң элек ни кеби хәлләргә дикъкать итәсең?» — дип сораган. Шәкерте исә: «Акчасы булу-булмасына!» — дип җавап бирмештер.

Җыючы — ***Равил Әмирхан***

СӘНГАТИ МИРАС

Үз уенымны уйнадым, шөкер,
Бу тормыш сәхнәсендә...

Роберт Әхмәтҗанов

МИЛЛИ МИРАС САГЫНДА

ФИЛҮСӘ АРСЛАН

Һәр халыкның тарихта тоткан урыны аның дөнья мәдәниятенә керткән өлеше һәм шул уртак хәзинәдән файдалана белү сәләте белән билгеләнә.

Габдулла Тукайның халык җырларына кагылышлы фикерләре бүген бик актуаль: *«Халык җырлары — безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр… Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска, иҗтиһад итәргә кирәк…»* — дигән ул.

Энҗе-мәрҗәннәрдән дә кыйммәтле милли-мәдәни мирасыбызны барлау, саклау һәм аны янә халыкка җиткерү, буыннан-буынга тапшыру ише гаять җаваплы миссияне ошбу язмабызның каһарманы Гөлзадә Сафиуллина кебек фидакарь сәнгатькярләребез гамәлгә ашырып килә…

Татарстанның халык артисты, Республиканың М.Җәлил исемендәге бүләк иясе, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, җәмәгать әйдаманы, Бөтендөнья төрки хатын-кызларының бердәмлек һәм теләктәшлек җәмгыяте президиумы әгъзасы, «Сөембикә варислары» төрки-татар балалар фестивален оештыручы, «Гөлзадә» студиясе хуҗабикәсе… Зыялы татар хатын-кызларына гына хас якты нур чәчеп торган бу ханымны радио-телевидение аша, сәхнәләрдә, җәмәгать урыннарында күреп, газет-журналларда чыккан язмалардан, шулай ук үз язмаларыннан да беләбез.

Күп гасырлар буена җыр башкару тел традициясе белән яшәп килгән. Халык җырчылары үзләренең осталыгын телдән бирүнең традицион юлларын дәвам итеп, җырлауның милли мәктәбен булдырганнар. Халыкча ысул белән җырлап, җыр-моң байлыгыбызны дөньяга таныткан бөек шәхесләребез элек тә булган һәм хәзер дә бар. Г.Сөләйманова, З.Басыйрова, Р.Ильясов, Г.Рәхимкулов, И.Шакиров, Ә.Афзалова кебекләрнең традицияләрен дәвам иткән, башкару сәнгатенә бик тә оригиналь яңалыклар алып кергән Гөлзадә Сафиуллинаның халкыбызның мәдәни мирасын саклауга керткән олуг хезмәтен өч өлешкә бүлеп карау мөһимдер. Беренчесе, җырчы буларак — иҗат, концерт эшчәнлеге; икенчесе — «Гөлзадә» иҗат студиясе; өченчесе —«Сөембикә варислары» төрки-татар балалар иҗаты фестивале.

Гөлзадә Сафиуллина, Разил Вәлиев, Сервер Кокура һәм Илдус Тарханов. Кырым. 2002 ел

Сөембикә варислары фестивале. Алгы планда – Сәйдә абыстай Аппакова

Гөлзадә Сафиуллина көчле матур тембрлы җете тавышы, үзенә генә хас моңы белән, күпкырлы талантлы артист буларак, безнең күз алдында, Тукай әйткәнчә, чын безнеңчә матур итеп, халыкча башкару остасы булып үсте. Җыры белән генә түгел, киемнәре, үз-үзен тотышы, сәхнәдәге килешле хәрәкәтләре, халык белән аралашуы, кешеләр белән мөгамәләсе — барысы да үзебезчә, милли. *«Мөнәҗәтләрне ул инде онытылып, югалып бара торган борынгы киемнәрен киеп, милләтебез кулланган борынгы шәмдәлләр, уен кораллары белән оста файдаланып, тәэсирле итеп, матур мәкамнәр белән көйли. Аның дини тәрбияви чыгышлары ышандыра, ихлас күңелдән башкарыла»,* — дип язды заманында Г.Тукай бүләге иясе, шагыйрә Гөлшат апа Зәйнашева.

Арча районының Шекә авылында җырлы-моңлы сигез балалы гаиләдә дүртенчесе булып үскән Гөлзадә Са-

Һиндстан, Хәйдәрабад штаты. Концерттан соң бүләк кабул итү

фиуллина җыр сәнгатендә очраклы кеше түгел. Аның оештыру сәяте дә бик иртә — балачактан табигать кочагында җырлап-биеп, авыл балаларына концертлар куеп ачыла. Әтисе Гомәр абый балаларын хезмәт белән тәрбияли. Авылда 7 сыйныф белем алган кызын ул фермага сыер саварга урнаштыра. Әмма Гөлзадәдә уку, югары белем алу теләге көчле була, бәхетенә туган авылында кичке мәктәп тә ачыла. Аны тәмамлагач, Казан дәүләт ветеринария институтында белем ала. Аннан Үзбәкстандагы иң зур кошчылык фабрикасында табиб булып эшли. Мәктәптә чагында да, институтның хорында да җырлый, драмтүгәрәккә йөри, үзешчәннәрнең җыр бәйгеләрендә катнашып, беренче урыннарны яулый. Ташкентта «Дуслык» исемле үзешчән татар ансамбле оештыра.

Гөлзадә җырлау мәктәбен Илһам Шакиров белән Әлфия Афзаловадан, аларның концертларын алып баручы, сүз остасы булып эшләгәндә ала. Чөнки ул заманнарда да филармониядә җырчыдан махсус белеме булуын шарт итеп куялар. Сөекле ире Риф Сафиуллин консерватория тәмамлаган, баритон тавышлы бу җырчының киңәшләре дә аңа ярдәм иткәндер. Зөләйха Хисмәтуллинадан да Гөлзадә сулыш белән эш итү, диапозонны киңәйтү, регистрларны тигезләү кебек җырчы өчен мөһим сыйфат-гамәлләргә өйрәнә. Табигатьтән куелган халыкчан тавышка академик ысул белеме мөһим шарт түгеллеген белеп укыткан остаз иде Зөләйха апа (урыны җәннәттә булсын). Шулай җыр дөньясына Гөлзадә урау-урау юллар белән килә, вокал белеме алып, опера җырчысы түгел, халыкка хезмәт итә торган халыкчан җырлау остасы булып кала ул.

Гөлзадәдә — табигать тудырган чиста, яңгыравык, күп вакыт кыюгаярь, шук-шаян да яңгыраган «очa торган» тавыш. Вакыты-вакыты белән ургып, вакыты-вакыты белән киңәеп

киткән тавышы белән һәр чыгышы саен такыя үреп бирә. Ул җырда тирән моң-бизәкләрне урынлы куллану маһирлыгына ия. Табигый тавышта гына яшәгән моңны рух көзгесе, дибез ич. Кешенең рухы нинди — тавыш матурлыгы да шундый. Гөлзадә моңының күңелне, уйларны үзенә тарта, ияртә, үзенең омтылышына буйсындыра торган хасияте бар. Башкару характеры үзенчәлекле: гади дә, гали дә, ихласлыгы белән ышандыра, сәнгати образны таба, бай рухлы, миһербанлы, кешелекле, моң ташкыны күңеленнән ашкынып, чишмә сыман ургылып чыга! Ул тавыш белән нечкә эш итә, тавышын җырлаганда чыңлатып-чыңлатып җибәрә ала. Бу моңга аерым бер үзенчәлекле бизәк өсти.

Репертуардагы җырларының текстына килгәндә, дөньяга үз карашы, үз тәрбиясе биргәнне генә эзләп сайлый ул. Җырның мәгънәсен, эчтәлеген, тарихын аңламыйча җырлау мөмкин дә түгел. Арча якларының башкару традицияләрен дәвам иткән җырчыларның берсе булып, йөрәкләргә дәва булып, сүнгән күңелләргә нур булып, тыңлаучы күңеленә кереп урнаша. Халыктан өйрәнеп, отып алып, халыкча башкару манерасын бер дә үзгәртмичә, югары кимәлдә халыкка кире кайтара. Җыр аның өчен эш түгел — тормыш, язмыш һәм җирдә яшәвенең куанычы, юанычы, ләззәте ул. Аның тормышындагы зур борылыш мәлләре дә җырга бәйләнгән.

1980 елда Гөлзадәнең иң беренче концерт программасы Харрас Әюповның «Кеше тавышы» дип аталган поэмасына салынган каһарман җырлар циклы белән башланды. Ул бик күп җирләрдә — мәктәпләрдә, пионер лагерьларында, авылларда булып, бушлай һәм тынычлык фондына атап бик күп концертлар бирә. 1985 елда шушы концертлары өчен Комсомол өлкә комитетының М.Җәлил исемендәге бүләгенә лаек була һәм Бөтендөнья яшьләр фестиваленә җибәрелә. Шул ук елны Опера һәм балет театрының концерт төркеменә эшкә чакырыла. Шуннан соң инде үзенең төрле концерт программалары белән татарлар яшәгән бөтен төбәкләрне берничә тапкыр урый. Дистәләгән концерт программаларыннан берничәсен атап үтик: «Кеше тавышы», «Йөрәкләрне җыр кавыштыра», «Ат елы бу, әйе», «Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә», «Безгә дөнья дәшә» (балалар өчен программа), 20 еллык иҗат эшчәнлегенә концерт программасы, «Мәрхабә» — мөнәҗәтләр һәм татар халык җырлары кичәсе, «Җиңүнең 50 еллыгына багышланган хәйрия концертын, «Мин дә сибелгән татарның бер газиз баласы ла...», «Әй, моң дәрьясы, бер тамчың булсам иде», «И, туган телем, и, газиз җирем», «Минем җырым», «Үлемсез Ил җыры» һ.б.

Республикабыз радио фондында Гөлзадә башкаруында 150дән артык җыр, Татарстан дәүләт теле-радиокомпаниясе фондында 8 концерты саклана, аның тарафыннан 2 грампластинка дөнья күрде — «Мөнәҗәтләр, бәетләр» (1993) һәм «Сине эзлим» — татар халык һәм композиторлар җырлары. Бу пластинкалар бөтен татар дөньясына таратылды.

Гөлзадә — мөнәҗәт-бәетләрне бөртекләп җыеп, беренчеләрдән булып, дини мәкамнәребезне янәдән халыкка җиткерүче дә. Аның мөнәҗәтләр әйткәндә ышандыра алырлык үз алымнары, манерасы бар. Ике тапкыр Америкада булып, шунда яшәүче татарларга да, беренчеләрдән булып, Татарстан иләндәге җыр-моңнарны ирештерде ул. Бу очрашулардан яңа җырлар, мөнәҗәтләр дә алып кайтты. Мисалга, «Абау, Алла» җырын Татарстанга алып кайтып, халык җыры дәрәҗәсенә күтәрде. I Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә Гөлзадәнең Америка татарлары турында үзе төшергән

фильмы Татарстан телевидениесе аша күрсәтелде.

1990 елда, әле Советлар союзының таркалмаган чагында ук, ул Греция, Италия, Франция, Мальта, Кипр, Израиль, Төркия, Мисыр илләренең зур сәхнәләрендә дөньяның иң танылган җырчылары белән беррәттән татар халык җырларын җырлый һәм мөнәҗәтләр әйтә иде. Шушы мәдәни миссиядә Гөлзадә татар халык җырларының, мөнәҗәтләренең тылсымлы көчкә ия булуын аңлады. Анда катнашу аңа бөтендөнья фольклор фестивальләренә юл ачты — рухи юнәлештәге тәрбияви җырлар белән ул бик күп илләрне урады. Төрки халыкларга багышланган «Күңел багы» тапшыруында Гөлзадәнең 40 минутлык фольклор әсәрләреннән төзелгән концерт программасы (ул бүген Төркия дәүләт телевидениесе фондында саклана) язылды. Балтыйк буе илләрендә, Байконурда, нугай далаларында ул, беренче булып, татар җырларын яңгыратты...

Гөлзадә Мәскәүгә барып тавыш белән дәвалау терапиясе институтында курслар үтә, дүрт тапкыр Һиндстанда булып, тын алу күнекмәләре, йога һәм фәлсәфә юнәлешендә шөгыльләнә. Иҗаты һәм яшәеше белән дә рухи өлгереп, Мәккә каласына өч мәртәбә хаҗ кылды.

***

...90 нчы елларда, халкыбызның үзаңы уяна башлаган чорда, аның җыры, концерт залларына гына сыеша алмыйча, бәйсезлек өчен көрәш барганда Ирек мәйданнарына бәреп чыкты. Гөлзадә җырлары белән милләтнең йөрәк ярасын дәвалаган, Ил язмышы өчен көрәшкә өндәгән үз кызы булды татарның! Бөтендөнья төрки хатын-кызларының бердәмлек һәм теләктәшлек Корылтайларында катнашып, халкыбызның бәйсезлеген яклап, үз сүзен ирештерүче дә ул. Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәш барган елларда милләт кызы Гөлзадә җыры белән генә түгел, бик күп милли чараларны оештыруда матди ярдәм күрсәтеп, татар меценатлары исемлеген дәвам иттерүчеләр рәтенә керде.

Иҗаты җыр кысаларына гына сый-

мыйча, Гөлзадә үзенең иҗат студиясен төзеде. Анда ул милләтебезнең бай мәдәни мирасын пропагандалау эшен җәелдереп җибәрде. Рухи мирасыбызга багышланган бихисап тематик аудио-альбомнар чыгарды. Алар күрсәтмә әсбаплар сыйфатында татар балалар бакчаларына, мәктәпләргә һәм училищеларга таратылды. Шулай ук һөнәри урта, мәдәният һәм сәнгать югары уку йортларында да кулланыш таптылар алар. Филармониянең сәнгать җитәкчесе Илгиз Мәҗитов эшләгән чорда ук Гөлзаданең мөнәҗәтләр, халык җырлары, эстрада, композиторлар әсәрләре, балалар өчен җырлардан төзелгән 7 кассета чыккач, Илгиз Габидулла улы: «Бу бит татарның җыр энциклопедиясе!» — дип, аларга югары бәя бирә.

Беренче булып «Рухи мирас» серияләреннән дин программасы буенча 13 аудиокассетадан торган «Коръән-Кәрим тәфсире»ндә аятьләрнең һәм сүрәләрнең эчтәлеге аңлатыла, «Галәм тарихы» — җир һәм Адәм (г.һ.с.)нән алып Мөхәммәт (г.һ.с.)гә кадәрге пәйгамбәрләр тарихына багышлана, «Пәйгамбәрләр тарихы», «Һәфтияк Шәриф», «Иң матур Азан», Коръәндәге иң сихәтле догалар язмасы, «Борынгы татар мәкаме белән Коръән»не уку, «Борынгы моңнар» — Җәмил Зәйнуллин башкаруында Казан татарлары мөнәҗәтләре (Татар дәүләт кыллы квартет белән берлектә) һ.б. язмалар дөнья күрде.

Әдәби мирасыбыз сериясеннән язмалар да беренчеләрдән булып дөнья күрде. Флёра Гыйззәтуллинаның «Җан авазы» аудиоальбомы, кече яшьтәге балалар өчен «Җыр агачы» шигырьләр бәйләме — Айрат Арсланов башкаруында иң яхшы шигырь үрнәкләре тупланмасы, «Ниса» — Розалина Шаһиева шигырьләре тупланмасы. «Яшә, телем!» — аудиоальбомы күренекле мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралының тууына 150 елга, кырымтатар һәм татар шагыйрьләренең шигырьләре, «Шанлы Казан» — Казанның 1000 еллыгына багышлана. Казан турында шигырьләрне А.Арсланов укый, җырларны И.Шакиров һәм А.Аббасов башкара. Шул ук дискта «Сөембикә» җырын Гөлзадә үзе җырлый. «Мин — табигать баласы» — язучы Дания Гайнетдинованың туган як, ана, табигать темасына кыска хикәяләре һ.б.

«Музыкаль мирас» тупланмасында «Моң дәрьясы сериясеннән «Сәйдәштән — Сәйдәшкә» аудиоальбомы С.Сәйдәшевның 100 еллыгына Сәйдәш Гарифуллин башкаруында композитор әсәрләренең джаз эшкәртмәләре, «Татар халык көйләре» — Сәйдәш Гарифуллинның джаз эшкәртүендә, «Татар халык көйләре» — Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге халык уен кораллары ансамбле, «Татар халык көйләре»н исә — Рамил Курамшин тарихи баянда башкара. «Саз» ансамбле җырлары — Рифкат Гомәровны искә алып, «Мәңге яшисе килә» — Фәтхрахман Әхмәдиевның популяр җырлары, «Ак каеннар шаулый» — Илгиз Мәҗитов җырлары, «Кыр казлары артыннан» — Исламия Мәхмүтова башкаруында спектакльләрдән җырлар, үз язмаларыннан мөнәҗәтләр, халык һәм композитор җырлары, һәм дә башка бик күп шәхесләрнең иҗади аудиоязмалары дөнья күрде. Ул балалар фольклоры сериясеннән дә аудио һәм видеоматериаллар яздыра. Үз язмаларыннан: «Мөнәҗәтләр һәм бәетләр», «Көзге ачы җилләрдә» (татар халык җырлары), «Яшьлегем чәчәк атканда» (татар композиторлары әсәрләре), «Серле йөрәк» (күренекле шагыйрьләр сүзләренә Риф Гатауллин көйләре), «Җырым канат булсын» (халык җырлары белән композитор әсәрләре), соңгы елларда балалар өчен дөнья күргән «Шат чак», «Куль-Куль Җиһан» (мөнәҗәт, бәетләр), «Каршы ал, туган ягым» (туган җиргә, Ватанга

багышланган җырлар), «Үлемсез Ил җыры» (каһарман җырлар) һ.б. аудиоязмалары халык арасында киң танылa.

Гөлзадә ханым 1990 елда «Мирас» ширкате төзи. Шул ук елны — концерт һәм студия эшчәнлеге белән генә чикләнми — халкыбызның мәдәни-рухи байлыгын телдән-телгә тапшыру кирәклеген аңлап, «Мирас» балалар ансамбле оештыра. Биредә балаларны музыка вә җыр сәнгатенә өйрәтер өчен оста музыкантлар чакырыла. Күренекле композитор Фасил Әхмәтов та байтак еллар ансамбльдә балаларны музыка серләренә өйрәтте.

1999 елдан бирле төрки-татар балаларының «Сөембикә варислары» фестивале уздырыла.

Шул елдан алып, бүгенгәчә бер йомгаклау концертларында гына да Идел-Урал, Себер, Кавказ, Мәскәү, Украина, Кырым, Балтыйк буе, Урта Азия һәм Казахстаннан ун меңнән артык бала катнашты. Фестивальнең лауреат һәм дипломантлары үзләрен иҗади актив, талантлы яшьләр итеп күрсәтеп, исбатлап килә. Аларны бүген радио-телевидениедән ишетергә, Казан һәм Ялтада гына түгел, Рәсәй төбәкләре һәм чит илләрнең концерт залларында да күрергә була.

Шулар белән беррәттән, Гөлзадә төрки халыклар белән элемтә оештыруда, аларны рухи якынлаштыруда гаять зур эш алып бара. Аның тырышлыгы белән ике тугандаш халык — Казан һәм Кырым татарлары арасында дуслык күпере салынды. Татарстан белән Кырым республикасы арасында мәдәни-гамәли хезмәттәшлеккә юл ачылды.

Гөлзадә, Бөтендөнья татар конгрессы белән хезмәттәшлектә, татарлар яши торган Литва, Себер, Кавказ, Ставрополь, Урал (Җаек), Ташкент, Бохара, Урта Азия республикаларында булып, милләттәшләребез алдында биһисап чыгышлар ясый. 2012 елда Ерак Көнчыгышта Находка, Уссурийски, Артём һәм Владивосток шәһәрләрендә, татарларыбызны туплап, фольклор ансамбле төзеп, Рәсәй күләмендәге Сабан туена җыеп алып чыкты. Кая гына барса да, ул үзенең чыгышларын тарихыбыз, динебез, мәдәниятебез, бөек шәхесләребез турында сөйләүдән башлый.

Гөлзадә, Тукайга охшатыбрак әйтсәк, коеп куйган артист кына түгел, шул җыр-моңы аша милләтнең сәләтле балаларын дөньяга таныту, рухи-мәдәни мирасыбызны саклау һәм халыкка кайтару өчен янып йөргән булдыклы эшмәкәр дә. Кызы Резидәсе өчен шәфкатьле ана да, өч зирәк оныгы өчен яраткан дәү әни дә.

Гөлзадә Сафиуллина — һичшиксез, татар җыр сәнгате дөньясында үз урынын тапкан, һәм үз сүзен әйтүче уникаль шәхес. Ул үзенең моңнары белән милләт күңеленә үтеп керә алды. Җырлары һәрвакыт дуслыкка, яктылыкка, сафлыкка өнди, садә хистойгылар уята, игелекле эшләргә чакыра... Ул — халкыбызның мирасын җыючы да, энҗе-мәрҗән итеп туплаучы да, кадерен белеп саклап, алдагы буыннарга тапшыручы да!

Язмамны күренекле әдибебез Марсель Галиевнең «Рух» китабыннан бер өзек китереп тәмамлыйм. Ул Гөлзадәбезнең асылын, рухын, тоткан мәсләген төгәл ачып бирә шикелле:

Җырла син, сулкылдасын бәгырь,
Тетрәнсен рух, җылатып юат мәртәбәле татар дөньясын.
Җырла син, моң галәмендә ни гамь бар.
Сөйлә безгә күңелләрне сыгылдырып, моңай бер,
Тарих пәрдәләре артында үткән зурлыкларның даны ачылсын! ■

ЗӨЛӘЙХА

ӘХТӘМ ЗАРИПОВ

«Айга менеп, түбән карап,
сине күрәсем килә...»
(«Зөләйха» җырыннан)

...Без Ватан сугышы чорында үстек. Ничәнче елда икәнен хәтерләмим (урак өстендәге яңгырлы көн иде), концерт бригадасы белән килгән баянчы белән биючене безгә фатирга керттеләр. Ул чакта артистларны фатирга алу чиратсыз дефицит товар табуга тиң иде. Концертка бушлай керү мөмкинлеге генә түгел, «артистлы булу» да абруй санала иде.

...Безгә артистлар кертелүнең төп сәбәбе — 18 яшендә сугышта үтерелгән баянчы абыйда һәм аның баянында булгандыр, дип уйлыйм. Фронтка алынганчы абыем күпмедер вакыт районның колхоз-совхоз театрында баянчы-артист булып эшләп алган. Нинди артист булуы турында беркем, берни белмәсә дә, әнкәй өчен һәр килгән концерт группасы «театр», андагы һәркем «артист» буларак кабул ителә иде. Әгәр клуб мөдире онытыпмы, башка сәбәптәнме, «театр» килеп, «артист» безгә кермәсә, әнкәй аны «дулап», үзе барып алыр иде.

Бу юлы да урамга чыкмаслык яңгырлы көндә, алдан әйтмичә-килешенмичә, юешләнеп-күшегеп беткән ике артист китерелгәч, хәсрәтле утырган әнкәй, кинәт җанланып киткәндәй, кунакларны рәхмәт әйтеп каршылый, бик тиз генә мичкә ягып җибәрә, казан астына ут кабыза.

Икенче көнне бердәнбер куыкны берәрсе чатнатып китерсә дә, орышмый әнкәй, «куык түгел — үзебез дә чатныйбыз» дип, аны артистлар биреп калдырган такта чәй белән сыйлый. Бу, әлбәттә, артистлар кертүе өчен аның рәхмәт белдерү йоласын үтәве була.

Әйе — шулай... Артистлар кергәнче оек-бияләй бәйләүдән генә онытылу тапкан әнкәйнең хәсрәтле йөзе ачылып киткәндәй була. Сүз арты сүздән соң, үзара ияләшә төшкәч, гармун биштәре асып кергән апайга абыйның баянын бирә дә ул: «Чәй өлгергәнче уйнап күрсәтмәссеңме!» — ди.

...Ябык йөзле мөлаем апай, безнең баянны алдына алуга, аны «тегеләй-болай» тарткалап, телләрен баскалап-төрткәләп карагач: «Бераз караштырасы бар икән шул», — дип читкә этәреп куя. Өйдә озакка сузылган тынлык урнаша. Мин, әлбәттә, хатын-кыз турында — алар гармун уйный белмиләр һәм белергә тиеш тә түгелләр, дигән катгый караштa булганлыктан, моңа һич тә аптырамадым, эчемнән генә «әйдә-хәйләлә», дип кенә куйдым. Әнкәй исә елау хәлендә: «Баламны нишләткәннәр?..» — диде дә, миңа карады.

Бу караш: «Син генә ваткансың!» — дип хөкем итү карашы иде.

...Яңа уңыш бәрәңгесе ашап, чәй эчкәннән соң, ябык чырайлы бу мөлаем апай, баяныбызның эчен актарып,

Узган гасырның утызынчы еллары. Милләтебезнең асыл затлары: Мөхәммәт Садри, Зөләйха Әхмәтова, Җәүдәт Фәйзи, Хәсән Гобәйдуллин һәм Наилә Рәхмәтуллина

нәрсәләрендер борыштырып, үзе белән йөрткән җилем белән сахтыяннарын беркетеп, төзәткәндәй иткәч, бик озын бер көй уйнады, аны «яңа ишеткән көй», диде. Сүз әйтү хокукым алынганлыктан, һәм дә, тыңлаган бу озын көйдән тылсымланудан мин катып калган идем.

Апай уйнап кына туктамады, икенче бер көйгә күчеп, моңлы тавышы белән җырлады да: «Сагынасыңмы?» — дип сорыйсың, сагынмаган кая ул...» Бусы да безнең өчен яңа көй иде...

...Бераздан җырга әнкәй дә кушылды. Икәүләп 2-3 көй җырладылар. Аннары әнкәй, абыйдан калган бер көйгә, баянсыз гына җырлап күрсәтте дә, шуны кабатлап баянда уйнарга кушты: «Мәрхүм улым шушы көйне ярата иде», — диде.

Ул көйне соңрак мин дә өйрәндем. Мин аны баянчы апайның соңрак «Зөләйха апага бүләк» дигәненнән чыгып, Зөләйха көе дип уйный идем.

Баянчы апай әнкәй җырлап күрсәткән исемсез бу көйне үзенчә кәгазенә сызгалап, «Зөләйха апага тагы бер бүләк» дип, иптәшенә әйткәнен дә ишетеп калдым...

Мин аның үзе өчен оригиналь тоелган халык көйләрен «нотага язып» бару һәм аларны Зөләйха Әхмәтовага кайтарып бирүе турында шушы язмама материаллар эзли башлагач кына белдем.

Күңеле булганчы баян тыңлагач, җырлагач, әнкәй, абый кайткандагыдай куанып, баянчы апайга үзе бәйләгән йон перчатка бүләк итте, «бармакларыңны өшетүдән һәм күз тиюдән сакла», дип ниндидер балдак-йөзек кияргә киңәш бирде, аннары ярты каз түшкәсе турап, тары өйрәсе пешерде. Ул көннең калганы барыбыз өчен дә бәйрәмгә тиң узды.

...Оста баянчы уенынннан тәэсирләнүем никадәр көчле булса, шулкадәр ныклы ышаныч белән үземә-үзем сүз бирүем дә хәтердә: «Мин дә шулай уйнарлык өйрәнергә тиешмен!»

Бик кызганыч, әлбәттә, сүземдә тора алмадым. Музыкант чыкмады миннән, берничә гармун һәм баян алып карасам да, һәвәскәрлектән узмадым, тыңлаучы гына булып калдым.

...Бу һөнәр минем хыялым булып яшәде һәм яши...

...Тормышка ашмаган хыяллары һәркемнең дә бардыр... Сүзем — үз хыялларын тормышка ашырган талантлар турында.

...Язмамны могҗизалар тудырган баянчы белән очрашу хатирәсеннән башладым. Ләкин бусы әле чын очрашу булмаган икән, анысы соңрак булган икән...

...Сугыш беткәч, исән калганнар илгә кайта башлады...

Бер аягын калдырып, «немец гармуны» (аккордеон) алып кайткан Әфка абый, култык таякларына таянып, капка төбендәге урындыкка чыгып утырыр иде дә, күргән-белгәннәрен сөйләгәч, немец гармунын чыгартыр иде... «Әйдә, акырсын аккордион!» — янәсе.

Белгәне — ике көй: «Ночь тиха» һәм «Катюша». Үзе уйнап, үзе җырлый да, ахырдан елый иде ул. Елау — таралашырга сигнал: Әфка абый өенә таба атлый...

...Соңрак аны клубка «вечер уйнатырга» алып китә башлыйлар. Биетергә дә аның бер генә көе бар: «Барыня». Яшь-җилкенчәк, сукыр лампаларда керәчине беткәнче, шул көйгә сикерә. Башка көйләр уйный белмәвен Әфка абый бер генә җөмлә белән: «Фрунтта Казан радиосы сөйләми», — дия иде.

Яшьләр «Барыня»га да бик күп сикерә алмыйлар, чөнки Әфка абыйны колхозның баш бухгалтеры итеп куялар. Начальник булгач, гармун уйныймы кеше? Уйнамый, әлбәттә...

Аның бу үсешеннән соң «кәнсә» дигән идарә йортыннан төрле хәбәрләр тарала башлый: яңа заемнар чыгачагы, сайлаулар булачагы, акча алышыначагы... кебек яңалыклар. Әфка абый, техника җанлы, оста куллы егет буларак, җил әйләндергеч ток бирә торган җил тегермәне — динамо алдыра. Аны баганага куялар. Аннары аккумулятордан эшли торган зур радиоалгыч һәм каяндыр табып, эшкә яраксызланган хәрби кыр телефоннары кайтарта ул. «Кәнсәне» читәннән читәнгә сузылган чыбыклар белән бригада йортларына тоташтыргач, колхоз белән телефон аша гына идарә итү башлана. Тозга ташланган сарык көтүедәй, халык «упшы» йортындагы кадакка эленгән «колакчага» сарыла. Чөнки нәрәттән соң концерт (безнеңчәсе «консирт»)! Аны идарәнең бүләге дип тәкъдим итәләр: «Бушлай консирт тыңлагыз», — диләр. Әмма бу бәхетле көннәр озакка бармый. Мембраналар сүгенеп акырынуларга түзәрлек исәпләп эшләнмәгән, күрәсең, аппаратураларның нәрсәседер яна... «Токның көче җитмәүдән янды, зуррак движок кирәк», — дип аңлата Әфка абый.

...Телефон аша идарә итү барып чыкмаса да, бухгалтерия бүлмәсендә радио сөйләүдән туктамый. Кыска гына вакыт арасында авылдашларыбыз дөньяда Гөлсем Сөләйманова, Сара Садыйкова, Зөләйха Әхмәтова, Рокыя Ибраһимовалар барлыгын ишетеп белә.

...Баксаң-күрсәң, бу кешеләр колхозның баш бухгалтеры Әфка шкафындагы «Родина» дигән тартмада бикләнеп яшиләр икән! Шулай итеп авылыбызда чыбыксыз телефон — радио тыңлау чире тарала. Урын тапсаң кереп утыр да — тыңла! Хөррият! Абзар-кура тирәсендә эшләрен бетергәннән соң үзен-үзе йөртә алганнар «кәнсәгә» ашыга, җайлырак урынга утырып, «тыңлагыз, Казан сөйли»не көтә.

...Радио тыңларга «кәнсәгә» килү кайберәүләрнең гадәтенә керә, шөгыленә әверелә, колхозга бушка эшләүләре турында онытып торырга булыша.

Кичтән ишеткән чыгыш, спектакль яисә берәр музыкаль номер икенче көннең кичենә кадәр тикшерү объекты була, сүз сагызына әверелә.

Бер яктан радио алдаса, икенче яктан, ышанган булып, тыңлаучы үзен-үзе алдый. Авыл кешесе ул чак радиодан ишеткән бер генә нәрсәне бәхәссез кабул иткәндер — ул да булса профессиональ башкарылыштагы милли музыканы. Моң — татар милләтеннән булган олыны, кечене үзенә чакырып, буйсындырып, әдәпкә, итагатьле булырга өнди, күндәмлеккә, сабырлыкка чакыра... Хәзер исә, «денем өчен түгел, көнем өчен» дип яшәүче елгырлар аны «ясарга» өйрәнделәр. Көй «чыгару», моң «ясау» кәсепкә

әверелде. Бүгенге моңга имитация ясарга өйрәнгән кәсепче музыкантларның үзләренә дә, алар чыгарган «товарная продукция»гә дә сүз белән тию куркыныч. Алар тыңлаучыларыннан күбрәк тә, максатчанрак та, оешканрак та халык. Кәсепчеләрне әйтүем: алар хәзер хакимият тирәсенә үрмәләргә дә юлын таптылар. Мисалларын әллә каян эзлисе юк — алар белән эфир тулган. Аларга сүз әйтергә куркыныч…

Товарга әверелгән музыкалары турындагы кире фикереңне белсәләр — нишләтсәләр дә көчләрендә. Чөнки… алданган халыкның акчасы алар кулында.

Ә безнең сүзебез акчасыз иҗат иткән чын музыкаль талантлар турында…

…Шулай: безнең авыл халкы радио тыңларга колхоз идарәсе урнашкан йортка йөрде. Безне исә: «Яшегез җиткәч килерсез», — дип куалар иде.

…Беркөнне яшьтәшем Хәтиф: «Әнкәй кәнсәдә җыештыручы булып эшли, утын кисешсәгез, үзем урнаштырырмын», — дип әйтте ди.

Кисештек тә, ташыдык та, кертеп өйдек тә утынны. Шулай безнең Казан радиосын тыңлар өчен махсус урыныбыз булды: мич артына кибәргә өелгән утын пүләннәре.

…Беренче көнебездә концерт булмады… Ниндидер бер ир кеше «Гасырлар һәм минутлар»ны сөйләде. Китаптан укыган таныш шигырь булса да, аңлагач, кызык нәрсә икәненә ышандык. Икенче көнне иртәрәк килеп кунакладык. Башта кемнедер, нигәдер мактадылар. Аннары «консирт», диделәр… Гөлсем Сөләйманова ике җыр җырлады. Аннан соң: «Рокыя Ибраһимова баянда уйный», — диделәр. Монысы махсус минем өчендер кебек тоелды: баян! Хәзер мине дә баянист, диләр бит. Биетерлек уйнамасам да, җырлаучыга кушыла алам. Шул хакта Хәтифкә мактанмакчы булган идем дә, сүземне дәвам итә алмыйча, бүленеп калдым. Чөнки… чөнки радиодан баянчы нәкъ теге чакта безнең баянда уйнаган озын көйне сыздыра иде! Көйнең һәр бормасы миңа ул чактагы мөлаем йөзле моңлы апаны хәтерләтеп яңгырый. Менә кем булган икән ул безгә фатир кергән артист! Рокыя Ибраһимова үзе!

…Ул чакта аңа «Рокыя», дип дәшүләре хәтергә төште. Әнкәй дә перчатка бүләк иткәндә, кат-кат: «Рокыя» — диде. Ләкин Ибраһимова дигәнен ишетмәдем кебек. Ишеткән булсам да, ул миңа бары тик баянчының фамилиясе генә булып тоелыр иде. Ә хәзер исә даһи баянчының җисеменә туры килгән лаек исеме булып яңгырады! Сүз агышын бүлеп әйткәндә, Рокыя апаны тыңлап, көен таныганнан соң, мин, башка баянчыларны да, уен стильләреннән таный башладым.

…Икенче көннең концерт программасына: «Хормейстер Зөләйха Әхмәтова җитәкчелегендәге хор башкаруында халык көйләре», — диелгән иде. Без бераз аптырашта калдык. Нинди «хормейстер» ул? Кем булыр ул? Нишли ул? Хорга нинди җитәкче кирәк икән?! Тезелеп бастың да җырладың бит инде! «Хор» дип бездә, берничә укытучының бергә басып, «Яшь егетләр, яшь кызлар» көен җырлауны әйтәләр. Бәйрәм саен гел шул җыр, бер үк укытучылар. Монда да шундыйрак берәр көйдер, дип ташлап чыгып китәргә уйласак та, китә алмадык, безне радио дулкыннары китергән ниндидер күзгә күренмәгән көчләр туктатты. Башта Александр Ключарёв эшкәртүендә «Кара урман», диделәр. Таныш булса да, хор башкаруындагы бу көй җыр гына түгел, ә ниндидер кодрәт белән яңгыраган тавышлар картинасы иде. Тыңлыйсың да, тере табигать кочагында йөзеп, сәяхәт кыласың кебек.

…Елга-күлләр белән очрашасың, тауларга күтәреләсең, җилләрдән сыйпатасың, чәчәкләр җыясың, кәккүктән гомер-елларыңны санатасың. Юк, бу — хор, хор гына түгелдер, бу могҗизадыр! Адәм балалары күтәрелә алган биеклек тә, бөеклек тә шушыдыр…

…Икенче җырны «Тәфтиләү», диделәр.

Бусы да җыр гына түгел, ә ниндидер тылсымлы көчләр агымы, сүз белән генә әйтеп булмый торган үтенечләр, васыятьләр ташкыны, хатирәләр букеты иде ул. Шуны ишетүем белән мин бәхетле идем ул кичтә. Тук идем… Кем әйтмешли, «күңелем мәтәлчек ата» иде.

Башка җырлары хәтеремдә калмаган. Аларының тәэсире кечерәк булудан түгел, ә баштагы көйләрнең әсир итү көченнән: алар миңа бүген дә — осталык, башкару үрнәге. Бүген дә хыял җитмәс, уй ирешмәс матурлык символы булып хәтердә һәм күңелдә яши алар.

Тәэсирләрем белән уртаклашмакчы булып, Хәтифкә карасам, ул да елыйелый, шешенеп беткән кыяфәттә иде.

Әнә нәрсә икән ул «хор» дигәннәре, әнә нишләтә ала икән көйне хормейстер дигәннәре…

Ихтимал, Хәтифкә бу көйләр сугыш бетәр алдыннан гына «үлде» хәбәре килгән әтисен хәтерләтәдер? Үскәч, аның оста гармунчы булуына да шушы концертта алган тәэсирләре сәбәпче түгелме икән әле? Ихтимал.

Үсмер чакта мич артындагы утын өеме өстендә тыңлаган концертлардагы «хор», «оркестр», «ансамбль», «композитор» дигән сүзләр Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарёв, Зөләйха Әхмәтова исемнәре белән бизәлеп, гомер буе юлдашлыкка чакырып күңелләрдә яңгыраса да, җырчы була алмаган бик күпләр, музыка белән рухланып гомер итүләренең сәбәбен күңелләренә моң иңдергән, моң оеткысы салган җырчыларда күрәләр. Милләтебез хәзинәсендә алар бихисап. Берсен атасаң — икенчесен рәнҗетермен кебек тоелудан, бу язмада аларның остазларына гына тукталасы килә… Алары күп түгелләр. Шулардан берсе һәм иң берәгәйлесе хормейстер Зөләйха Әхмәтова булуы бәхәссездер…

Аның эшкәртүендә хор башкарудагы җырларны күп тыңласам да, останың үзен күрү безгә насыйп булмады. Инде күреп белгәннәрнең күбесе дә бакыйлыкка күчкән. Исән булганнары исә, «Әйбәт кеше иде, урыны оҗмахта булсын»нан артык сүз әйтелмәү яшендәгеләр. Кызганычка, җитәкче, хормейстер, дирижёр буларак үзенчәлекле якларын, холкын-фигылен, гадәтләрен, Зөләйханы бердәнбер ясаган асыл сыйфатларын тасвирлаган язма материалларны да таба алмадым. Бәлки алар язылып ятадыр?!

Музыка сәнгате буенча галим исеме күтәреп йөрүчеләр бакчасына таш ыргытасы килә: кайда, нинди «форшлаг» куярга өйрәткәнче, иҗади шәхесләребезнең үсү, эшләү, яшәү, иҗат итү үзенчәлекләре турында язсалар иде алар…

Соңыннан… соң була…

Исемен атарга кушмаса да, өлкән яшьтәге бер җырчының әйткәнен язмасам, гөнаһ булыр: «Зөләйха ападан көнләшәм мин. Ул үзенә-үзе гаҗәеп һәйкәл куйган шәхес: Татарстанның дәүләт җыр һәм бию ансамбле ул. Инде бөтен дөньяга танылган, дәүләт премиясенә лаек коллективның беренче җитәкчесе, анасы булган Зөләйха атлы бу легендар ханым — татар җыр сәнгатенең офыкларын киңәйтеп, милли музыкабызга яңа тавышлар өстәүче дә. Бу ачышлары өчен ул аерым бер һәйкәлгә лаек. Ул ишетелә торган гына түгел, күренә торган җырлар башкарту остасы!» — Шулай дигән иде ул.

Бу фикергә кушылучыларның яшь сәнгатькярләр арасында да булуы — Зөләйха Әхмәтова иҗатына тагы бер ихлас мәдхия.

Димәк, аның мәктәбен узучылар үзләрен алыштыручыларга ансамбльнең иҗади традицияләрен, эстафета флагыдай тапшырып баралар, калдыра баралар. Шуңа күрә дә, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең узганы — шанлы, бүгенгесе — данлы, киләчәге… өметле, дибез.

…Шул хакта сабакташым Флүрә Хәмитова белән фикерләр уртаклашып

утырабыз. Ул — Академия театрында җырлы рольләрне уңышлы башкарган мәшһүр актриса. Аннары, кәефе килгәндә, төрле җырчыларга пародия ясарга ярата иде ул. Галия Гафиятуллина булып (әверелеп) җырлаганы хәтердә. Атаклы җырчының Зөләйха Әхмәтова җитәкләгән ансамбльдә эшләп лаеклы ялга чыгуын, аннары, Галия Гафиятуллина белән Флүрәнең якын туганнар икәнен белгәнгә, Зөләйха апага кагылышлы истәлекләр сөйләмәсме дигәннән чыгып кына:

— Пародияңне Галия апа үзе күргәч, үпкәләмәдеме? — дип сорадым.

— Мин аңа пародия күрсәтергә курка идем. Тиргәвеннән түгел, хата табуыннан. Бик таләпчән иде бит ул. Ни әйтсәң дә, Зөләйха Әхмәтова укучысы!

— Зөләйха турында берәр нәрсә сөйләгәнен хәтерләмисеңме?

— Зөләйха апа турында мин сиңа үзем сөйли алам!.. Сәхнә оеткысын ул салды бит миңа!

— Чынлапмы?

— Чөнки ул Татарстан радиосы каршында балалар өчен оештырылган хор түгәрәген җитәкләде. Ничәнчедә укыган чагым булгандыр — өченче класстамы, дүртенчедәме — Хәтимә апай мине шушы түгәрәккә китереп, Зөләйха Әхмәтовага «бирде». Җыр өйрәнергә димме, җырларгамы — икесе дә дөрес.

— Галия апаң китермәдемени сине?

— Ул вакытта Галия түгел иде әле ул — Хәтимә иде. Аңа Галия исемен, сәхнәдән җырлый башлагач, Зөләйха апай кушкан. Ансамбльгә чакырып китерүчесе дә ул булган. Аңарчы Хәтимә апай урам чатларына ипилеккәтозлыкка яшеренеп кенә җырлаган әтиебез Харис аңа: «Нәселне хур итәсең», — дип ачулана торган булган. Шулай, җыр серләрен ачарга миңа ачкыч бирүчем Әхмәтова Зөләйха булса, миннән вокал буенча имтихан алган беренче музыкант — Салих Сәйдәшев үзе! Кем белән сөйләшүеңне белеп сөйләш! Салих абый белән очрашуларым әле тагы да булды, алары хакында башка чакта. Ә Зөләйха апаның: «Һәр җырны җырлауның үз позасы була», — дигәнен эшли-эшли генә аңладым. «Җыр ишетелергә генә түгел, күренергә дә тиеш», — ди иде ул. Хаклы булган!

Никадәр ихлас булсалар да, Флүрә сөйләгәннәр аның балачак истәлекләре иде. Зөләйха Әхмәтова — филармония театрының директоры да, ансамбльнең беренче сәнгать җитәкчесе дә булган олы шәхес. Миңа шул чорның ансамбль иҗатына бәйле документлар күрү лязем иде.

Филармония театры музеена юл тоттым.

...Дөресен әйтим, театрында да, музеенда да үз тарихлары белән кызыксынуларына ышанычым шикле иде. Заманы, кешеләре башка — инде өченче буын алышына, таләпләр бүтән.

Ялгышканмын булып чыкты. Бүгенге филармония театры артистлары Зөләйхалар буынының төшенә дә кермәгән мәһабәт сарайда иҗат итә. Хезмәткәрләре берсеннән икенчесе итагатьле, үз эшенең осталары.

Музей җитәкчесе Алсу ханым, максатымны белүгә үк, фондларында сакланган экспонатлар тулы калын бер папканы чыгарып: «Монда шул чор ансамбленең яшәү атмосферасы, иҗат пульсы, тамашачы зәвыклары», — диде дә, уңыш теләп, ялгызымны калдырды.

Репетиция залында оркестр яңа музыка өйрәнә. Көйне башлыйлар да — туктыйлар. Күрәсең, оркестрантлар киңәшләшеп алалар... Бераз тынлыктан соң бу сәнгать сарае тагын музыка белән тула. Татар халык көйләренә фантазия өйрәнәләр, ахры. Ул миңа да күчә...

...Шул өзек-өзек ишетелгән музыка фонында мин мәкаләләр, әмерләр укыйм. Алар миндә өзек түгел, ә бөтен бер фикер тудыралар: Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оештырылган көннәреннән башлап, бүгенгечә иҗаты белән милләтне милләт буларак саклауда тиңсез олы хезмәт күрсәткән! Һәм хәзер дә күрсәтә!

Билгеле ки, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле күп гомерен гастрольләрдә

йөреп үткәрергә мәҗбүр була. Әмма ул башка регионнарда көтеп алынган сәнгать коллективы гына түгел, ә милләтебезнең тулы хокуклы илчесе дә булып чыгышлар ясый. Документлар шуны сөйли, шуны раслый:

«...Балетмейстер Фәйзи Гаскәров куйган бию номерлары «Ял иткәндә», «Гармонь, гармонь» композицияләрендә җыр номерларын җанландырып һәм тулыландырып кына калмыйлар, сәнгатьтә яңа жанр тууны күрсәтәләр...»

«...Ансамбль башкарган «Күпердә», «Чишмә янында», «Шома бас», «Ике дус», «Җизнәкәй» хореографик композицияләре, һич икеләнмичә, шул яңа жанрның шедеврларыннан саналырга хаклылар».

«...Аларда хис тә, акыл да, башкару осталыгы да, бергә кушылып, гүзәллек тудыралар, чын сәнгать әсәре ясыйлар...»

«...Бу миниатюрный музыкаль спектакльләрнең куючы режиссёры Әхмәтова Зөләйха үзен «хормейстер» дип кенә күрсәтә. Остазның тыйнаклыгы җаваплылыктан качудан түгел, ә аның һәр эшкә үтә җаваплы карап, җентекләп эшләвеннән туган бу хореографик шедеврлар...»

«Сәнгатьнең һәр төренә үз осталарын табып, алардан үзең күрергә теләгәнне эшләтә алу — аерым бер талант, сирәк очрый торган һәм бик тә кирәкле талант».

«...Хормейстер Әхмәтова Зөләйха Саттаровна җырчылар белән генә түгел, бөтен ансамбль коллективы белән дә оста дирижёрлык итүче җитәкче булуын һәр эшендә раслый».

Ахыргы цитата «Омская правда» газетасыннан, 1951 елның 12 октябрь санында милләттәшебез Зөфәр Камалов мәкаләсеннән.

Башка милләт вәкилләре ансамбль концертларына йөргәннәрме? Бу турыда ничек язганнар?

1952 елның 16 июнендә чыккан «Вечерний Ленинград» газетасындагы А.Савин мәкаләсендәге юлларга күз салыйк: *«...Большинство обработок, (хормейстер З.Ахметова) сохраняя свое своеобразие мелодической простоты и гармонической строгости татарских народных песен, раскрывает многообразие их музыкального содержания введением подголосков, полифонических приёмов».*

***

Зөләйха Габделсаттар кызы Әхмәтова Чиләбе шәһәрендә 1904 елның 13 мартында дөньяга килә. Гаиләдә 16 нчы бала буларак туганлыктан, аны «төпчек» дип йөртәләр.

Габделсаттар абзыйның эш аты була. Шуның белән ул, тимер юл вокзалыннан шәһәргә пассажирлар ташып, гаиләсен туендыра. Ашарга җитсә дә яшәргә җитмәгәч, ишле гаилә әгъзаларыннан өлкәнрәкләре этиләренә төрлечә акча эшләргә булышалар.

Шулай эш белән гомер итә, үсә, яши гаиләнең 18 әгъзасы. Өске катта яшәүче музыка укытучысының исә фатирында физгармония була.

...Еш кына музыка тыңларга һәм бергәләп җырларга дип, ике гаилә бергә җыйнала торган була.

Зөләйха өчен мондый шөгыльләр башлангыч музыка мәктәбе дәресләре ролен үтәгәндер. Музыка укытучысының бер кызы — Зөләйханың яшьтәше — аеруча җырга гашыйк, җырлаучан тавышлы кыз була һәм ул Зөләйханы да үзенә ияртә. Алар, әти-әниләренә әйтмичә генә, чиркәү хоры тыңларга йөри башлыйлар. Шунда Зөләйха көйне бер генә тавыш белән түгел, төрле-төрле тавышлар белән җырлап булуын күрә, ишетә.

...Кызыйның музыкага тартылуы мәсьәләгә ачыклык кертә: әйе — баланың музыкага сәләтле булуы шиксез. Димәк, ул җырчы булырга тиеш! Бу — гаилә карары!

...Алар, Чиләбене калдырып, Өфегә (Уфага) күченәләр, Зөләйха музыкаль техникумда укый башлый. Тик, озакламый, этисе Габделсаттар абзый үпкә чиреннән вафат була.

Апасында торып, көндезләрен балалар йортында тәрбияче булып эшләп, бик авыр укыса да, Зөләйха 1930 елда кичке техникумны тәмамлап, җырчы-педагог дипломы ала. Ул чор өчен гаять кыйммәтле диплом була бу.

Техникумнан соң, өметле кадрлар сафында саналганлыктан, аны Мәскәү дәүләт консерваториясенең балаларга музыкаль тәрбия бирү бүлегенә укырга җибәрәләр.

Ниһаять, ул 1934 елда диплом эшен якларга дип, Уфага кайта. Тик аңа диплом якларга мөмкинлек бирмиләр. «Соңыннан», — диләр. Мәдәният министрлыгы аны баштарак Башкорт сәнгать техникумына, аннары музыка училищесына директор итеп билгеләли. Югары квалификацияле кадрлар җитмәүне сылтау итеп, яшь белгечне Башнаркомпросның музыкаль курсларында педагог буларак та файдаланалар. Зөләйха Әхмәтова кайда чакырсалар да, карышмый, алган белемнәре белән уртаклаша; яратып, бирелеп эшләве аркасында, дипломын якларга соңыннан да вакыты җитми — «калган эшкә кар ява». Шулай «на износ» эшләп, 1937 ел җитә. Коточкыч репрессияләр чоры башлана. «Тик кенә торганда капланды томанга бар һава», дигәндәй, кинәт Зөләйханың якын дусты, җырчы, беренче татар операсын язган Газиз Әлмөхәммәтов, кулга алынып, юкка чыгарыла.

Техникум директорына Уфадан китеп торырга киңәш итәләр. Ул Урта Азиядә яшәүче туганнары янына китәргә карар кыла.

Ташкент якларына юл Казан аша булганлыктан, Зөләйха Казанда туктала. Шул ук «сәбәп белән» Уфадан Казанга килеп урнашкан дусты һәм иҗади тугандашы Александр Ключарёв белән очраша.

Ключарёв аны китмәскә, талантны харап итмәскә, Казанда калырга димли, радиокомитетка хор дирижёры вазифасында эшләп торырга тәкъдим ясый. Тәкъдим кабул ителеп, шуннан Зөләйха Әхмәтованың җимешле, уңышлы иҗади гомер чоры башлана.

Бу чор башында, репрессия хәбәрләре белән аралаш, республикаларда профессиональ музыка коллективлары оештырылачак, дигән хәбәрләр дә ишетелә башлый.

Һәм... чынлап та, 1937 елның 21 августында Татарстан халык комиссарлары Советының: «В целях широкой пропаганды и развития музыкальной культуры образовать Татарскую государственную филармонию», — дигән карары чыга.

Филармония каршында хор капелласы оештырылып, аны җитәкләүне Зөләйха Әхмәтовага тәкъдим итәләр. Капелланы! Тәкъдим кызыктырырлык булса да, милләт «колагының» хорга карашын белгәннәнме, милләтнең традицияләрен, гореф-гадәтләрен яхшы белүдәнме, хор сәнгатенең беренче профессионалы Зөләйха Әхмәтова үз шартын куя: «Әгәр дә капелла янына биючеләр труппасы да алырга рөхсәт булса — мин риза», — ди ул, соңыннан бу капелланың җыр һәм бию ансамбленә әверелү перспективасын күздә тотып. Аның алдан күрүчәнлектәге даһилыгы түгелме соң бу? Тыңлыйлар профессиональ белгечнең сүзен, идея кабул ителә. 1938 елда «Җыр һәм бию ансамблен оештыру» турындагы карар чыга (Хәтта шушы карар чыгуга өлеше өчен генә дә ансамбль Зөләйха Әхмәтова исемен йөртергә лаек). Шуннан башлап 20 ел дәвамында ул ансамбльне биеклеккә күтәрүдә бөтен көчен, белемен, талантын биреп эшли: өйрәтә, өйрәнә, укый, укыта, җырлый, җырлата. Әйе, көнчел дошманнарының хыянәтле һөҗүменә кадәр шулай була...

Зур хезмәтләре өчен Зөләйха Әхмәтова Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Әйе, бүләкләнә ул, мактала, яраталар аны, хөрмәт итәләр... Эшли, эшләтә белә чөнки... Талантларны таба, аларга юл ача белә. Кеше буларак ярдәмчел, остаз буларак ихлас күңелле чын педагог, гади, гадел.

Бу сыйфатлары аның иң мөһимнәредер, бәлки...

Әмма да ләкин пенсия яшенә җиткәнче үк аны яраткан эшеннән аеруга ирешәләр... Кемнәрме? Татар сәнгате орбитасында, чын талантларга иярчен булып, «кысыр чәчәкләр» әйләнә. Алар музыкантлар арасында да, язучылар, рәссамнар арасында да еш очрый. Берләшә беләләр, сүзләрен гамәлгә ашыру җәһәтеннән үтә максатчаннар. Алар, аеруча тоталитар система атмосферасында үрчеп, җәмгыятнең төрле тармакларында микробларын калдыра алдылар, үрчеделәр...

Зөләйха Әхмәтованы да шул микроблардан яралып үскән «сәнгать белгече» «ашый». Иренә урын кирәк булганга шулай эшләвен белсәләр дә, музыкаль белеме дә булмаган надан бу «белгечкә» авыз ачып сүз әйтүче табылмый. Соңыннан Зөләйханы яклап һәм мактап сөйләүчеләр күп була, әлбәттә. Ләкин инде поезды киткән, кояшы баеган. Шулай орденлы хормейстер Зөләйха Әхмәтова хорсыз-эшсез кала. Нәкъ татарча «бүләкләнә»! Остаз өчен иң зур бүләк — осталыкта аны уздырган шәкертләре, диләр. Бәлки, шулайдыр... Ләкин кеше язмышын хәл иткәндә шәкертләрне тыңламыйлар шул...

Башка иҗади коллективлардан аермалы буларак, ансамбльдә сәнгать җитәкчесе булып кем генә эшләсә дә, шөкер, үзләренә кадәр эшләгән остазның буразнасын боза алмыйлар. Ә кайберләре исә, остадан мирас булып калган хәзинәләрне, мәсәлән, хореографик миниатюраларны камилләштереп, аларны оригиналь сәнгать үрнәге — эталон дәрәҗәсенә күтәрәләр. Ансамбльне Лима Кустабаева, Айрат Хәмитовлар җитәкләп, хормейстеры Венера Гәрәева, балетмейстеры Раилә Гарипова булган композицияләрдә — шулай.

Дөньякүләм абруй казанган ансамбльнең шәҗәрә башында Зөләйха Әхмәтова торса, аны милли моңнар белән сугарган чишмәләр — композиторларыбыз һәм башкаручы музыкантларыбыз аша тоташкан әбиләребез, әниләребез булуы — бу уникаль коллективны милләтнең үз баласы итә.

Әйе, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле — асылында да чын халыкныкы ул: милләтебезнең йөзек кашы!

Ни кызганыч, урамнарыбыз «Латыш стрелоклары», «Юдин», «Азин», «Бауман» дигән шикле типларның исемнәре белән аталып, шәһәребезне чүпләсә дә, шулардан арынырга дигән карарның, ни сәбәпледер, һаман чыкмавы — замандашларыбызны шомландыра торган чынбарлык.

Чынлап та, ни көтәләр бу урамнарга исем кушучы чиновниклар? Узганнарның кире кайтуынмы? Ихтимал. Милләтебезнең җәүһәрләреннән булган шәхесләргә «урам юк», имеш! Чын булса, Казанда бер үк исемдә генә 258 урам бар, диләр. Шуларның берәрсенә ярамаса, яңа төзелгән урам беренче милли хормейстер Зөләйха Әхмәтова исеме белән аталса, бу үз сәнгатебезне саклауга таба кыю бер адым булыр иде ләбаса. Һәр юл — беренче адымнан башлана бит. Ул адымны атлату кем ихтыярында һәм кем атларга тиеш? Нигә бу җаваплы чиновникның газеталарда чыгып килүче тәкъдимнәргә җавабы юк? Язалар бит, сорыйлар, дәлиллиләр. Юк җавап...

Атаклы сәнгатькяребезнең тууына 100 ел тулганда, аның иҗатына багышлап, ихлас күңелле музыка белгече Филүсә Арсланова тарафыннан китап чыгарылган иде. Халык талантына чын хөрмәт иде бу. Ыргыткан ташымның берсен кире алырга мәҗбүрмен...

Гафу үтенеп, рәхмәт әйтәм китап авторына.

Мәрхүм булган талант ияләре исән милләттәшләреннән дога гына көтәләр. Дога — хәтерләү ул, китап, җыр исә — һәйкәл.

Казан урамнарының берсе Зөләйха Әхмәтова исемен йөртсә, бу шәхес турындагы хатирәләр, «Зөләйха» көе кебек, милләт күңелендә җуелмыйча сакланыр иде. ■

РӘФКАТЬ БИКЧӘНТӘЕВНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

БИКЧӘНТӘЕВЛӘР ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

Рәфкать Бикчәнтәев – гастрольдә

Шәүкәт БИКТИМЕРОВ

Медицина институты студенты Шәриф Хөсәенов комедия язган икән дә, анда яшь эшче Абдулны Рәфкать уйный икән. Казанның кайсы төшенә генә барып чыкмыйсың, һәркайда: «Рәфкать Бикчәнтәевне карадыгызмы әле, менә ичмасам уйнап та карый!» — дип сөйлиләр. Карыйм әле үзен, мәйтәм, ничек икән? Без танышлар да бит… Карый башлауга ук таң калдырды бу мине. Бикчәнтәй үзен ничектер ычкындырып җибәргән. Йөзә генә. Тормыштагы кебек ышандыра да, башкалардан үзгә булып аерылып та тора. Карале, болай итеп тә уйнап була икән, дим. Әйтүемчә, Казанда Бикчәнтәевтән дә популяр кеше юк иде.

«Беренче мәхәббәт»тә – Әпсәләм ролендә. Рәхилә – Наилә Гәрәева, Нурсәнә – Асия Хәйруллина

«Мәкер һәм мәхәббәт»тә – Гофмаршал ролендә

Луара ШАКИРҖАН

«Беренче мәхәббәт». 1960 ел. Г.Камал исемендәге театрда 35 яшьлек артист сәхнәләштергән бу спектакльнең уңышы шул дәрәҗәгә җитә ки — берничә айдан яшь автор Х.Вахит һәм әсәрне куючы Р.Бикчәнтәев Г.Тукай бүләгенә лаек дип табыла.

«Беренче мәхәббәт»не караган меңләгән тамашачыны күз алдына китерсәк, шушы уен нәтиҗәсендә күпме яшь егет-кыз театрга һәм сәхнәгә гашыйк булгандыр, кешеләр дә, язмышлар да матураеп киткәндер… Тик андый статистика юк. Ә менә хәтер яши. Студентка Наиләне халыкның яраткан артисткасы иткән, яшь Шәүкәт Биктимеровны Тәлгать итеп таныткан, татар театрын яңартып, үстереп җибәргән бу спектакль һәм аның режиссёры (әлбәттә, автор да) тарихта һәм тамашачы күңелендә мәңге калыр.

Фәрит БИКЧӘНТӘЕВ

Режиссурага мин бик күп нәрсә аша килгәнмендер кебек. Димәк, эти турындагы уйны да инкаяр итеп булмый. Шуның белән бергә: «Ах, менә минем әтием режиссёр иде, тукта, мин дә режиссёр булыйм әле, диеп уйладым мин», — дип, кеше көлдерүдән дә сакланам. Ул менә хәзер генә, соңгы бишүн елда гына уйландыра. Әти еш искә төшә. Үзем дә әти кеше. Кайчак әтинең режиссурадагы тәҗрибәләре, аның ирешкәннәре белән бәйләп тә уйлап куям. Режиссурага бик күп нәрсәләр аша килүемне икърар иткәндә, бәлкем, әти йогынтысы да булгандыр, тик ул эчтә, бик тирәндә утыргандыр, дип тә фаразлап куясың.

Атага иң кадерле кеше – улы

Мәсгут ИМАШЕВ

Рәфкать Бикчәнтәев образларның характерын тәгаенләгәндә дә, тормыш күренешләренә бәя биргәндә дә, акны ак дип, караны кара дип туры әйтүче, үз фикерендә нык торучы шәхес иде.

«Хуҗа Насретдин»дә – Чәчтараш ролендә

«Һиҗрәт»тән Абдулич ролендә

Шамил ЗАКИРОВ

Шундый җырлар була. Гомерең буена да оныта алмыйсың аны. Рәфкать абый әнә шундый бөек җыр иде, поэзия. Аның иҗаты да тоташтан поэзия. Театрдан башка яши алмый иде ул. Ә үзе театрдан бер китеп, бер кайтып торды. Аның сәбәпләре булгандыр. Һәм гади сәбәпләр генә дә түгелдер. Болай дип эчке сизенү буенча гына әйтүем, күп вакытлар узгач кына төшенеп була торган сәбәпләрдер алар. Нигәдер минем уема Рәфкать абый белән бергә Дамир Сираҗиев та килеп керә. Охшашлык табам шул ике зур талант арасында. Табигый саф көенчә табылган алтын кисәкләрен хәтерләтүче халыкның үз арасыннан килеп чыккан чын талантлар итеп күрәм. Тумыштан ук зур талант белән туган шәхесләр.

Зөлфәт МАЛИКОВ

Бикчәнтәевләрнең геннары дәвам итүе дә искиткеч!.. Менә Рәфкать аганың Фәрите нинди! Очраклы хәлмени ул?! Аның каны күчкән бит. Аллага шөкер, әле ярый күчеп калган! Ул бит гөрләтеп эшләп ята! Курыкмыйча нинди әсәрләргә алына, нинди темаларны күтәрә! Әтисенә хас нинди кыюлык бар аңарда! Лирик хис атасында күбрәк иде кебек. Бөтен җанытәне белән шагыйрь иде бит Рәфкать ага. Күңеле тулы шигъри тойгылар. Фикерләрендә шигъри тирәнлек, бетмәс-төкәнмәс шигъри хис...

«Алмазбулат»
Наилә Гәрәева – Ана, Фәрит Бикчәнтәев – Алмазбулат ролендә. 1981ел

Р.Бикчәнтәев хакында күренекле замандашларының фикерләре Юныс Сафиуллин төзегән «Рәфкать Бикчәнтәев» исемле истәлекләр китабыннан алынды. Фоторәсемнәрне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тәкъдим итте.

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

АДЛЕР ТИМЕРГАЛИН
(1931 – 2013)

Кулъязма хәлендә 210 басма табактан да күләмлерәк булган бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде. Ул бик тиз таралып бетте һәм хәзерге вакытта сирәк очрый торган басмалар исәбендә йөри.

Бу сүзлек үзенең колачы белән гамәлдәге күпчелек сүзлек һәм белешмәләрдән аерыла. Асылда, анда төрле характердагы, төрле юнәлештәге (тарихи, фәлсәфи, дини һ.б.) төшенчәләр бергә тупланган, һәм мин мондый синтезда гайре табигый нәрсә күрмим, киресенчә, кристаллаша торгач, ул яңа сыйфатларга ия булган эретмә, ягъни бербөтен тәшкил итте, татарның милли галәмен киңрәк һәм панорамалы итеп ача торган китап туды, дип уйлыйм.

Сүзлек практик максатларны күздә тота, хәзерге заман татар укучысын язма чыганакларга, таихыбызга һәм иманыбызга якынайтуны, артык вакыт сарыф итмичә генә татар телендә дөнья күргән күпчелек тарихи, фәлсәфи, фәнни һәм дини әдәбиятны зиһенгә алу эшен җиңеләйтүне максат итеп куя.

Автор

АБАГА — Русча эквиваленты *кочедыжник* (папоротник түгел). Искечә — *абага көпшәсе,* диалектта *бүре тарагы* да, диләр. «Абага» атамасы чуваш телендәге «упа (упаха, опака) кепчи — «аю көпшәсе» дигән сүздән» (Р.Әхмәтҗанов). Шушы ук автор бу сүз «апа, абый, бабай» нигезеннән дип уйлый. «Күп кенә халыклар үзләренең чыгышларын аюдан дип исәпләгәннәр, аюны «бабай» дип йөрткәннәр». *Абага үләне* — аю үләне атамасы да шуннан килеп чыккан.

Татарстанда *каяу яфраклы абага* һәм ана абага дигән төрләре үсә.

«Абаганың чәчәк атуы турындагы әкият бик борынгы заманнардан килә. Ул заманда әле славян халыклары яшен алласы Перунга табына торган булганнар. Перунга беркем дә күрмәгән

«ялкын төсле кызыл» абага чәчәге багышланган. «Ә бу үлән хәзинәләрнең дә иң көчлесе — чәчәкләр патшасы, абага үлән!» — диелгән борынгы кулъязма «Үләннәр китабы»нда. Борынгылар, ялт итеп киткән яшен утыдай күреп өлгереп булмый торган «абага чәчәге» кешене күзгә күренми торган итә дип ышанганнар. Елга бер мәртәбә, Иван Купалага каршы төнне абага берничә генә минутка утлы чәчәк ата һәм мондый чәчәкне кулына алган кеше бөтен яшерен эшләрне белә, җир астындагы хәзинәләрне күрә башлый, имеш. Бу төн христиан динендәге Иоанн Предтечаның туган көнендә (24 июнь/7 июльдә) була.

Татардагы «Абага чәчәге ут булыр, атып җиткәнче юк булыр» дигән мәкальгә караганда, мондый хорафатка безнең бабаларыбыз да ышанган.

Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» дигән фантастик хикәясе (фэнтэзи) абага чәчәген капкан кешенең, имештер, күзгә күренмәс булуы турындагы әкияткә корылган.

//*Абагалар шау чәчәктә, имеш! Ел да төнен барып карыйм, димен, — һаман вакыт тими.* Равил Фәйзуллин.

АБЕЛХӘЯТ, АБХӘЯТ фг. — Терек суы, тереклек суы (мәңге суы). Күчерелмә мәгънәдә—аракы. Сәйф Сараида «абелхәят» мәгънәсендә абе хәйван сүзе очрый. Кайбер ривайәтләрдә *чишмәи абелхәят («чешмәи аби хәйан»)* — терек суы чишмәсе. Риваятьтә бу чишмәдән су эчкән кеше мәңге вафат итми тора һәм *Хозыр Ильяс* та шуның суын эчкән, дип сөйләнелә (*Хозыр суы* дигән төшенчә дә бар). Аннары Аллаһы Тәгалә чишмәи абелхәятне кеше күзеннән яшергән. Риваятьләргә караганда, бу чишмә нindидер бер караңгы җирдә икән. Искәндәр Зөлкарнәин, абелхәят чишмәсен эзләп, Көнбатышка сәяхәт кылганда, үзенә Хозырны да ияртеп барган, имеш. Аннары Хозыр, Сөләйман Бакырганиның шигырьләренә сокланып, аның авызына төкергән дә, шуннан соң Бакыргани үлемсез шигырьләр иҗат итә башлаган, дип сөйлиләр.

//*Кем, караңгылык эчендә табылыр абехәят. Сәйф Сараи. Гыйльме җәһд ит, ул дорыр абе хәят*—Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул. Г.Утыз Имәни. *Шөйлә кәзмешем, гүя эчмешем абе хәят, Һәркем үлемне татучыдыр икәндер, белмәдем.* Һибәтулла Салихов. (Монда *кәзмешем* — гамьсез йөргәнмен мәгънәсендә.)

«Суфичылык серләре» китабында бу сүзнең аб-ы бәка, аб-ы җавидан, аб-ы хайван, аб-ы Хызыр, аб-ы рәуан, аб-ы зиндәги, аб-ы Искәндәр һ.б. синонимнары китерелгән.

XIII гасырда Европада икмәктән куылган аракы күренә башлагач, аны aqua vita, ягъни «терек суы» дип атаганнар һәм ул башта аптекаларда дару сыйфатында сатылган. Көньяк Русьта бу суны баштарак «оковита» дип атаганнар, әле «водка» атамасы (*су* сүзеннән) соңрак килеп чыккан. Украинада аны, ут ярдәмендә хәзерләнүеннән чыгып, «горилка» дип йөрткәннәр. Тукай бу сүзнең мондый мәгънәсен түбәндәге шигырь юлларында чагылдыра; «Йә сихерле шишәдән абелхәят эчмәктәме? Мәст улып, аляме дөньядан тәмам кичмәктәме?»
Абелхәятнең капма-каршысы — *үле суы.* *Әбелхәят* язылышы да очрый.
Тагын кара: ***Хозыр Ильяс. Зөлкарнәин.***

АБЗАР ИЯСЕ тар. — Казан татарлары ышануынча, абзарда (диалектларда — азбарда, арбазда) яки ишегалдында яши торган рух. Башкача исеме — *мал иясе.* Чүпрәле татарларында — *аран иясе.* К.Насыйри язуынча, «йорт хайваннарының, атларның, бигрәк тә сыерларның хыялый хуҗалары». Кайчагында төннәрен кешеләргә еракта адәм сурәтендә күренәләр имеш. Ул яраткан хайваннар һәрвакыт көр,

шома, матур булып, ул яратмаганнары тирләүчән, бик тиз ябыгучан булалар икән. Абзар иясе яраткан атларының ялларын үрә, аларга ашарга сала, дип тә ышанганнар.

Узган гасырда яшәгән Яков Емельянов исемле керәшен шагыйренең бер шигырендә «абзар ияләре» мәгънәсендә *кләүләр* сүзе кулланылган.

Көнбатыш Себер татарларында абзар иясен *мал иясе, Зәнги баба* һәм *Пәша ана* дип атыйлар. Чувашларда *вол иясе* — мал иясе. Инглиз телендә *«наян Ральф»* дигән атама бар, аны «типография хуҗасы» дип тә йөртәләр. Наян Ральф типографиядә наянлыклар эшләп ташлый, җыелган хәрефләрне тарата, имеш.

Ихтимал, *мал (вол) иясе* дигән атама борынгы рус мифологиясендәге *Волос — Велес* дигән терлек алласына *(«скотий бог»)* барып тоташа торгандыр: *Волос — вол (мал) иясе?* Рус телендә «Волос» һәм «Велес» дип ике төрле язу, ягъни сүзне кулланудагы тотрыксызлык та әлеге фараз файдасына сөйли. Билгеле булганча, борынгы Киевтә кенәз пулаты каршындагы мәйданда төрле аллаларның сыннары куелган була. Төп алла Перун янында төркиләр табына торган Симарогл һәм фин халыкларының алласы Мокошь торган (Н.Е.Артемов, В.И.Лебедев. — История СССР, Учпедгиз, 1959). Волосның сыны исә, хәзерге вакытта рус авторлары бу алланы ничек кенә күтәрмәсеннәр, Подолдагы базар мәйданына гына куелган була, ягъни ул дәрәҗәле аллалардан исәпләнмәгән. Волос — Велесны бәҗәнәкләрнең «Мал иясе» дип фараз итәргә мөмкин. Биредә бәҗәнәкләр, ихтимал, ат сата торган булганнардыр? Бу очракта тагын шуны искә төшерү урынлы булыр: Себергә килеп төпләнгән руслар аюны «хозяин тайги» дип атаганда җирле төрки халыкларның таулар һәм тайга (*тайга* да асылда — тау урманы) хуҗасы мәгънәсендәге *таг иясе* атамасын турыдан-туры тәрҗемә итеп кенә алганнар.

АБРАКАДАБРА — Латин теленнән дип карала, мәгънәсе: **1.**Тылсымлы сүз, урта гасырларда аңа сихер көченә ия, дип караганнар. **2.**Аңлаешсыз сүз боткасы, мәгънәсез сүз.

Гыйбрани телдәге «Abreg as habra» — «Яшенеңне үлемгә дә ат» җөмләсеннән килә, дип уйлыйлар. Борынгы Рим амулетларында һәм геммаларында сугыш киеме кигән яугир — *Абраксас* алла рәвешендә сурәтләнә. Аның башы — әтәчнеке, аяклары урынына ике елан гәүдәсе, бер кулында — түгәрәк калкан, икенчесендә — камчы. Ул Алла белән Иблиснең сыйфатларын үзендә берләштергән, имеш.

Башка версия дә бар. Библия текстын өйрәнеп тикшерүче инглиз галиме Джон Аллегро фикеренчә, бу сүз борынгы месопотам гыйбарәсе АБ-БА-ТАБ-БА-РИ дан килә. Борынгы шумерлар бу гыйбарәне дини мәрәсимнәр үтәгәндә әйтә торган булганнар.

Борынгы еврейларның бизгәктән котылу өчен муеннарына асып йөртелә торган әфсене түбәндәгечә яңгыраган:

Аб Абр Абра Абрак Абрака
Абрака Абракала Абракал
Абрака Абрак Абра Абр Аб.

АБЫЗАГАЙЛАР ХӘРӘКӘТЕ — XVIII гасыр ахырларында — XIX гасыр башларында татар руханилары арасында иҗтимагый-сәяси һәм дини хәрәкәт. Әдәбиятта *абызлар хәрәкәте* («Движение абызов») термины да йөри. Мәсгуд Гайнетдин абызагайлар турында: «Абызагайлар — Диния Нәзарәтенә буйсынудан, Указ алудан, имтиханга барудан баш тартучы демократик авыл руханилары, үз заманының укымышлылары (абызлары)», — дип яза.

Бу хәрәкәт татарлар арасында ди-

ни-реформаторлык һәм рационалистик идеяләр таралуына булышлык иткән. Абызлар хәрәкәтендә, мәсәлән, татар дин эшлеклесе, суфи шагыйрь Әбелмәних Каргалыйның катнашканлыгы билгеле.

1667-1671 елларда Степан Разин кузгалышында, 1711 елда Батырша кузгалышында катнашкан мөселманнарга Морад мулла һәм Хисаметдин Мөслими идеяләренә шушы абыз-агайлар хәрәкәтенең йогынтысы зур булган.

Борынгы Болгар шәһәрен «изге ватан» итеп санау һәм торгызу идеясе абызлар хәрәкәте белән аерылгысыз бәйләнгән.

XIX гасыр башларына абызлар хәрәкәте әкренләп сүнә барып, аргы төбәкләрдә (Урал буенда, мишәрләр яшәгән җирләрдә) генә кала, ә XIX гасыр урталарына, Оренбург мөселман рухани җыелышы эшчәнлеге тамыр җәйгәннән соң, әлеге хәрәкәт юкка чыга, дияргә мөмкин.

АВЫЗ АЧУ — Кичен рузә вакыты чыкканнан соң ашау-эчү, *ифтар кылу.* Бу вакытта, кояш баегач, кипкән җимеш яки ипи сыныгы ашап куярга, су эчәргә һәм шуннан соң гына, кичке намаздан соң, туйганчы ашарга кирәк.

Авыз ачканда укыла торган дога: «Аллаһүммә ләкә сумтү вә бикә әмәнтү вә галәйкә тәүәккәлтү вә галә ризкыйкә әфтартү вәли-сауми гадим мин шәһри Рамазан нәүәйтү фигъфирли йа гаффар ма каддәмтү вә ма әххәртү бирәхмәтикә йа әрхәмәр-рахимин».

Мәгънәсе: «Йә Аллам! Мин Синең ризалыгың өчен ураза тоттым, һәм мин Сиңа ышанам, һәм мин Сиңа өмет итәм, мин Синең ризыгың белән авыз ачтым, һәм мин Рамазан аеның иртәнге көнендә дә ураза тотарга ниятлим. Йә Кичерүче! Синең мәрхәмәтең белән элек кылганнарымны һәм соңрак кылганнарымны кичер. Ий иң рәхимле, иң мәрхәмәтле зат!»

«Авыз ачу» сүзенең тарихы кызыклы булса кирәк. Охшаш сүз (төшенчә) йәһүд динендәге караимнар телендә дә бар («авуз ачар» — кайгы көннәренең тәмамлануы — җырларга һәм кычкырып сөйләшергә рөхсәт ителү). Татар телендә (шулай ук караимнарда) «авыз йабу» төшенчәсе дә булган (ураза башы). Мондый сүзләрнең башлангычын хәзәрләрдә йәһүдилек рәсми дин булып исәпләнгән заманнардан ук эзләргә кирәк, чөнки борынгы бабаларыбыз шактый вакыт хәзәр дәүләте кул астында яшәгәннәр. XI гасырда яшәгән бөек галим Бируни дә болгар телендә хәзәр элементлары булуга игътибар иткән.

АГАЧАТ — Башкортта: кире беткән, үҗәт ат. Димәк, төркиләрдә «агач атка атландыру» фразеологизмының туры мәгънәсе дә булган икән. *//Агачатка менмә, сабыйга тимә, күккә сөянмә—мәкаль. ...Кайвакыт мәҗнүн кеби көлмәс вә шатланмас идем, — Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң.* Тукай.

Гомумән, «агач атка атлану», «агач атка атландыру» (берәр кешене хәйлә белән алдалау, төп башына утырту) гыйбарәсен борынгы җырчы Һомерның «Илиада»сына (агачтан ясалган «Троя аты»на) гына бәйләп аңлату белән килешеп булмый, чөнки, мәсәлән, телебездә шул ук мәгънәдәге «таякка атландыру» гыйбарәсе дә яши, ихтимал, анысы беренчелдер әле. Өстәвенә данайлылар троялыларга бүләк иткән атка (рус телендә «троянский конь») берәү дә атланмый һәм атлана да алмый, чөнки бу эче куыш ат корсагында данайлы сугышчылар посып ятарлык зур булган.

Татар телендәге «җилгә атлану» сүзе дә әлеге мәгънәви рәткә карый. ■

Дәвамы бар

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның март ае

Тукай җәмгыятенә рәд җавабы

Казанда Тукай исеменә җәмгыять[1] ачарга рөхсәт соралган. Мөрәҗәгатькә вилаять мәҗлесеннән бер мәртәбә рәд [кире кагу] җавабы алынганлыгы язылган иде. Шуннан соң җәмгыятьнең мөәссисләре [оештыручылары] уставның җитешмәгән җирләрен төзәтеп, яңадан мөрәҗәгать иткән иделәр. Әле бу көннәрдә тагын берничә җитешмәгәнлек күрсәтелеп, рәд җавабы кайткан. Инде мөәссисләр шушы җитешмәгәнлекләрне тәкмил итеп [тутырып], шушы көннәрдә яңадан рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәчәкләрдер.

1914. — № 352. — 4 март.

Кызык заявление

Суконная урамнарыннан беренең халкы җыелып үз урамнарын «Диңгез урамы» диеп аталуын сорап управага гариза биргәннәр. Алар үзләренең гаризаларында, урамны болай аталуга сәбәп итеп, үз урамнарында бер кое барлыгын, бу коеның суы диңгез суы кеби яхшы (?!)[2] икәнен бәян иткәннәр.

1914. — № 353. — 5 март.

Шәһәр хайваннарын көтүгә чыгару

Соңгы елларда шәһәр кешеләре хайваннарын көтү эшләре шәһәр идарәсе тарафыннан эшләнә иде. Казан мөселман халкы шәһәр управасына гариза биреп, хайваннар көтүенең шәһәр кулыннан чыгарылып, искедәгечә подряд ысулы белән көтүчегә бирелүен сораганнар һәм дә көтүдәге үгезләрнең саны арттырылсын иде, дип үтенгәннәр. Шәһәрнең урманнар һәм болыннар комиссиясе бу гариза хакында мөзакәрә иткәннән [фикер алышканнан] соң, шушындый бер карарга килгәннәр: 1) көтү көтүнең шәһәр кулыннан чыгарылуына гаид кыйсемен [караган өлешен] игътибарсыз калдырырга; 2) үгезләрне арттырырга; үгезләрне һәр егерме биш сыерга бер туры килерлек итеп арттырырга (элек 100 сыерга бер үгез иде); 3) бу үгезләрне голландский нәселдән алырга.

1914. — № 357 — 10 март.

Тукай урамы

Шәһәрнең урам исемнәрен үзгәртү мәсьәләсе Думаның үткән мәҗлесендә мөзакәрәгә куела алмый клган иде. Исемнәр тәгаен итү комиссиясе Мәрҗани[3]

---

[1] Казанда Тукай җәмгыятен оештыру теләге гамәлгә ашмый кала.
[2] Чыганакта шулай бирелгән.
[3] Революциягә кадәр «Левая набережная Кабана», Совет чорында «Комсомольская» буларак танылган урамга 1998 елда Ш.Мәрҗани исеме бирелә.

һәм Насыйриларга[4] берәр урам аерса да, Тукай исеменә урам тәгаен итмәгән. Шунлыктан, Дума мәҗлесендә ул мәсьәләнең бөтенләй телгә алынмый калуы бик мөмкиндер.

Менә шуны хәтергә алып, Тукайны ихтирам итүче бәгъзе затлар шәһәр управасына бер гариза биреп, бер урамның Тукай исеме белән аталуын таләп итәргә хәзерләнәләр икән.

Тукайның вафат елы тулу мөнәсәбәте белән бу эшнең бик вакытлы вә бик урынлы икәнлеген сөйләп торырга ихтыяҗ юктыр. Тукай хәзергә кадәр татар дөньясында булып үткән шагыйрьләрнең халык тарафыннан иң тәкъдир ителгәне вә соңгы шагыйрьләр арасыннан иң күп укылганыдыр. Урта Русия мөселманнары арасында бер гаилә табылмас ки, анда Тукайның исемен белмәсеннәр, урта Русия мөселманнары арасында мәктәптә укучы бер бала табылмас ки, ул Тукай шигырьләреннән берничәсен хифза [яттан] белмәсен. Халык тарафыннан шулкадәр укылган вә шулкадәр тәкъдир ителгән бер шагыйрь исеменә бер урам тәгаен итүдән, әгәр мөселманнар таләп кылсалар, шәһәр Думасы да имтинаг итмәс [тыймас].

Менә шунлыктан без, югарыда мәзкүр [әйтеп үтелгән] затларның шәһәр управасына гариза бирмәкче булуларын тәбрик итәбез вә бу тәшәббеснең [инициативаның] муаффәкыятьле [уңышлы] булачагын өмид итәбез. Тукай исеменә булганда, язу таный торган халык арасыннан кирәгеннән артык имза табарга мөмкин булачактыр. Фәкать, бу эшне тизрәк тотып, вакытлы эшләп өлгертергә кирәк[5].

1914. — № 363. — 17 март.

Мөселман приказчиклары тормышыннан

Казанның төрле урамнарында мөселманнар кулында утыздан артык фрукты магазиннары бар. Болар атнаның һәр көнендә ачык булалар, боларда хезмәт итүче приказчиклар ни мөселман вә ни рус бәйрәмнәренең һичберсендә бушамыйлар.

Мәзкүр магазиннарда хезмәт итүчеләрдән бәгъзеләренең идарәбезгә хәбәр бирүләренә күрә, болар өйләреннән иртән сәгать җидедә чыгып, кич сәгать 11дә генә кайталар, гаиләле вә балалылары да атнасына бер генә көнне дә гаиләсе янында уздыра алмый, вакыты-вакыты белән берәр атна тоташтан балаларын күрә алмый йөриләр икән. Аталары чыгып киткәндә йокыда калган балалар, аталары кайтканда йоклап өлгергән булалар вә шулай итеп, аталарын күрмиләр, хәтта ятсынып үсәләр икән.

Менә шул эшләрне хәтергә алып, фрукты магазиннарында хезмәт итүчеләр, без дә башка кешеләр шикелле үк ял итәргә, гаиләбезне күрергә, балаларыбызны сөяргә мохтаҗларбыз, безгә фәкать җомга көн җомгага кадәр булган вакытны ял итәргә ирек бирү кирәкле иде, диләр.

Хезмәт халкының бу хаклы таләбенә игътибар итмәскә мөмкин түгел. Фрукты магазиннары тотучы сәүдәгәрләр үзләрендә хезмәт итүчеләрнең һәр ноктадан караганда бик хаклы булган бу таләпләрен игътибарга алыр-

[4] 1930 елда Захарьевская урамына К.Насыйри исеме бирелә.
[5] Революциядән соң Екатерининская һәм Тихвинская урамнары берләшә һәм «Тукаев урамы» дип атала башлый, 1986 елда гына, шагыйрьнең 100 еллык юбилее уңаеннан, Казан шәһәре башкарма комитеты карары нигезендә, әлеге урамга Габдулла Тукай исеме бирелә.

лар һәм иттифак белән җомга көннәрне кибетләрен җомгадан соң гына ача башларлар, дип өмид итәбез.

1914. — №366. — 20 март.

Болгарская[6] бенефисы

Җомга көн Болгарскаяның бенефисы булып үтте. Островскийның «Гроза» исемле пьесасы татарчага тәрҗемә ителеп куелган иде. Артистлар пьесаны тырышып, иттифаклы уйнадылар. Бенефис сахибәсе [иясе] Катерина ролен шактый муаффәкыять [уңыш] белән иҗраэ итте [башкарды].

Карарга килүчеләр, урыннарның кыйммәтлегенә дә карамастан, күп булды. Шәрык клубының залы тулы иде. Бенефис сахибәсенә түбәндәге һәдияләр [бүләкләр] тәкъдим ителде. Шәрык клубыннан көмеш ридикюль, Зәйнәп ханым Хәсәниядән[7] кыйммәтле ташлы алтын йөзек, Фәхрелислам Агиевтан[8] чын чәчәкләр букеты, Г.Кариевтан[9] беләк сәгате, Газиз Биккиниевтан алтын булавка һәм башкалардан альбом, чәчәкләр, берничә ханымәфәнделәрдән акча бирелде.

Спектакль бик соң башланып, бик соң бетте. Игълан ителгән танцыларга да вакыт калмады. Халыкта беркадәр ялыкканлык сизелде.

1914. — № 368. — 23 март.

Шәрык клубында чахотка[10] җәмгыяте файдасына спектакль

26 мартта* Шәрык клубы залында чахотка илә көрәшү җәмгыяте файдасына мөселманча вә русча спектакль куелды. Бу кичә, мөселман зыялыларыннан бу эшкә мәхәббәт итүчеләр тарафыннан ясалып, беренче эш булуына карамыйча, бик гүзәл генә ясалган. Шәрык клубының залы кыйммәтле ковёрлар вә ак чәчәкләр илә бик матур итеп җыештырылган, хатыннар бүлмәсенә гүзәл генә чәй өстәле хәзерләнгән иде. Ләкин бу кичәнең сөекле бер кичә булуына карамыйча, халык никтер яхшы ук аз килгән. Бу тугрыда мәхәлли [җирле] матбугатының алдан хәбәрдар итмәве сәбәпле, халыкны бу эшкә димләштермәвенең дә тәэсире булганга охшыйдыр ки, киләчәктә матбугат һәм кичәне ясаучылар, әлбәттә, бу кимчелекне тутырырлар, дип өмид ителәдер.

«Сәяр» труппасы бу кичә өчен муаффәкыятьсез [уңышсыз], шуның берлә бик иске пьеса булган «Оят, яки Күз яше» пьесасын[11] сайлаган икән. Артистлар үз рольләрен һәммәсе тигез генә уйнадылар. Мөселманча спектакльдән соң чахотка берлә көрәшү җәмгыяте әгъзаларыннан врач Лори кыска гына нотык берлә артистлар вә халыкка мөрәҗәгать итеп: «Безнең Казанда бу җәмгыятьне тәэсис иткәндә [оештырганда] Казанның бу җәмгятькә башка шәһәрләргә ике өлеш артык мохтаҗ булганлыгын икърар иткән идек. Чөнки Казан халкы араларында чахотка иң күп таралган мөселман халкы. Үз арасында

---

* Даталар иске стиль белән бирелә

[6] Гөлсем Муса кызы Болгарская (Мостафина Өммегөлсем) (1891-1968) — актриса, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисткасы.

[7] Зәйнәп Ногман кызы Хәсәни (1887-1967) — «Аң» журналының сәркатибе. Ире Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәни (1883-1934) — «Аң» журналының (1812-1818) нашире һәм мөхәррире.

[8] Фәхрелислам Нигъмәтулла улы Агиев (1887-1938) — балалар язучысы, журналист. «Ак юл» журналының нашире һәм мөхәррире.

[9] Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйрулла улы Хәйруллин) (1886-1920) — актёр, режиссёр.

[10] Чахотка — үпкә туберкулёзы авыруының иске атамасы.

[11] «Оят, яки Күз яше» 4 пәрдәлек драма әсәренең авторы Я.Вәли.

Чахотка корбаннары: шагыйрь Габдулла Тукаев, мөгаллимә вә мөхәррирә Фатыймаи-Фәридә ханым.
«Вакыт» газетасы. 1916 ел, 1 май (№ 2025)

чахотка бик күп таралган булса да, халык бу хәерле эшкә үзләре катнашмас, дип уйлаган идек. Ләкин шушы берничә еллык тәҗрибә безнең ул уебызның хата булганын бик ачык күрсәтте. Табигый, без уебызның хата чыгуына соң дәрәҗәдә шатланабыз. Без уйлыйбыз ки, мөселман халкы моннан соң да бу эшкә чынлап торып катнашыр вә хезмәт итәр. Хосусән, соң дәрәҗәдә кызгандыгым, мөселман халкының сөекле шагыйре Тукаевның һәм дә мөслимә мөхәррирәләреннән Фатыймаи-Фәридә ханымның[12] шушы чахотка корбаны булулары, мөселман халкына бу чахотка илә чынлап торып көрәшүләренә сәбәп булыр, аларны бу кыйммәтле адәмнәренең югалулары чахотканың чын кабахәт дошман икәненә төшендерер, диеп уйлыйбыз». Соңрак, клуб идарәсенә вә мөхтәрәм артистларга: «Безгә бинаны бушлай бирдегегез вә бушлай уйнадыгыгыз өчен чын күңелдән тәшәккер итәбез. Без, мөселман артистлары, бу кадәр художественный уйный алырлар, диеп уйламаган идек, ләкин безнең шатлык илә тәгаҗҗебебезгә каршы, мөселман артистлары соң дәрәҗәдә яхшы вә һәрбер хәрәкәтләре илә мөкәммәл дәрәҗәдә матур вә художественный итеп уйныйлар икән», — диде.

Русча спектакль дә матур гына үтте. Кичәдә ак чәчәк сатып йөрүче зыялы яшьләр вә ханымнарның булмавы да аермачык күзгә бәреләдер иде. Ләкин шулай да, күбрәк зыялы халыктан гыйбарәт булган бу кичә күңелле генә, матур гына үтте. Кичәнең башында торып хезмәт итүче яшь врачларыбыздан Әбүбәкер әфәнде Терегулов[13], Әминә ханым Терегуловаларга[14] мондый сөекле кичә ясап артыннан тырышып йөрдекләре вә күп хезмәт куйдыклары өчен, Шәрык клубы идарәсенә шундый сөекле эшкә Шәрык клубы залын бушлай бирдеге вә артистларга бушлай уйнадыклары өчен чын-чын тәшәккер итеп, киләсе кичәләрнең һәм матди, һәм мәгънәви муаффәкыятьле [уңышлы] чыгуларын чын күңелдән теләп каламын. Кичәдән йөз сум чамасы файда калган. И.Бикколов[15].

1914. - №373. — 28 март.

*Текстны һәм искәрмәләрне басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

---

[12] Фатыймаи-Фәридә (Фатыймаи-Фәридә Мортаза кызы Ваһапова) (1889-1914) — педагог, публицист, нашир. Ире М.Нәүрүзов белән бергә «Сибирия», «Тормыш» газеталарын нәшер итә.

[13] Әбүбәкер Батыргәрәй улы Терегулов (1885-1966) — табиб һәм педагог, галим, җәмәгать эшлеклесе, медицина фәннәре докторы, татарлар арасында беренче медицина профессоры, ТАССР һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе.

[14] Әминә Ибраһим кызы Терегулова (1887-1975) — «Яшьләр» труппасында катнашкан сәнгатькяр, тәрҗемәче, укытучы. Әбүбәкер Терегуловның хатыны.

[15] Ибраһим Җамалетдин улы Бикколов (1884-1938) — журналист, педагог, тәрҗемәче.

СПОРТ ТАРИХЫ – ИЛ ТАРИХЫ

АЛМАЗ ГАФИЯТОВ

БҮГЕН СПОРТ ТОРМЫШЫБЫЗГА ШУЛКАДӘР ҮТЕП КЕРГӘН КИ, ЯШӘЕШЕБЕЗНЕ АННАН БАШКА КҮЗАЛЛАП ТА БУЛМЫЙ. КАЙЧАНДЫР СПОРТ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮ ХОББИ, ЯГЬНИ МАВЫГУ ДИП КЕНӘ КАРАЛСА, БҮГЕН УЛ ПРОФЕССИОНАЛЛАРДАН ТОРГАН БЕРБӨТЕН СИСТЕМА БУЛАРАК БӘЯЛӘНӘ.

Спорт индустриясендә атлетлар гына түгел, аларның тренерлары, табиблар, югары уку йортлары белгечләре, стадион, спорт сарайлары хезмәткәрләре һәм хәтта җанатарлар да «әйләнә». Әйе, бездә хәзер яраткан командалары артыннан башка шәһәрләргә, хәтта чит илләргә йөрүче профессиональ җанатарлар да бар. Татарстанны да бүген нәкъ менә атаклы спортчылары, «Ак барс», «Рубин», «УНИКС», «Зенит», «Динамо-Казан», «Синтез» кебек командалары аркылы беләләр. Чыннан да, бүген спорт тормышыбызда әһәмиятле урын алып тора.

Үзеннән-үзе «Ни өчен?» дигән сорау туа. Моның җавабы гади: бер-берсе белән узышу, көчле, батыр булу теләге биологик зат буларак кешенең генына ук салынган. Шуңа күрәме Борынгы Грециядә беренче Олимпия уеннары уздырыла башлаганчы ук, төрле илләрдә яшәүче халыкларның үз ярышлары (уктан ату, йөгерү, йодрык сугышы, таш күтәрү, көймәдә йөзү, атта чабу һ.б.) барлыкка килгән.

Татар халкының ерак гасырлардан килә торган милли бәйрәме — Сабан туе да, нигездә, спорт ярышларыннан, төрле көч сынашулардан тора. Галимнәр фикеренчә, ул да Олимпия уеннарына кадәр барлыкка килгән. Шулай булгач, республикабыз спортының тарихы да берничә мең ел белән исәпләнә.

Кызганычка каршы, халкыбызның милли бәйрәмнәре, шул исәптән спорт тарихы да, ныклап өйрәнелмәгән һәм язылмаган. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Милли архивы фотосурәтләре фонды берничә мең кадрдан тора. Әмма алар, нигездә, XX гасыр уртасыннан бүгенгә кадәр генә төшерелгән фотосурәтләр. Югыйсә башкалабыз Казанда беренче спорт түгәрәкләре XIX гасыр ахырында ук оеша. Мәсәлән, шахмат клубы 1884 елда ачыла. Ул СССРда Петербург, Харьков һәм Ташкенттан соң дүртенче клуб була. 1912 елда Казанга булачак дөнья чемпионы Александр Алехинның килүе билгеле. «Камско-Волжская речь» газетасында әлеге вакыйга уңаеннан зур-зур язмалар дөнья күргән, анда атаклы шахматчының көндәшләре, ничек уйнавы, җиңү һәм җиңелүләре хакында бик тәфсилләп язылган.

Спорт тарихы ил тарихыннан, республика тарихыннан аерылгысыз. Безнең илдә: «Спорт чын-чынлап Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына чәчәк атты», — дип әйтергә яраталар. Әмма бу алай түгел. Мәсәлән, Казан чаңгычылар клубы, «Яхт-клуб», «Сокол», «Беркут» спорт җәмгыятьләре 1908-1912 елларда барлыкка килә. Казанда тимераякта узышу буенча беренче чемпионат 1912 елда уздырыла, стартка сигез спортчы чыга. Чаңгычылар арасында Казан университеты студентлары шулчакта ук дан тота. 1915 елда Сечень һәм Геркан фамилияле ике студент Казаннан Сембер шәһәренә чаңгы походы оештыра. Соңрак әлеге поход массакүләм төс ала.

Революциягә кадәр Россиядә спортның үсеп китә алмавын физик культура кадрларының аз булуы, укытучы һәм инструкторларның нигездә чит илләрдә укып кайткан белгечләрдән торуына бәйле. Мәсәлән, зур территорияне биләп торган Казан губернасында бу елларда махсус дипломга ия булган нибары егерме биш физкультура укытучысы исәпләнә, аларның да егерме бере Праганың атаклы Сокольский җәмгыятендә укыган була. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң берничә ай үтүгә, 1918 елның апрелендә, кырык яшькә кадәрге эшчеләрне һәм уналты яшьтән башлап үсмерләрне мәҗбүри рәвештә хәрби сәнгатькә өйрәтү хакында декрет дөнья күрә. Хәрби өйрәнүләрнең нигезе итеп физик күнекмәләр алына. Бигрәк тә халык арасында киң таралган чаңгы спорты буенча өйрәнүләр массакүләм төс ала. Всеобуч (гомуми белем бирү) оешмасы тарафыннан «Наставление по обучению лыжных частей» һәм «Положение об отдельных лыжных ротах-командах» дигән китап-брошюралар чыгарыла, һәм яшьләрне чаңгыда шуарга өйрәтү өчен иң көчле чаңгычы-инструкторлар чакырыла. Боларның барысы да хакимиятнең бу эшкә зур әһәмият бирүе хакында сөйли. Бу вакытта илдә Гражданнар сугышы баруын да онытмыйк. 1919 елның ахырында Казанда Үзәк хәрби-спорт клубы оеша. Ул бөтен Идел буе төбәгендә беренче була һәм физкультура-спорт үсешендә

зур роль уйный. 1920 елның кышында Казанда ике зур чаңгы базасы ачыла (берсе Кабан күле буенда, икенчесе «Рус Швейцариясе» дип аталган Үзәк паркта була). Моның өстәвенә һәр өяз шәһәренә чаңгы буенча инструкторлар чакырыла, укучылар чаңгы белән тәэмин ителә, әлеге спорт төре, мәктәп программасына кертелә. Алгарак китеп булса да, тагын шунысын да әйтик: чаңгы буенча Татарстан беренчелеге тәүге тапкыр 1921 елның 12 мартында Казанның Үзәк ял һәм мәдәният паркында үткәрелә. Ярышларны оештыручылар тарафыннан бары бер генә дистанция — егерме биш чакрымга узышу тәкъдим ителә, катнашучыларның саны өч дистәгә дә тулмый, әмма, безнеңчә, республикабызның чаңгы спорты тарихы әнә шул датадан башлап исәпләнергә тиеш.

Республикабызның спорт тарихы исә 1920 елның 25 июненнән башлана, чөнки шул көнне Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү хакындагы декретка кул куела.

1921 елның гыйнварында Казанда Всетатспорт оешмасына нигез салына (аны хәзерге Спорт министрлыгының башлангычы, дип атарга мөмкин). Әлеге оешма республикадагы барлык спорт секцияләрен, түгәрәкләрен берләштерә, ярышлар оештыра, спорт инструкторлары әзерли, мәктәпләр, пионер һәм комсомол оешмалары, завод-фабрикалар белән тыгыз элемтәдә тора.

1928 елда илдә беренче җәйге Бөтенсоюз спартакиадасы үткәрелә. Анда катнашу өчен, республикабыз атлетлары иң элек үзебездә сайлап алу ярышларын үтәргә тиеш була. Кадрларны сайлау эшен 1926 елда Татарстанда оешкан «Динамо» җәмгыяте тормышка ашыра. Әлеге җәмгыять республика спорты үсешенә бик зур өлеш кертә: «Динамо»да тәрбияләнгән спортчылар авыр атлетика, фехтование, самбо, дзюдо, иректле һәм грек-рим көрәше, волейбол, чаңгы спорты, җиңел атлетика буенча СССР, Европа, дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында һәм Универсиадаларда катнаша, дистәләрчә медальләр яулый. Бөтен ил буенча ГТО, «Ворошиловча атучы» значокларына норматив кертелә, физкультура институтлары һәм техникумнары ачыла, алар чыныккан, таза-сау яшьләр тәрбияләүне максат итеп куя.

1931 елда Казанда беренче физкультура техникумы, 1949 елның мартында Казан дәүләт педагогика институтында физик тәрбия факультеты ачыла. Соңрак Әлмәттә физкультура техникумы, Чаллыда физкультура институты оеша, һәм республика спортына кадрлар әзерләү эше массакүләм төс ала.

Әле берничә ел элек кенә Идел буе физкультура, спорт һәм туризм академиясенең барлыкка килүе, 2013 елда Казаныбызда Универсиада үтү, ел саен диярлек бездә аерым төрләрдән Европа, дөнья чемпионатлары уздыру Казанны Россиянең спорт башкаласына әйләндерде.

Республика спорты тарихын язучылар арасында без Дамир Шәрәфетдинов, Илдус Илдарханов, Мәгъсүм Гәрәев, Борис Марихин, Владимир Болдаевский, Атлас Гафиятов, Александр Медведев кебек күренекле журналистларны кертә алабыз.

Кечкенә генә күзәтүдә республикабызның спорт тарихын тулысынча чагылдыру мөмкин түгел. Чөнки спорт үзе бик күп төрләрдән тора, һәркайсының үз тарихы бар. Бүген Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы үткәрә торган ярышлар календарена йөзгә якын спорт төре кертелгән. ■

Мирасворд

- кием каптыргычы
- дини тезмә әсәр
- ... Дәүли
- элекке административ-территориаль берәмлек
- Габдерәхим ... Имәни
- шарык поэзиясендә лирик жанр
- бер динне тоткан халык
- үткен, зирәк, хәйләкәр
- Идел буе Болгары шәһәре / ... Шәриф
- 1906 елда Казанда чыккан газета
- татар халык җыры
- шагыйрь Шамил ...
- бергә җигелгән берничә ат
- Татарстандагы елга
- җырлы-биюле уен
- Марсель ... (фольклорчы галим)
- матур, сөйкемле (иск.)
- ут, ялкын (иск.)
- Фатих Кәрим поэмасы / зарар
- мәркәзе Бәйрут
- ... Ишморат / ... Үрманче
- Гарсиа ... (испан шагыйре)
- мәшһүр татар җырчысы
- Наис ...
- ... Мирзаянов
- тропик дала
- Болгария каласы
- мәчет каланчасы / баш кисәк
- күренекле татар химигы
- халык, халык массасы (иск.)
- дару, шифа
- Алтын ... дәүләте
- Венгр шагыйре
- Оканың уң кушылдыгы
- Рәсүл Гамзатовның милләте
- Нарьян-... / дивар шәмдәле
- Майн ...
- Батыр сугышчы, рыцарь (иск.)
- Борынгы Идел
- Румыниядәге шәһәр

***Рәис Габдулла** төзеде*

ЯҢА КИТАПЛАР



Хамидуллин Л.Х. АМИРХАН ЕНИКИ [перевод с татар. Б.Хамидуллина]. — Казань: Татар. кн. изд.-во, 2013. — 48с.

Әмирхан Еники иҗаты турында күпсанлы мәкаләләр язылган, фәнни-тикшеренү эшләре башкарылган булса да, әдип үткән юл, кылган гамәлләр даими рәвештә төрле катлам укучыларын кызыксындырып тора. Күренекле галим, язучы Лирон Хәмидуллинның Әмирхан Еники иҗаты белән кызыксынуы очраклы хәл булмый. Ул шәхси архивына, әдип турында сакланган мәгълүматларга, «Казан утлары» журналында җыелган материалларга, әдипләр Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин тарафыннан тәкъдим ителгән фотоларны кулланып, тарихимәдәни эчтәлекле китап язып чыга.

Әлеге китап Булат Хәмидуллин тәкъдим иткән «Татар тарихы шәхесләр язмышында» сериясе кысаларында басыла. Сериянең бу китабын язган һәм төзегән Л.Хәмидуллин кызыклы гына эзлеклелектә материалны урнаштырып чыгуга ирешкән. Аерым игътибар әдип үткән юлга гына түгел, ә нәсел җебен, шәҗәрәсен өйрәнүгә юнәлтелгән. 1773 елда морза Еникеевләр Терегуловлар белән берлектә Мамлеевлар, Кильмаметовлар, Янгуразовлар Башкортстандагы Яңа Каргалы авылына нигез салучылар буларак ачыла. Шул буыннар алмашында Әмирханның этисе Нигъмәтҗанның тормышы шактый тәфсилле ачыла. Ул һәрвакытта ирекле һөнәр сайлый. Аның Совет власте елларында сәүдә эше белән шөгыльләнүе дә күрсәтелә. Шуңа бәйле рәвештә Әмирхан да ирекле һөнәр сайлый. Әмма заман шаукымы, гаугалы елларда ул хәтта кайсы нәселдән булуын яшерергә мәҗбүр була.

Бу китаптагы барлык мәгълүмат 11 бүлеккә таркатып тәкъдим ителә. Һәр бүлек әдип тормышындагы яңа бер сәхифәне ачуга багышлана. Язучы тормышындагы беренче мәхәббәт тарихы алгы планда бирелә. Әмир — Хаҗәр мөнәсәбәтләре кызыклы итеп тасвир ителә. Гомумән, барлык мәгълүматлар Ә.Еникинең «Соңгы китап» повестеннан, әдәби-публицистик мәкаләләреннән, матбугатта басылган тәнкыйть фикеренә нигезләнеп алынган.

Әлеге сериягә кергән мәгълүмат арасында Ә.Еники һәм башка шәхесләр белән булган мөнәсәбәтләр аерым бирелә. Аеруча әдипнең беренче иҗат адымнары хисси-эмоциональ планда ачыла. Әдипнең Һ.Такташ, Г.Кутуй, Ш.Усманов, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, М.Җәлилгә бәйле вакыйгалар фотосурәтләргә нигезләнеп тә ачыла. Әйтик, 23 нче биттәге Ә.Еники, М.Җәлил һәм Т.Ченәкәй төшкән фотосурәт укучылар өчен кызыклы булачак. Чөнки XX гасыр башында исеме күпләргә мәгълүм булган, әмма, объектив сәбәпләр аркасында, әдәби процесстан төшеп калдырылган Төхфәт Ченәкәй эшчәнлеген бөтенләй телгә алмыйбыз. Аның каравы, бу шәхес нәкъ Ә.Еники тәкъдим иткән «Ченекәй кем ул?» дигән мәкаләдә ачыла. Әлеге күзәтүдә дә кайчандыр Ә.Еники белән бәйле булган Ченәкәй исеме «җидегәнчелек» хәрәкәте белән бәйләп карала.

Җыеп әйткәндә, әлеге сериягә кергән китапта Ә.Еники эшчәнлеге тарихи фактлар яссылыгында ачыла. Архив материалларына таяну, әдип мәкаләләрен игътибарга алу, «Соңгы китап», «Без дә солдатлар идек» кебек әдәби һәм автобиографик чыганакларга нигезләнеп, документальлеккә корылган күзәтү ясала. Әдип гомере буе үзе яшәгән чор, чолгап алган тирәлек, шәхесләр белән кызыксынып яши. Аның мәкаләләрендә, публицистик язмаларында һәм әдәби әсәрләрендә үткән юлы, хис-кичерешләре, мөнәсәбәте чагылыш таба.

Әлфия Мотыйгуллина,
филология фәннәре кандидаты

РАВИЛ ЗАҺИДУЛЛИН

рәссам

Равил Габделбәшир улы Заһидуллин 1960 елның 28 октябрендә Казан шәһәрендә туа. 1978-1984 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында укый. Иҗаты тарихи темаларга багышлана. 1990 елда СССРның Рәссамнар берлегенә кабул ителә. Казан, Мәскәү, Будапешт (Венгрия), Зютфен (Голландия), Абу-Даби (БГӘ), Чебоксар, Кувейтта үткәрелгән күргәзмәләрдә катнаша.

Равил Заһидуллинның әсәрләре шәхси тупланмаларда Казан шәһәренең сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә урын алган.

«Болгар кызы». 2011. Киндер, майлы буяу

«Болгар шәһәрен саклау». 2009.
Киндер, майлы буяу

МИРАС
№3 / 2014

*Халкыбыз тарихы,
әдәби, мәдәни мирасыбыз,
тәнкыйди фикер һәм
заманча караш – барысы да*
«ЧЫН МИРАС»
журналында

Университет һәм Зур Проломная урамнары почмагындагы И.Бренинг даруханәсе.
Бүгенге көндә — И.Бренинг даруханәсе

ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ – 70275

БЕЗ МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «ЧЫН МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!